Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә шайтан 1) дини мифологиядә: кешеләрне котыртып юлдан яздыручы, җирдә явызлык таратучы явыз көч, иблис *(Үз котырыгына ияргән шайтанны гаеплиләр)*; 2) мәҗүсиләрдә: корбан таләп итә торган явыз рух; 3) куч. Андый кешене яман эшкә этәрә торган хисләр символы *(Нәфес – шайтан, акыл – иман)*; 4) сүгенү, тиргәү сүзе дип бирелгән. Әлеге лексема кергән фразеологизмнар да китерелгән. *Шайтан күбеге* – төче суларда яши торган болыт; *шайтан таягы* – оешма чәчәклеләр семьялыгыннан чәнечкеле үлән, үсемлек; *шайтан алгыры(сы)* – 1) каргау, тиргәү сүзе; 2) үкенү сүзе; *шайтан алыштырган* – бик үҗәт, тискәре һәм киребеткән кеше турында; *шайтан ачыткычы (төкереге)* – аракы; *шайтан аягын сындырырлык* (ирон.) – бик чуалчык, буталчык нәрсә, тәртипсезлек; *шайтан бала чыгарган җир* – бер җирдә кешеләр һаман җыелып бик көлсә, шаулашса, шулай әйтелә; *шайтан башлыгы* – шашынып, котырып, башкаларны да котыртып шау-гөр, уен-көлке тудырып, шуннан тәм табучы кеше; *шайтан белсен* – кеше төшенерлек хәл түгел; *шайтан бисмилладан курыккан кебек* – дини караштан; *шайтанга үлчим* – ташка үлчим; *шайтан дагалаган җир* – бозыклык оясы; *шайтан да юк (күренми)* – беркем, бернәрсә дә юк; *шайтан еккыры* – тиргәү сүзе; *шайтан кендеген (койрыгын) күрсәтеп тора мәллә* – бернинди сәбәпсез көлеп куйган кешегә әйтелә; *шайтан котырту* – үзсүзләнү, юри этлеккә салыну; *шайтан котырыгы* – бер гаеп эшләп тотылганда, гаепне шайтанга сылтап әйтү; *шайтан курчагы* – бик ямьсез бизәнгән, зәвыксыз киенгән хатын-кыз; *шайтан сабагы* – дини өйрәтүләргә нигезләнмәгән уку; *шайтан симертү* – нәфесне аздыру, симертү, күп йоклау; *шайтан суы* – аракы; *шайтан таңы* – таң алдыннан була торган сыек яктылык, якты таң; *шайтан тырнагы* – тырнак төбе яргаланып кубудан барлыкка килгән җәрәхәтле тиренмә тире; *шайтан туе* – өермә; *шайтан фигыле* – кешеләр өчен хас булмаска тиешле начар холык, кыланыш эш турында; *шайтан яшеннән курыккан кебек* – бик каты курку; *шайтани* – шайтанга хас, шайтан кебек; *шайтани көлү* – явыз, мәкерле, мыскыллы көлү; *шайтани көнчелек* – мәкерле, явыз көнләшү; *шайтани тынычлык* – тулы, берничек тә бозып булмаслык тынычлык;

---

* Ass. Prof., Ph. D., Kazan Federal University, Kazan

*шайтани төш* – мәгънәсез, куркыныч төш турында; *шайтанлану* – 1) хәйләләнү, ялганлау белән шөгыльләнү; 2) шаяру, шуклану (ТТАС, 2005: 674-675).

Шулай ук шайтан сүзенең дериватлары да тәкъдим ителгән: *шайтанлана бару, шайтанлана төшү, шайтанланып бетү, шайтанланып йөрү, шайтанланып кую, шайтанланып тору*.

Этимологик сүзлектә шайтан сүзе «черт», «сатана» – гарәпчәдән *шайтан-ун* «шайтан» сүзеннән (*сатана белән бер нигездән*), семит телләрендә «*суд позициясе*» дип аңлатыла (Әхмәтъянов, 2001: 246).

Фикер йөртүләребез буенча, шайтан дигәч, җенне күз алдына китергән идек, әмма синонимнар сүзлегендә *шайтан* сүзенә дә, *җен* һәм *перигә* дә синонимнар таба алмадык. Соңрак исә, дини әдәбият белән танышканнан соң, шайтан белән җен икесе ике нәрсә, алар арасында аерма зур икәнлеге ачыкланды. *Җен* ул – кешегә начарлык эшләми торган, әмма аны үз максатлары өчен кулланучы, ә *шайтан* – кешегә начарлык эшләүче, аны котыртучы. Дини белешмә сүзлектә шайтанга *иблис* туры килә. Ул болай бирелә: иблис – яла ягучы шайтан. Аллаһка буйсынмаган өчен каһәрләнеп, күктән җиргә сөрелгән һәм кешеләрне адаштыру белән шөгыльләнүче элеккеге фәрештә (Фәхретдин, 2004: 108).

Шайтан сүзе урысчага тәрҗемә иткәндә *черт* дип бирелә, җен дә шулай ук *черт*, ләкин татар телендә алар мәгънәре буенча аерылалар.

Дингә каршы килеп, «Миллият сүзлеге»ндә болай диелгән: *гадәттә шайтан сүзен иблис сүзенең синонимы итеп карыйлар, ләкин бу төгәл түгел. Иблис ул – шайтаннарның башлыгы, аны «Иблис әш-шайтан» дип тә йөртәләр* (Миллият сүзлеге, 2007: 547).

Бу сүзлектә шулай ук *шайтанат* сүзенә шайтаннарның күплек саны, *шайтанлык* – хәйләкәрлек, мәкерлек; *шайтан арбасы* – көлтә ташый торган арба, тирес ташый торган арба, башкача пәри арбасы, дүңгәләк, тәгәрәй үләне; *шайтан туе* – тузан өермәсе, башкача пәри туе, җен туе дигән фразеологизмнар да бирелгән. Татарларда нардуганны «шайтан туе» дип атаганнарын, элек гаепле, гөнаһлы кешене урам буенча мәсхәрә кылып йөртүне дә *шайтан туе* дип әйткәннәрен искәртеп үтелгән (Миллият сүзлеге, 2007: 547).

Димәк, сүзлекләрдән чыгып фикер йөртсәк, *шайтан* – кешеләрне котыртып юлдан яздыручы, корбан таләп итүче зат; сүгенү, тиргәү сүзе. Бу лексеманы, актив кулланылуына карамастан, алмаштырырлык һәм капма-каршы куярлык сүзләр юк, дип әйтә алабыз.

Татар халкында *шайтан* сүзе кергән мәкаль һәм әйтемнәр бик күп. Хәзер шуларга тукталып үтик.

38324 *Ак шайтан, кара шайтан – бар да шайтан*. Димәк, шайтанның яхшысы юк дигән сүз.

38325 *Алла шайтаныннан, адәм шайтаны яман*. Димәк, иң начар сыйфатка ия шайтан – кешенең үз шайтаны.

38326 *Алырсың шайтаннан иман!* – шайтан имансыз дигәнне аңлата.

38327 *Аргымакны байтал ияртә, әрвахны шайтан ияртә* – котыртучы мәгънәсендә.

38328 *Башны бозган балта, түшне бозган шайтан* – шайтан – бозучы.

38330 *Дары исеннән шайтан кача* – димәк, шайтаннан саклану ысуллары бар.

38331 *Адәм димче, шайтан камчы* – шайтан – тәнне авырттыручы.

38332 *Адәм шайтаны адәм булыр* – кешенең начарлыклары үзе шайтан дигән сүз.

38333 *Изгеләр янында шайтан үрчи* – шайтанның изге кешеләрне начарлыкка өндәргә тырышуы.

38336 *Ишәк ише, шайтан мәе белән* – шайтанның үз коралы бар һәм ул харәм аша керә.

38338 *Кешенең шайтаны үзендә* – шайтан кешенең эчендә яши һәм аның коткысына бирелергә мөмкин.

38339 *Кәефе килгәндә, шайтаннан да яхшы* – шайтанның иң начар зат икәнлеге күренә.

38340 *Күренми килгән шайтаннан күренеп килгән шайтан уздырыр* – шайтанның күренә торганы һәм күренми торганы бар, алар бер-берсеннән аерыла һәм күренеп килгән шайтан җитезрәк булып чыга.

38343 *Начар, начардан шайтан качар* – шайтан яхшы кешеләр янында гына йөрер, аның максаты – яхшы кешеләрне начарлыкка күндерү.

38342 *Муллаларга катышмасаң, дога белмәсәң, шайтан сиңа дошман түгел* – шайтан дингә каршы, ул дин юлындагы кешене ниятеннән кайтарырга тели.

38344 *Өермә – шайтан туе* – күз ачкысыз, бөтен нәрсәне үзенә җыеп ала торган күренешне шайтан туе дип атыйлар.

38345 *Өметсез – шайтан* – шайтан бернигә өметләнми, югалта торган изге әйберләре юк.

38346 *Сылтау өчен дөньяда шайтан бар* – берәр эш килеп чыкмаганда үз гаебеңне сылтарга шайтан бар мәгънәсендә.

38348 *Хәерле эшне ашыктырмасаң, шайтан катыша* – шайтан аны булдырмас өчен барын да эшләячәк.

38349 *Черт белән шайтан икесе дә бер* – алар икесе дә кешегә начарлык эшләүче.

38351 *Шайтан белән юлга чыксаң, койрыгын ычкындырма* – шайтан сине үзеннән адаштырып калдырырга мөмкин.

38352 *Шайтанга бармагыңны бирсәң, кулыңнан коры калырсың* – шайтан хәйләләү юлы белән күбрәкне үзенеке итәр.

38355 *Шайтаннан игелек көтмә* – шайтан игелексез.

38357 *Шайтаннан үлмәс туар, чукрактан көлмәс туа, сукырдан күрмәс туар* – шайтаннар үлемсез.

38358 *Шайтанны җен нишләтсен* – шайтан белән җен икесе дә кара көчләр.

38359 *Шайтанның бәйрәме юк* – шайтан андый нәрсәләрне белми.

38360 *Шайтанның дуслыгы дары агачы хәтле* – үзенә кирәк булган очракта гына дус булып кылана.

38361 *Шайтан төрлене уйлата* – начар уйларга бирелдерә.

38662 *Шайтан ярлы, без бай* – шайтанның бернәрсәсе юк, ә кешенең бай күңел дөньясы, изге гамәлләре бар.

38364 *Алла малын шайтан кызганган* – шайтан саран.

38365 *Алла шайтанны үзе яраткан*; 38366 *Алла шайтансыз булмый* – шайтан Алла каргышыннан килеп чыккан.

38369 *Хәлем Алла теләгәнчә дә түгел, шайтан теләгәнчә дә түгел* – Алла теләгәнчә хәл – яхшы булырга тиеш, шайтан теләгәнчә – начар.

38370 *Шайтан акыллы булса да, Алланы яратмый* – шайтан Аллага каршы.

692 *Тик йөргәннән тәңре бизәр, тикмәгә шайтан гизәр* – тик йөрүче кеше янында һәрчак шайтан булыр, үз кыйбласын төгәл ачыклап бетермәгән кешене юлдан яздыру җиңелрәк.

10568 *Яман хатыннан шайтан да качкан*; 10649 *Яхшы хатын – оҗмах ачкычы, яман хатын – шайтан камчысы*; 11140 *Бер хатын үзе җитмеш шайтанга тора*; 11170 *Хатын шайтаннан уздырган* – яман хатын шайтанның камчысы кебек авырттыручан, бәйләнүчән, каныгучан була.

11025 *Аерылган хатыннан шайтан үзе качкан, ди* – ирдән аерылу – гөнаһ эш икәнлеге ассызыклана.

19016 *Йоклап шайтан симертмә* – кеше никадәр ялкау булса, шайтанга шулкадәр яхшырак.

Шулай итеп, әлеге мәкаль-әйтемнәрдән шайтанны *ялганчы, кешеләрне туры юлдан яздыручы, начарлыкка өндәүче, имансыз*, *ак* яки *кара* төстәге, *койрыклы*, дин кануннары белән яшәүче һәр яхшы күңелле кешене *котыртып йөрүче* дип нәтиҗә чыгарырга була.

## ӘДӘБИЯТ

Әхмәтъянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – Б. 246.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 3 т-да. – Т. III. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – 991 б.

Миллият сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 575 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. – Б. 674-675.

Фәхретдинов Р. Сайланма хәдисләр аңлатмасы. – Казан: Матбугат йорты, 2004. – Б. 16.

# ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕ ҮСЕШЕН ТӘЭМИН ИТҮЧЕЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

## (ONE OF THE LEADING AUTHORS OF MODERN TATAR DRAMATURGY)

**Foat GALIMULLIN***

**SUMMARY**

The article gives a brief overview of the development of the Tatar drama, shows the influence of the Turkic drama. The leading playwrights are called. The creative way of the modern playwright Yu. Safiullina is considered in detail. The main theme and problems of his works are singled out.

Татар драматургиясе, әлбәттә, илдә үсешен тоткарлаучы сәбәпләр булмаган очракта, әле XIX гасырда ук барлыкка килер иде. Милли театар булдыру, туган телдә ачык спектакльләр уйнарга рөхсәт булмау бу эшне тоткарлап килә. Татарның зыялылары Казанда куелган рус театры спектакләрен карагач, шушындый тамашаларны үз туган телебездә дә оештырырга иде дип хыяллананалар. Ләкин рәсми хакимиятләр моны катгый рәвештә тыялар. Әмма, куелу ихтималы булмаса да, Г. Ильяси, Ф. Халиди кебек алдынгы карашлы татар зыялылары спектакль итеп уйнауга нигезләнгән беренче әсәрләрне иҗат итәләр. Төрек авторлары әсәрләрен тәрҗемә итә башлауны да шушы ихтыяҗ барлыкка китерә. Г. Исхакый, Г. Камалларның беренче драма әсәрләре язылган елларда да аларны халыкка спектакль рәвешендә уйнап тәкъдим итү мөмкинлеге булмый. Мондый ирек бары тик 1905 елда аеруча зур көч булып кабынган инкыйлаб нәтиҗәсендә генә яулап алына. Шуннан соң бер-бер артлы драма әсәрләре барлыкка килә башлый. Патша хакимияте 1906 елдан башлап аларны ачыктан-ачык сәхнәләрдә уйнарга рөхсәт итәргә мәҗбүр була. Ф. Әмирхан, Г. Коләхмәтов, К. Тинчурин Ш. Камал, М. Фәйзи, Ш. Усманов, Һ. Такташ, Ф. Бурнаш һәм башкалар иҗатның бу юнәлешен үстерүгә зур өлеш кертәләр. Аларның юлын Т. Гыйззәт, Г. Кутуй. Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, Х. Вахит, Т. Миннуллин һәм башкалар дәвам иттерделәр.

Шуннан соңгы чорларда татар драматургиясенең чәчәк атуына китергән шәхесләрнең берсе, һичшиксез, Юныс Сафиуллин. Бу тармактагы иҗаты шактый киңкырлы һәм нәтиҗәле булуына карамастан, бу үтә тыйнак, әмма гаҗәеп талантлы каләм әһеле турында аңа җиде дистә яшь тулган көннәрдә җыеп кына бер сүз дә әйтәсе килә. Каләмебезне бу очракта шушы теләк хәрәкәткә китерә.

Иҗат кешесе, нәрсә генә язмасын, яки сәнгатьнең кайсы төрендә генә пәйда булмасын, ул замандашларына нинди дә булса яңалыкны образ ярдәмендә бирүне, яшәешнең моңа кадәр күзгә ташланмаган якларын ачып күрсәтүне максат итә. Ул моны үз шәхесенең тирән күңел төпкелләрендә бөреләнгән хис-тойгыларын, уй-фикерләрен җитлектереп, билгеле бер рәвешкә китереп тормышка ашыра, шуның белән башкаларны да үзенең фикердәше, мәсләктәше итә торган тылсым көченә ия була. Күзгә артык ташланмыйча гына, үзләренең барлыгын әлләни сиздерергә омтылмыйча гына, иҗат колачларын киңәйтүләрен дәвам иттерәләр.

---

* Doktor Philol. Bilimler, Kazan, Kazan Federal Üniversitesi, Kazan.

Юныс Габдулла улын мин нәкъ шундый шәхес итеп карау ягында. Һәр нәрсә чагыштыруда ачык шәйләнә. Бу җәһәттән Ю. Сафиуллинны Т. Миннулин янәшәсенә куеп карыйк әле. Аларны бу очракта икесенең дә әтиләре Габдулла исемле булганлыгы гына түгел, бер үк чорда драматургиядә мәйдан тотулары да берләштерә. Т. Миннулин әсәрләре театрларыбызда еш уйналдылар, бер үк вакытта ул үзе дә халык күз алдында булды. Аның шаулатып сөйләмәгән заллары, аудиторияләре булмагандыр. Үткен, образлы чыгышлары белән тыңлаучыларны да уйландырды, катлаулы нәрсәләрне аларга гади, үтемле итеп җиткерә барды. Әсәрләре дә үзенең шушы холкына бәрабәр иде.

Юныс Габдулла улы да шул ук елларда иҗат колачын драматург буларак җәелдерә барды. Башка язучылардан аермалы буларак, драматург янәшәсендә аны аңлаучы фикердәше, әсәрләренә сәхнәдә җан өрүче “үз режиссеры” да булу шарт. Менә шул иҗатташыңны табу, аның белән бер арбага җигелеп тарту өчен дә үзенә бер төрле сыйфатларга ия булу кирәктер. Әмма безнең Юныс әсәрләр язу белән бергә аларны сәхнәгә чыгару гамәленә керешеп китүдә кыенлыклар кичерә. Бу бигрәк тә иҗатың башлангыч чорына карый. Шуңа күрә җитмешенче еллар башында ук сәхнә әсәрләре язуда уңышлы гына адымнар ясаса да, тамашачылар белән йөзгә-йөз очрашуларга әкренләп кенә килә. Югыйсә, ул язганнар үзләренең сәнгатьчә табышлары, күтәрелгән мәсьәләләрнең тормышчанлыгы һәм үткенлеге җәһәтеннән башка авторларның сәхнәдә барган әсәрләренән бер дә кайтыш булмый.

Сан барыбер сыйфатны тәэмин итә дигән фәлсәфи канун бу юлы да үзенең көчен раслый. Нәтиҗә булсын өчен, ягъни иҗатыңа игътибар итсеннәр, дисәң, үз-үзеңә нык ышанган хәлдә җиң сызганып эшләргә кирәк, нәтиҗә килми калмый. Юныс Габдулла улына да уңыш елмая башлый. Ниһаять, үзе эшли торган Күчмә театр “Әллә өйләнергә инде?!” комедиясен сәхнәләштерә. Исеме “күчмә” булса да, башкаладан читтә яшәгән халыкны театр тамашалары белән эстетик тәрбияләүгә гаять зур өлеш кертеп эшләүче әлеге коллективның спектакле киң яңгыраш ала. Мәсәлән, Мәскәүдә чыгучы “Тетральная жизнь” журналы (Без автора 1978: 37) бәяләвенчә, әсәр “персонажларның характерларын тирән белеп, күзәтү осталыгы һәм сәхнә кануннарын яхшы белеп” язылган. Ничек яхшы белмәсен? Бу вакытта инде Юныс Сафиуллин Казан театр училищесын гына түгел, Мәскәүнең үзендә Сәнгать институты каршындагы ике еллык Югары режиссерлык курсын да тәмамлап кайткан, шулар өстенә алты-җиде ел актер булып эшләү тәҗрибәсе дә бар. Димәк, болар аңа әсәрне язганда аны сәхнәдә гәүдәләндерү хасиятләрен дә профессионалларча күз алдына китерү мөмкинлеген бирә. Бу инде аның тагын бер өстенлеге булып тора. Театр сәнгаете белгече Д. Гыймранованың “Спектакль тамашачылар тарафыннан яратып кабул ителә” дип язуы әсәр авторы күңеленә дә канәгатьлек бирә (Советская Татария. – 1979. – 1 апрель). Башка театрлар да әлеге авторга игътибар итә башлыйлар. Әлмәт театры “Менә без дә үсеп җиттек...” әсәрен сәхнәгә чыгара (бу инде авторның үзенә дә нindидер ишарә булып кабул ителә, ягъни, менә мин иҗат иткән әсәрләр дә сәхнәгә күтәрелә башлады). Иң мөһиме – жанры буенча моңсу комедия дип билгеләнгән әлеге әсәрне дә тамашачы җылы кабул итә. Татар тел белеменең күренекле галиме, язучы Суфиян Поворисов аны, Уфадан эш белән командировкага килгәч, Туймазы шәһәрендә тамаша кыла һәм бик канәгать кала. “Уч төпләре кызганчы ярсый-ярсый кул чабу, рәхәтләнеп, вакыты-вакыты белән күздән яшь чыкканчы көлү спектакльнең

башыннан азагынача дәвам итте. Димәк, әсәр дә игътибарга лаек, уйнаучылар да үз рольләрен сәнгать югарылыгы дәрәҗәсендә башкара” (Поварисов, 1980: С.4). Сарман районыннан татар теле һәм әдәбияты мөгаллиме, шагыйрь Әзһәр Габидидә дә спектакль шуңа охшаш тәэсирләр калдырган. “Әсәр җитди итеп көлдерә, уйландыра, тирән борчылдыра торган вакыйгаларга корылган. Автор комедия белән драма жанры мөмкинлекләрен табигый рәвештә куша алган. Гыйбрәтле, көлкеле хәлләр, бергә кушылып, бергә үрелеп, эчке драматизмны барлыкка китерә, тамашачыны көләргә дә, уйланырга да мәҗбүр итә” (Габиди, 1980: 3). Беренче пьесалар җыентыгының нәкъ шушы әсәр исеме белән аталуы да, мөгаен, авторның әлеге әсәрен иҗатындагы бер мөһим баскыч итеп каравыннан киләдер.

1981 елда Ю. Сафиуллинның тормышы һәм эшчәнлеге Г. Камал исемендәге театр белән тыгыз бәйләнә. Шуннан соң менә утыз җиде ел инде ул шушы татар театр сәнгате мәркәзендәге иҗат мохитендә яши. Бирегә актер итеп алынуы ук аның осталык мөмкинлекләренә бирелгән зур бәя дип кабул ителергә тиеш. Артистның гомуми зур таланты һәм шуның өстенә тагын нинди дә булса бер аңа гына хас ягы булмаса, бередәге олы талантлар арасында тиешле урыныңны табармын димә.

Артистлар арасында каләмлеләре дә булу электән килгән күренеш. К. Тинчурин, Т. Гыйззәт, З. Солтан, Г. Шамуковларны искә алыйк. Ю. Сафиуллин да шулар арасында. Мондый күпьяклы эшчәнлек алып барырга сәләтле кешене коллективта тагын да нәтиҗәлерәк итеп файдаланырга кирәклеге аңлашылып тора. Шулай итәләр дә – аны әдәби бүлек мөдире итеп куялар. Театр коллективының уңышы иң әүвәл сәхнәләштерү өчен әсәрләр табудан башлана. Димәк, әлеге вазифа бередә барыннан да мөһимрәк. Бу очракта да төп сүзне, аңлашылганча, баш режиссер әйтә. Ул моны хәл иткәндә, үзенең иҗади амплуасын да исәпкә ала. Әмма аның өстәлендә вариантлар булырга тиеш. Моны инде Ю. Сафиуллин кебек әдәби бүлек мөдирләре тәэмин итәргә бурычлы. Үзе иҗат омтылышы белән янган шәхеснең үрнәге башка авторларга да уңай йогынты ясамый калмый. Сүз бара торган унъеллыкларның атаклы режиссеры М. Сәлимҗанов белән кулга-кул тотышып эшләве нәтиҗәсендә академия исемен йөрткән труппа зур илебездәге театр сәнгате диңгезендәге “Титаник”ларның берсе буларак иркен йөзә, ләкин, бу исемнең оригиналын йөрткән корабльдән аермалы буларак, һәрвакыт хәтәр-хәвефләргә юлыкмыйча йөзүен дәвам итә, куйган максатларына барып ирешә тора.

Ниһаять, 1981 елда талантлы һәм кыю режиссер Дамир Сираҗиев Ю. Сафиуллынның үз әсәре – “Алмазбулат”ны – академия театры сәхнәсенә күтәрә. Әниле-уллы Наилә Гәрәева белән Фәрит Бикчәнтәевнең төп рольләрне бергәләп башкарулары да матур яңалык булып кабул ителгәне бүген дә хәтеремдә. Икенче куелышта әсәр Ф.Бикчәнтәев режиссерлыгында туды. Тамашчы ничә еллар буена бу әсәрдән аерылырга теләмәде, күпләр аны кабат-кабат карады. Шулай итеп, әсәрнең сәхнә тормышы Ю. Сафиуллинны драматург буларак танытуда бер этап булды. Театрның аңа бер-бер артлы мөрәҗәгать итүе, һәр куелышта озын гомерле булуы автор талантының күрсәткече иде.

Бүгенге заманыбыз кешелек тарихы барышында иң кискен һәм хәтәр бер чор. Барлык ирешелгән казанышларны юк итүгә китерелү куркынычы баш өстендә һәрдаим янап тора. Рухи өлкәдәге каршылыкларны һаман үсендереп торучы глобализм дигән афәт тә ахыр килеп шушы һәлакәткә юлыктырырга мөмкин. Монысы да бүген генә пәйда булган нәрсә түгел. Әйтик,

алтмышынчы-җитмешенче елларда безнең ил халыкларын тоташ совет халкы дип аталучы кавемгә әверелдереп, бер телле итеп калдыру дәүләт сәясәте буларак эзлекле тормышка ашырылды. Ю. Сафиуллин исә ул вакытта ук мондый омтылышларга каршы чыкты. Әмма бүген алар тагын да ачыграк булып каршыбызга килеп баса. Хакимиятләр бу теләкләренә җиңел генә кайчан ирешерләр иде? Ч. Айтматов әйткән манкортлык гомуми чынбарлык булып әверелгән очракта, әлбәттә. Манкортлык үткәннәребезне, нәсел-нәсәпләребезне генә түгел, газиз телебезне, моңыбызны да оныттыру нәтиҗәсендә тамыр җәя. Ю. Сафиуллин нәкъ кирәк вакытта әлеге куркыныч турында кисәтте. Халкыбызның Г. Тукай шигыренә башкарыла торган “Туган тел” җырын гимн дәрәҗәсенә күтәреп яңгырату шушы әсәрдән башланды. “Туган тел” хәзергебез һәм киләчәбезнең турында гамьләнүнең нигез ташы – символы булып әверелде. Әлеге хәзинәбезгә зыян килмәгәндә генә халкыбыз үз йөзен, затлылыгын саклап кала алачак. Әсәрнең уңышы барыннан да элек шушы фикерне сәнгатьчә үтемле итеп яңгырата алуда иде. Менә ни өчен без Ю. Сафиуллиннны милләтпәрвәрлеге өчен дә яратабыз.

Шундый гаять мөһим әсәрләрнең икенчесе, әлбәттә, “Идегәй” трагедиясе. Аның тарихыбыздагы бу затны гәүдәләндерергә алынуы үзе бер иҗади кыюлык. Бу эшкә этәргеч бирүче итеп М. Сәлимҗановны санарга кирәк. Нәкъ аның тәкъдиме буенча “Идегәй" эпосына нигезләнеп сәхнә әсәрен язуга конкурс игълан ителә. Һәр эшкә үтә җаваплы, таләпчән килүне гадәт иткән Юныс Габулла улы Идегәй, Туктамыш хан, Аксак Тимер чорларын чагылдырган тарихи мәгълүматлар һәм әлеге халык авыз иҗаты әсәре белән ныклап таныша. Әмма шушы ук эпоска нигезләнеп әле утызынчы елларда Н. Исәнбәт иҗат иткән трагедияне аңлы рәвештә читкә этеп куя. Чөнки ул аның каләменә күпмедер тәэсир итәргә мөмкин иде.

Хәтерлим, Казан университетында әлеге эпосны һәм Ю. Сафиуллин әсәрен өйрәнүгә багышланган диплом эше язылган иде. Яклауга драматургның үзен дә чакырганнар. Шунда табигый бер сорау барлыкка килде: ни өчен М. Сәлимҗанов Нәкый ага Исәнбәт вариантын гына сәхнәләштермәгән? Минем Марсель Хәким улының үзенә дә шулай дип мөрәҗәгать иткәнем булды. Ул үзенең бу очрактагы максатын болайрак аңлатты: “Татар тарихын татар язмавы, үзләрен җиңүче дип санап безнең тарихны бозып язулары, ягъни минем халыкка ачы хакыйкатьне ярып әйтеп бирергә теләвем”

Үткәнгә күз салсак, 1940 елда ТДАТ Н. Исәнбәтнең “Идегәй” трагедиясен сәхнәләштерә. Аны Казанда күрсәтергә дә өлгерәләр. Алай гына да түгел, 1941 елның 30 июнендә Мәскәүдә ачылачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы репертуарына да кертәләр. Әмма шушы көнгә бер атна кала фашистлар Алманиясенең мәкерле һөҗүме нәтиҗәсендә бу вакыйга-бәйрәм булмый кала. Ә 1944 елның 9 августында, “ханнар-феодаллар эпосы” дигән мөһер тагып, “Идегәй” дигән халык әсәре фирка тарафыннан бөтенләй үк тыела. Чөнки ул татарларның көчле дәүләтләр тоткан чорын халык хәтерендә яңартып торуга хезмәт итә торган әсәр. Фирка җитәкчелеге болай уйлый: иң яхшысы – аны бөтенләй әдәбият, рухи мәйданнан алып ташлау. Н. Исәнбәт үз әсәрен утызынчы елларның икенче яртысындагы рухи кысынкылык шартларында язган, эпостан килеп чыга торган төп карашларны ачып бирү мөмкинлегеннән мәхрүм булган. Туксанынчы елларның хөрлеге шартларында иҗат ителгән сәхнә әсәре бернинди сәяси кысалар белән чикләнмичә эшләнә ала иде. Бу шулай булды да. Әйе, “Идегәй” спектакле

Мәскәүгә барып куелды, әмма ул инде яңа чорда – Юныс Сафиуллин әсәре буенча тормышка ашырылды.

Без инде Ю. Сафиуллинның иҗат йөзен тулы ачу максатында аның байтак әсәрләре буенча сүз алып бара алыр идек. Г. Исхакыйның “Зөләйха” әсәре буенча эшләнгән киносценарий, Чечен сугышы китергән фаҗигаләрне гәүдәләндергән “Йөзек һәм хәнҗәр” трагедиясе, М. Галәү дилогиясе буенча иҗат ителгән “Ирдәүкә” пьесасы һәм башка әсәрләрен бер-бер артлы күздән кичергәндә, без, драматургиябез һәм театр сәнгатетбезның олы юлы буена нинди эре, ераклардан күренеп торган маяклар тезеп куючыбыз барлыгын тоеп, зур горурлык хисләре кичерәбез. Шулар янына Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасына нигезләнеп шигырь белән иҗат ителгән “Йосыф һәм Зөләйха” әсәрен дә китереп куйсак, әлеге замандаш каләмдәшебез иҗатының биеклегенә тагын да бер таза ниргә өстәлүен күреп кинәнербез. Аның М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрының талантлы труппасы тарафыннан Казан алып килеп күрсәтелүе безнең тамашачылар өчен зур бер рухи бәйрәм булып әверелде.

Әйе, татар драматургиясе үсешен тәэмин итүче талантлы авторларыбыз арасында Юныс Сафиуллин исеме дә бар, бу – бәхәссез.

**ӘДӘБИЯТ**

Габиди Ә. Көлдерә дә, уйландыра да // Социалистический Татарстан. – 1980. – 24 февраля. – С. 3.

Поварисов С. Әлмәт театры Башкортстанда // Социалистик Татарстан. – 1980. – 9 апрель. – С. 4.

Премьера в передвижном театре // Театральная жизнь. – 1978. – № 17. – С. 37

# ГОМӘР БӘШИРОВ ИҖАТЫНДА МИЛЛИ ТРАДИЦИЯЛӘР («ТУГАН ЯГЫМ – ЯШЕЛ БИШЕК», «ҖИДЕГӘН ЧИШМӘ» ӘСӘРЛӘРЕ МИСАЛЫНДА)

## (NATIONAL TRADITIONS IN THE CREATIVITY OF GUMAR BASHIROV (ON THE EXAMPLE OF THE WORKS «NATIVE LAND - GREEN MY CRADLE», «SEVEN KEYS»))

**Aygul GANIEVA***

**SUMMARY**

Gumer Bashirov is one of the main figures of Tatar prose of the 20th century. Developing and enriching the various techniques of the epic imagery proposed by G. Ibragimov, he threw a bridge to future generations of Tatar writers. The author of the article stresses that in his autobiographical novel "Native land-green my cradle", the writer was one of the first in Tatar Soviet literature to show the bright and beautiful sides of our national past. Received in the literary criticism of the designation of the village encyclopaedia, this work is a successful example of the artistic embodiment of the spirit and inner world of the people. In the novel "Seven keys" an environmental problem is raised. Imbued with boundless love for his native land, nature, people, his spiritual values, this work focuses on highlighting the theme of nature from the standpoint of national ethics. and morality. G. Bashirov in this work places a great place in the national customs and folklore of the Tatar people. G. Bashirov made many efforts to collect the linguistic wealth of the Tatar people. Wrote deep and informative articles on tatar language, philosophy, art, customs and traditions. Plunging into the people's environment, he himself collected, processed and published in the form of collections of the work of oral folk art: tales, anecdotes, sayings. The light of national spiritual wealth, having penetrated into his work, made them more animated and attractive. All this speaks about the nationality and national spirit of the works of the aksakal of our literature of G. Bashirov

Г. Бәширов – XX гасыр сүз сәнгатен, аның да иң саллы, әйдәп баручы тармагын – прозаны тотып торган, совет чоры әдәбиятының төп юнәлешен, йөзен билгеләгән фигураларның берсе. XX йөз башы традицияләрен, аерым алганда Г. Ибраһимовның киң колачлы эпик сурәтләү алымнарын үстереп, баетып, үзеннән алдагы буыннарга тапшыручы күпер ул. Вакыт сынауларын үтеп тә, үз укучысын югалтмавының сәбәбен Д. Заһидуллина «махсус алып барылган интернациональлек дигән гомум тенденцияне кире какмастан, миллилекне саклау ягыннан аның алтын урталыкны таба» белүендә күрә (Заһидуллина, 2015: 223).

Чор проблемаларын чагылдыру ягыннан Т. Галиуллин Г.Бәширов иҗатын икегә бүлеп карый. Беренче дәвердә язучы яңа методның (социалистик реализм А.Г.) таләпләрен бик тырышып үти, әмма шунда да дөньяны үзенчәрәк сурәтли. «Сиваш» белән «Намус» әсәрләре шуның ачык үрнәге. Ул аларда да туган якны, табигатьне, мәхәббәтне һәм кеше күңелендәге кырыслыкны, усаллыкны, миһербансызлыкны сурәтләгәндә, романтик алымнарга, күпертү ысулларына таяна. Әмма катгый кануннардан читкә чыкмый, тәртәгә типми» (Галиуллин, 2003: 28) Галим Г. Бәширов иҗатындагы үзгәрешләр 60 елларның икенче яртысыннан башлануын

* Institute of Language Literature and Art. of G. Ibragimov, Kazan.

билгели. Бу, әлбәттә, шул елларда илдә барлыкка килгән яңарыш җилләре белән дә бәйле. Г. Бәширов «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик повестендә татар совет әдәбиятында беренчеләрдән булып, милли үткәнебезнең якты, матур якларын күрсәтеп бирә. Әдәби тәнкыйтьтә «авыл энциклопедиясе» дигән бәяләмә алган әлеге әсәр – татар халкының рухын, эчке дөньясын сәнгатьчә чагылдырган уңышлы әсәрләрнең берсе.

Повесть авторның туган халкына, яшәгән җирлегенә, табигатенә чиксез мәхәббәт белән сугарылган. Тормышның матди җитешсезлекләре булуга карамастан, авыл баласы табигать кочагында рухи бөтенлектә, табигать белән гармоник мөнәсәбәттә яши. Һәр ел фасылының мавыктыргыч уеннары бар. Менә кышкы кичтә балаларның бөтен дөньяларын онытып чана шуулары: «Инде чәнәшкәнең (кечкенә чана) арты да әллә кайчан каерылып төшеп калган. Киез итек белән бияләйләр дә гел боз гына. Бүтәнне әйткән дә юк, шуып төшкән саен егыла-мәтәлә торгач, чалбарларга тикле сыгып ташлардай булган. Кайткач орыш эләгәсен дә белеп торасың. Шулай да кайтып кына булмый бит. Булмый! Талчыккан аякларны көч-хәл белән атлап, мышкылдап, чәнәшкәләребезне тау башына сөйрибез. Әмма берсенең дә кайтыр исәбе юк. «Тагын бер генә шуыйк инде!..» -диләр. Ләкин ул тагын бер генә булып калмый, ике дә, өч тә, биш тә булып китә…» (Бәширов, 1982: 13).

Чүлмәчлеки – су сибешү– табигать торышына бәйле уен-йола. Җәен озак вакытлар яңгыр яумый торып, корылыкка китсә, ачлык куркынычы яный башлый. Авыл хуҗалыгы өчен корылык аеруча зур фаҗига. Шуңа әлеге уенда балалар гына түгел, олылар да теләп катнаша. Су сибешүне Г. Бәширов мавыктыргыч итеп болай сурәтли: «Йөгердек өйләргә, алдык кем кечкенә чиләк, кем зур чүмеч, киттек чыгып – очраган бер кешене коендырырга! Бала-чагамы ул, апа-җиңгиме – барыбер. Шулай да, кыз-кыркын, йә үзебез кебегрәкләр очраса, күңеллерәк инде анысы. Ул ишек алдына керсә, ишек алдына, өйгә керсә, артыннан өйгә кереп, башыннын ук коендырасың. Китә чыр-чу, китә кагыну, кибенү, башлана юри генә орышу, тиргәү. Шунысы кызык, чыланган кеше никадәр генә кычкырмасын, нинди генә усал сүзләр әйтмәсен, аңа һич исләре китми. Ник дисәң, аның үзенең дә авызы ерылырга тора. Чөнки йоласы шундый, борын-борыннан, бабайлар заманыннан ук шулай килгән. Бу – бер-береңә ачулана торган чак түгел. Бөтенесендә бертөрле борчу. Бөтен илгә яңгыр кирәк, яңгыр! Шундый изге ният белән коендырган кешегә ничек ачуланасың? Ярамый, килешми» (Бәширов, 1982: б. 92).

Г. Бәширов үз әсәрендә табигатьне зур әхлакый-тарихи мәгънәдә, ягъни кешелек буыннарын берләштерүче бербөтен итеп сурәтли. Ул табигать белән бәйле рухи кыйммәтләрнең тирән фәлсәфи мәгънәсен ача, бигрәк тә хәзерге заманда, буыннар чылбыры өзелү куркынычы янаганда, җирдә тормыш дәвам итсен өчен, адәм баласының төп тереклек итү урыны булган табигатьне саклап калырга чакыра.

Билгеле булганча, 60 еллардан җәмгыятьтә экологик проблеманың аерым халыклар өчен милли кризис төсен алуы күзәтелә башлый. Бу мәсьәлә беренчеләрдән булып Г. Бәшировның «Җидегән чишмә» романында күтәрелә. Туган җиргә, табигатькә, халыкка, аның рухи хәзинәләренә чиксез мәхәббәт белән сугарылган әлеге әсәрдә табигатьне милли-әхлакый планда яктыртуга басым ясала.

Зур тизлек белән үсеш алган фән-техника прогрессының җәмгыятькә йогынтысы ике яклы булды. Бер яктан, ул кешегә яшәү өчен уңайлырак матди шартлар тудырса, икенче яктан, аны рухи ярлыландырды. Мондый ярлылану бигрәк тә табигатькә мөнәсәбәттә, аңа торган саен күбрәк зыян китерүдә

күренде. Шул нигездә хасил булган экологик кризис ахыр чиктә аерым халыклар язмышына да кире йогынты ясый. Шушы хакыйкатьне күздә тотып язылган «Җидегән чишмә» романында табигать мәсьәләсенең яктыртылышы тәнкыйтьтә түбәндәгечә бәяләнде: «Мең, миллион еллар буена үз куенында кешеләргә урын һәм тормыш биргән: ашаткан, эчерткән, сокланырга-куанырга җирлек биргән Табигатькә без, XX гасырның соңгы чирегендә яшәүче, көчле техника белән коралланган көчле кешеләр, аңа ничек җавап бирәбез, нинди мөгамәләдә торабыз, аның кочагында нинди гамәлләр кылабыз?! Әсәр менә шул турыда» (Бәширова, 1995 24).

Әсәрдә табигатькә ике төрле караш һәм мөнәсәбәт чагылыш таба. Аларның икесе дә, беренче карашка, халык мәнфәгатьләрен яклый, аның бәхетле киләчәген кайгырта кебек. Шул ук вакытта алар арасында көрәш бара. Беренче караш тормышның күбрәк матди ягын күздә тота, ягъни ул халыкның көнкүрешен яхшырту, хезмәт кешесенә уңайлырак эш шартлары тудыру турында уйлана. Икенче караш исә беренче планга табигый байлыкларның рухи-эстетик кыйммәтен ачуны чыгара. Безнең заманда табигатьнең кешелек яшәешендә тәкъдири әһәмиятле роль уйнавын аңламыйча аңа җавапсыз, битараф һәм хәтта саксыз карауның көчәйгәннән-көчәя баруына нык борчылган әдип үзенең әсәрендә шушы мәсьәләгә аеруча басым ясый.

Беренче якның кулында көчле техника, производство, хакимият. Икенче якта исә халыкның киләчәк алдында җаваплылыгы, халыкның үткәненә илтифат, туган җиренә мәхәббәте. Кем җиңәр? Кайсы караш дөрес һәм тормышчанрак? Автор шул сорауга җавап эзли, эзләнә, уйлана, укучыны да бәхәскә чакыра.

Гомумән, әсәрдә табигатькә мөнәсәбәт геройларга бәя бирүдә төп факторларның берсенә әверелә. Шуннан чыгып, персонажларны да өч төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Аларның беренчесенә табигать сөючеләр, аның киләчәге өчен борчылучы туган җирнең чын патриотлары керә. Алар – яшь егет Гайнан, умартачы, сугыш ветераны Минһаҗ карт, сыер савучылар Җәүһәрия, Язидә, район газетасы редакторы Дәрҗия, партоешма җитәкчесе Идрис, язучы Камил Дусаев. Икенче төркем бүгенге көн белән генә яшәүче, табигатьне бары матди чыганак итеп кенә карауччы Чурмантаевтан, авыл советы рәисе Фәсхиевтән тора.

Өченче төркемгә кибетче Равил, агроном Фәйрүзә, комсомол секретаре Дилбәр керә. Алар табигатьне яраталар, әмма аны саклау өчен берни дә эшләмиләр. Тургайлар кырылганга, чишмәләрне җимергәнгә дә исләре китми аларның. Автор ваемсызлык, битарафлыкның яшьләргә хас булуына ачына.

Бүгенге авыл җирендә киң таралган тагын бер тискәре күренеш итеп язучы эчкечелекне күрсәтә. Безнең ата-бабаларыбыз беркайчан да хәмерне өнәмәгәннәр. Бу турыда автор үзенең «Туган ягым – яшел бишек» повестенда да яза. Бәшир ага, сыерлары үлеп, тормыш итүләре авырая башлагач, Арчадан Иван исемле урыс сәүдәгәренә үзенең келәтен биреп торырга була. Сатучы килеп, эш башлаганчы ук, авыл агайлары җыелып киләләр. Алар кибетче аракы, хәмер кебек нәрсәләр сатачакмы, шуны белергә телиләр. Кибетче, әлбәттә, нәрсә керемле, шуны сатарга тырыша. Аракы аңа күп табыш китерәчәк. Агайларның сүзен ул уенга алырга теләсә дә, картларның карары нык була. Алар аракыга дин тыйганга гына каршы тормыйлар. «Знаш, приятель, «языгы казык башына», ди безнең татар. Водка пить тек нихораша будет, бедный много будет, бальной многа будет. Вот чом дила!» (2, б. 368) –

дип аңлата Иванга Галимҗан абзый. Сатучы ризалашмыйча булдыра алмый, чөнки агайлар җәмәгать җыены җыеп, халык сүзен кистереп әйтәләр: «Яңасала кибетләрендә бертөрле эчемлек тә сатмаска! Исерткеч сата торган булса, кибет ачтырмаска!» Иван күнә, «чөнки җәмәгать җыены рөхсәт итмәсә, волостьта патент бирмиләр икән» (Бәширов, 1982: 369).

«Җидегән чишмә»дә исә аракының халык тормышына тирән үтеп керүе, аның аркасында җитди күңелсезлекләр килеп чыгуы тасвирлана. Бу Фәрит – Язидә мөнәсәбәтендә ачык чагыла. Фәрит начар егет булмаса да, хәмер белән дуслыгы бар. Шуңа алар ярәшкән көнне Минһаҗ карт кистереп әйтә: «Монда чит кеше юк, кем, Фәрит туган, баштан ук турысын әйтеп сөйләшик. Соңыннан үпкәләшерлек булмасын! Сиңа ялган, безгә чын, менә икмәк алды, моңарчы нәселебездә эчкече булмады, йортыбызга аракы заты кермәде. Моннан соң да язмасын! Күреп торабыз лабаса! Көлле явызлыклар эчкечелектән башлана, җыен сыек башлы, чиле-пешле гарип балалар исеректән туа. Менә күреп карыйк, беравык бер-беребезне сынашыйк. Әгәренки шуңа түзәсең икән, бик хуп. Гомергә бәхетле булыгыз. Инде шуңарга көчең җитми икән, бигайбә, ул чагында, ай-һай, без хәер-фатиха бирә алмыйбыз. Юк!» (Бәширов, 1983: 225). Фәрит сынауны үтә алмый. Ул исереп кенә калмый, салган баштан, Язидәгә үч итеп, халыкның мәңге яшәгән чишмәләрен минут эчендә юкка чыгара: бульдозеры белән җимерә, сыта, таптый.

Г. Бәширов халыкның тел хәзинәләрен барлауга да зур хезмәт куя. Татар теленә, фәлсәфәсенә, сәнгатенә, гореф-гадәтләренә кагылышлы тирән эчтәлекле мәкаләләр яза. Авыз иҗаты әсәрләрен: мәзәкләрен, мәкал-әйтемнәрен, әкиятләрен халык арасына чыгып үзе җыя, туплап, җыентыклар бастыра. Милли рухи хәзинәбезнең якты нуры аның үз әсәрләренә дә үтеп, аларны тагы да җанлырак, күркәмрәк итә. Болар барысы да әдәбият аксакалы булган Г. Бәширов иҗатының халыкчанлыгы, миллилеге турында сөйли.

### ӘДӘБИЯТ

Бәширов Г. Җидегән чишмә: Роман // Әсәрләр: 4 томда: 3т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 422 б.

Бәширов Г. Туган ягым – яшел бишек: Повесть // Әсәрләр: 4 томда: 2т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. – 453 б.

Бәширова И. Җидегән чишмә моңы…/ Г. Бәшировның иҗат лабораториясеннән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995 – 144 б.

Галиуллин Т. Гомәр Бәширов иҗатында чор проблемаларының чагылышы // Шәхесне гасырлар тудыра. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. –192 б.

Заһидуллина Д. Гомәр Бәширов прозасы: әдәбиятта милли дөнья сурәте // 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 383 б.

# ӘМИРХАН ЕНИКИНЕҢ «ГӨЛӘНДӘМ ТУТАШ ХАТИРӘСЕ» РОМАНТИК ПОВЕСТЕНДА МИЛЛИ ЯШӘЕШ КАРТИНАСЫ

## (NATIONAL PICTURE OF THE WORLD IN THE ROMANTIC NOVEL AMIRKHAN ENIKI «MEMORIES GULENDAM»)

**Gulfia GAYNYLLINA***

**SUMMARY**

The great tatar classic Amirkhan Eniki wrote a story in 1975, in which the story of extraordinary love intertwines with the historical events of the country's life in the early twentieth century. According to scientists, in romanticism divine and high are in the first place. Depicting the story of the composer's first love, Salih Saidashev Amirkhan Eniki refers to the romantic principles of perception of the world around him. The story of a writer "Memories Gulendam" continues the tradition of classical romanticism in the Tatar prose. In the work, the outside world is refracted in the internal, psychological. This is a description of the depths of the human soul. A romantic story is on behalf of the young girls Gulendam, who fell in love with a young music teacher, the first professional tatar composer Salih Saidashev and author, recreating an idealized picture of the world. Symbolization occupies a Central place in the structure of the story, it becomes a method of detailing, and a way to assess the reality or psychological state of the heroine. Against the backdrop of an emotionally intense stream of feelings presented in the storyline and philosophy of human nature, the story sounds the motives of a return to national origins. Romantic motives (the cult music, the cult of love) creating a national picture of the world. Thus, the idealized picture of the life of tatar intelligentsia of the early twentieth century is recreated.

XX гасырның 70-80 нче елларында Ә.Еники милли яшәеш фәлсәфәсен үз асылыңны табу, буыннарга тапшыра алу турындагы эчтәлек аша сөйләп бирә. “Гөләндәм туташ хатирәсе” (февраль, 1975) романтик повестенда “тарихи материал психологик эчтәлекле мәхәббәт турында сөйләүдә эретелә” (Заһидуллина, 2015: 202). Әсәр эчтәлегенә субъектив образ – Гөләндәм исемле туташ алып керә, повесть хикәяләүченең мәхәббәт тарихын сөйләвенә корылган. Автор романтик алымнар ярдәмендә үкенечле мәхәббәт тарихын сөйләп чыга.

Әсәргә алып керү өчен хикәяләүче чит/үз бинар оппозициясе оештыра, аны үз дөньясына яшеренергә мәҗбүр ителгән кызның кичерешләр тарихы кебек алып бара. Романтик кичерешләр сызыгы уйланулар вакыты кебек аңланган кич вакытын һәм моңсу шомлы көз фасылын символлаштыру аша башланып китә. Мифологиядә дулкынлану, рухи таяныч тоймау кебек укылган җил образы яңгыр образы (хакыйкать тамчысы мәгънәсендә) белән янәшәлектә тормыш-яшәеш тәртибенә төшенергә теләгән кешенең эзләнүләре турындагы эчтәлеккә алып керә. “Сәер тавышлар” – “дөберди, кыштырдый, ыңгыраша” – Гөләндәмнең бу чынбарлыктан куркуын көчәйтеп күрсәтү юлы кебек укыла: “Мин, куркынып, укый торган китабымнан аерылып, колак салып тора башлыйм” (Еники, 2002: 238). Кичерешләр рухи ныклыкка ирешә алмаган очракта (“хәерсез усал җил”) һичшиксез кайгы булачагын

---

* Candidate of Philology Sciences, Associate Prof., Kazan Federal University, Kazan.

(“тыштагы каен ыңгыраша”) искәртү белән дәвам итә. Күңел кичерешләре таяныч тоймаганга курку кебек тамгалана (өйнең стенасына шәрә ботаклар бәрелә-сугыла тырнаша). Интертекстуальлек (С.Җәләлнең “Дим буенда”, “На заре туманной юности”, “Яз да була”, “Туган тел”, Хәмдия”, “Казан сөлгесе, “Эрбет”, “Тәфтиләү”, “Агыйдел каты ага”, “Сибелә чәчәк” җырлары, К.Тинчуринның “Соңгы сәлам” драмасы, “Сакмар” көе, “Тукай маршы, “Мәдинәкәй” җыры, “Аккош маршы” ) әсәрнең буеннан-буена укучыны шул эчтәлек дулкынына көйләү юлы булып тора.

Кыз үзе өчен өр-яңа чынбарлык белән танышканда (“күзгә күренмәс диварга килеп бәрелгәндә”) романтик табигатьле самими бала хисләре белән яши (“өстендә гади генә ситсы күлмәк, йомшак чүәк” (Еники, 2002: 239)), үзен уңайсыз хис итә (“битләре кинәт , ут капкандай , кызыша башлый”, “чәч толымнары тизрәк артка күчерә” (Еники, 2002: 239)). Вакыйгалар барышында Салихның Гөләндәмне әлеге чынбарлыкка алып керүе тасвирлана (тар баскычтан залга төшә), кичерешләр сызыгы беренче романтик саф хисләр тарихын сөйләү кебек алып барыла. “Зәңгәр күзле, мәрмәрдәй ак маңгайлы” ачык йөзле, “акыл сатарга, күп сөйләргә яратмый торган” (Еники, 2002: 239) Салих Сәйдәшев образы да романтик яссылыкта эшләнгән образ. Автор бөек татар композиторы образы ярдәмендә камил рухлы, җитди карашлы татар егете кичерешләрен тергезә (аның җомга көнне изге эшләр белән шөгыльләнүе). Иң элек кыз белән танышу укучыны шул рух дөньясына алып керү максатына хезмәт итә. Беренче романсны уйнаган кызга егет бәясе тормыш-яшәешкә дөрес караш тәрбияләнмәгән кешегә илаһи чынбарлык бәясе кебек кабул ителә. Әсәр кызның гармониягә ирешү юлы кебек укыла.

Гармониягә ирешү өчен үз рухыңнан үз телеңне эзләп табу таләп ителә (Салих кыздан татарча уйнавын сорый). Телнең иҗтимагый вазифасын алга куеп, татарча сөйләшүне кирәксенмәгән укучыга иң тәүдә шул хакыйкать җиткерелә. Беренче бүлектә гашыйк кызның кичерешләренә “нәфислеккә омтылыш” теләге салына. Татар кешесенең гармониягә юлы “нәфислеккә омтылыштан” башлана, нәфислек кешенең ана телендә уйлау, сөйләшү әдәбендә чагылыш таба, ди автор: “ ...кулың белән уйнаганны күңелең белән ишетергә генә кирәк” (Еники, 2002: 247). Ак, нәфис, җыйнак куллы Салихның уйнап күрсәткән беренче көе “Туган тел” булу (беренче исеме “Анам кабере янында” икәнлеге махсус искәртелә) очраклы түгел. Ифрат әдәпле, ихлас күңелле кыз Салих эшкәртүендәге “гади дә, таныш та бу көйне бозмыйча-нитмичә уйнап чыга” (Еники, 2002: 248). Кыз үз рухына хас нәфислекне гаҗәпләнеп, сокланып, сөенеп ача, соңрак йөрәктә туган табигыйлекккә сихерләнә, кодрәтле моң көчен – халык зарын, ачы язмышын тоя.

Беренче “учлап карарга теләгән мамыктай, коры, таралып торган кар” (Еники, 2002: 254) – кызның үз рухын эзләве, ләкин әле “үзең теләгәнчә, тойганча уйнау” (Еники, 2002: 255) – әлеге рухның гадәткә кергән гамәлләр белән ныгытылмаганлыгы (карның укмашмавы), ягъни чит/үз бинар оппозициясенең юкка чыга башлавы турында хәбәр итә (шәл деталенә салынган эчтәлек).

Повестьның эчке музыкасы эмоциональ эчтәлек хасил итә. Салихның үз хисләрен әйтеп бирү өлеше (”Агыйдел каты ага” тексты) яңа чынбарлыкка керер өчен кызда кыюлык, сайлаган юлга ышаныч тәрбияләү кирәклеге турында сөйли: “Сез каты аккан Агыйделне дә җиңел кичәрсез” (Еники, 2002: 259). Көрешүгә чакыруы – кыз өчен гайре табигый вакыйга – гашыйк Гөләндәмнең хисләрен киеренкеләндерә, асылда кыюлык һәм ышаныч өсти.

Кыздагы яңа халәт – сер көтү – яңа чынбарлыкка керүне тагын да ашыктыра. Автор Салих сөйләгән сурәтләр аша кешедәге уй-гамәл гармониясе сурәтен ясый. Татар кешесендә туган гармония – аның бәхетле-тигез тормышының матур гадәтләре, эчке моңы, ди автор. Гамәлдә шуны тергезмичә торып татар кешесе рухи ныклыкка ирешә алмый. Шул моң татарның хөрлеге, аның җыры (“Сибелә чәчәк” тексты), даими күңел халәте.

Кызларның театрга киенүләре үзләрендә яшәгән әти-әниләре тәрбиялләгән тарлыктан милли рух табылган хөрлеккә чыгу юлына басулары кебек укыла.

Гөләндәмнең эчке, күңел пространствосы, сюжет ситуацияләрендә ачыла торган холык сыйфатлары белән иске тормышның реаль урын контурлары бәрелешә. Кызның “гарип булса да, кызгану хисе уятмый торган, мескенлектән бик өстен булган” Ф.Әмирхан белән очрашуы кешелек горурлыгы турында искәртүче тагын бер вакыйга. Татар яшьләре оештырган кичәдә катнашу кызның кыюсыз, куркак чынбарлыгына яңа эчтәлек өсти. Салихка мәхәббәте аша Гөләндәм тагын да ачыла, яктыра төшә, “Соңгы сәлам” спектаклен тоюы шул хакта сөйли: “Ольга барысын да әтиләре белән уйлашып, киңәшеп эшли! Нинди мәхәббәт була соң инде бу?!” (Еники, 2002: 284). Укучы әти-әнисе тозагында яшәргә күнеккән Гөләндәм күңелендә туган хис үзгәрешен тоя, ләкин автор Вахит-Ольга язмышының кабатланачагын Салих сүзләре белән искәртә: “Бигрәк тә дин һәм милләт аермасы гашыйкларны әнә шундый фаҗигагә китерә дә... Әйе, авыр фаҗига, тамыры бик тирән әле” (Еники, 2002: 284).

Кызның ябык пространстводан ачык просранствога омтылышын пейзаж бирелеше хасил итә: “Тышта галәмәт буран икән ләбаса! Шул дөньяга сыя алмыйча котырына, имеш! Буран гаепле моңа, буран шулай саташтыра, буран җөтен нәрсәне йә бик якынайта, йә бик еракка алып китә. Менә буран басылгач, барысы да үз урынына кайтыр, һәм мин дә бәлки бервакыт чын дөресен генә белермен. Чын дөресен?! Әмма кирәкме соң ул “чын дөресен генә” белү, кирәкме? Нәрсә китерер ул миңа – сөенечме, әллә көенечме?” (Еники, 2002: 264) Үзе яраткан “Сакмар” көен уйнаганда кызның әтисенә эчке эндәшүендә дә шул укыла: “Зифа талдай үсеп җиткән кызыңның үз бәхетен үзе сайларга хакы юкмыни, әти, җаным, бәгърем?!” (Еники, 2002: 264) Кызның елавы – героиняның иркенлеккә таба хәрәкәте, хис үзгәреше, җан сызлавы ул. “Буранлы көн” кызга юл ачучы Сабираның “бик кадерле, бик яшерен серен фаш итү” белән тәгәлләнә.

Салихның алдагы уйнаган көе беренче хәлфәсе З.Яруллинның “Тукай маршы” булу очраклы түгел. Салихның хәлфәсе турында “бернинди ясалу-кыланусыз сөйләп чыгуы” кызны сокландыра, башка дулкынга көйли, Гөләндәм Салихның Тукайны күрү-күрмәве белән кызыксына. Шул урында Салих исеменнән автор кеше күңеле омтылырга тиеш үзгә халәт – “халык күңелендә мәңге яши башлау” омтылышы турында әйтә: “Күпме уй-хис бу музыкада! Олы хәсрәттән тирән әрнү бар, хәтта тәкатьсез үксү дә ишетелеп кала, әмма шул ук вакытта ул кешенең рухын төшерми, өметсезләндерми, киресенчә, аны үстерә, дәртләндерә, гүя зур-зур эшләргә канатландыра!.. Ихлас! Ә менә бу җирендә – тыңлагыз әле, тыңлагыз” Нindидер бер тантаналы горурлык яңгырый түгелме соң?! Тукай өчен, Тукайны тудырган халык өчен горурлык – ишетәсезме зез шуны?” (Еники, 2002: 248) Димәк, үз халкы белән горурлану хисләре һәр кешенең күңел таләбе, үз асылын табуга, тануга юлы икән.

Күпкатламлылыкка ирешү максатында Ә.Еники пейзаж, романтик шәркый алымнарга, сүз-сурәтләргә мөрәҗәгать итә. Милли проблематиканы иҗтимагый мотивлаштыру әсәрдә пейзаж бирелешенә салына, "чыкылдап торган татар оясы Печән базарында" – "Евангилистовский белән Захарьевский чатында зур гына ак чиркәү, вак кына мәчетләр" шул эчтәлекне укырга әзерли. Салихның чиркәү янына җыелган гарип-гораба саилчеләргә карап торуы авторның укучысы ярдәмендә чынбарлыкка бәясе кебек кебек укыла. Кыз белән егет барган Болак күпере – авторның Салих ярдәмендә укучысын яңа милли чынбарлыкка таба алып бару юлы. Кеше гармониягә омтылганда билгеле бер көй дулкынына көйләнә, шул көй аның үз-үзе белән гармониягә ирешүен кичәйтә, ныгыта, ди автор: "Тик безнең мәчетләр генә музыкадан мәхрүм. Шәригать дигән нәрсә мәчеткә курай белән сорнайны гына керткән булса да, дин әһелләре музыкага бу кадәр тискәре карамаслар иде. Ә шуның аркасында без күпме артта калдык". Азан көенең мәгънәсен бирү аша автор кешенең бу дөньядагы тормышына әһәмият бирергә тиешлеген тамгалый кебек: "Гаҗәп сагышлы, моңлы ишетелә шул чакта кичке азан! Гүя фани дөньядан аера ул сине, уйлар, өметләр – барысы да бик кечерәеп кала. Тик соңыннан гына бик ямансу булып китә, тизрәк үзебезнең шул гөнаһлы дөньяга әйләнеп кайтасы килә... Дөнья кызыклырак бит, Гөләндәм!" (Еники, 2002: 270)

Гөләндәмнең Фәйзи Биккинин, Мансур Мозаффаров, Солтан Габәши, Кәрим Тинчуриннар белән танышуы – Салих чакырган хөр рухлы, матур чынбарлыкка аяк атлавы ул. "Шәрык кичәсенә әзерләнү, кичәдәге чыгышлар кызга бу рухны бик кын итәргә, яратырга мөмкинлек тудыралар. Салих белән башкарган "Мәдинәкәй" җыры – мәхәббәт көче, аның башкаларга тәэсире турында сөйли. Шул вакыйгадан соң Салихның Гөләндәмгә "иң саф, иң мөкатдәс" хисләре әйтелүе очраклы түгел.

Чит/үз каршылыгын үтә баручы кызның курку белән тулы дөньясы ачыла, эчке калтырану аркасында тән авыруы кичергәннән соң, кыз башка чынбарлыкка күчкәнлеген аңлый: "Инде менә күзләрем ачылуга гаҗәеп дөнья үзенең кояшы, тәрәзә башында гөрләгән күгәрченнәре, әллә каян гына килгән серле өннәре, гел алышынып торган төс-бизәкләре, онытылмаган хатирәләре, сүнмәс өметләре белән әкрен генә миңа да кайта башлады" (Еники, 2002: 342). Укучы кызның "офыкта кабынган бердәнбер йолдызын" табуын – үзен, үз нәфислеген, матурлыгын тануын тоеп ала.

"Көтү, ышанып, сагынып көтүне кызлар эше" дип инанган Гөләндәм әнисе тәкъдим иткән чынбарлыкка – утарга "затлы күлмәкләренең берсен дә алмаска" – яңа затлы чынбарлыгына хыянәт итмәскә карар кыла. Идел-чикне кичкәндә кыз шул яңа чынбарлык алдында сынала. Салих белән очрашу, шул көйләр серенә уралу, мәхәббәтнең көчен тою – Гөләндәм-Гөлгенәне бәхетле итә, ышандыра. Ләкин горур-сабыр Салихның эчке рухи ныклыгы (утарга барудан баш тартуы) Гөләндәмгә аңлашылмый, ягъни кызда ачылган гүзәллек әле үзен сакларлык булып ныгымаган, горур-сабыр рух гамәлләр белән гадәткә кермәгән. Салих аерылганда уйнаган "Аккош маршы" укучыга шул эчтәлекне әйтеп бирә.

Гөләндәмнең Газизгә кияүгә чыгарга каршылык күрсәтергә тырышуы – беренче зур сыналуы. Салихның моңа каршы җавабында "мәхәббәт кенә түгел, уртак теләкләр дә бәйләргә тиешлеге" автор карашы кебек тамгалана. Ә.Еники "бәхеткә илтергә тиешле юл" – кешенең үз көен, рухын, ахыр килеп, матурлык тудыра ала торган гамәлен табу дип күрсәтә.

“Европачарак киенергә ярата торган, Сембердә туып үскән” сабыр гына, ярашырга күнеккән Гөләндәмнең әнисе һәм “күп очракта әнисе белән килешергә мәҗбүр” әтисе “хатын-кызның мәхәббәте ул күп вакытта ир-ат мәхәббәтенә җавап рәвешендә туа” дип буйсынуга көйләнгән чынбарлыкны яклаучылар итеп тәкъдим ителә. Шул чынбарлыкта тәрбия алган, шул дулкынга көйләнгән Гөләндәмгә, билгеле, зур сынаулар үтәсе әле, Салихка китәргә җыенган кызның “әти-әнием ишетеп-күреп яталар кебек тоелды өзгәләнеп торуымны” дип автор аны куркуын, кире уйлавын нигезли. “Рухы сынган, тәкъдиренә буйсынган, язмышы белән килешкән” чит дөньяга кайтып утырган кызны гомерлек үкенеч көтә. Эпилогка урнаштырылган автор сүзләре шул хакта. Ә Еники, кеше бары үз хисләрен яклый алса, үз рухына туры килмәгән чынбарлыкка каршы төшә алса гына, гармониягә ирешә, үзен бу дөньяда хөр һәм бәхетле хис итә, ди.

Ә.Еникинең романтик фикерләүгә нигезләнгән “Гөләндәм туташ хатирәсе” повесте – милли нигезләргә кайту дәвере татар прозасының уңышы, югарылыгы, дәрәҗәсе. Тәэсирлелек, табигатьне яки тышкы дөньяны, психологик кичерешләрне детальләштерү, текстларның эчке көе, музыкальлеге, яңгырашның матурлыгы һәм камиллеге автор стиленең таныла торган сыйфатларына әверелә.

**ӘДӘБИЯТ**

Еники Ә. Гөләндәм туташ хатирәсе / Әсәрләр. 5 томда. 3 том. Повестьлар. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2002. – Б.237-399.

Заһидуллина Д.Ф.1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр. Монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 383б.

# ТАТАР АНТРОПОНИМНАРЫНЫҢ СӨЙЛӘМ ТЕЛЕНДӘ КУЛЛАНЫЛЫШЫ[4]

## (FUNCTIONING OF THE TATAR ANTHROPONYMS IN COLLOQUIAL SPEECH)

**Gulshat GALIULLINA[*]**

**SUMMARY**

The article shows the specificity of functioning antroponimos Tatar language in contemporary speech. The authors emphasize the basic phonetic changes, which led to a variation of personal names in the spoken language. Variants of anthroponyms initially appear in colloquial speech, then are reflected in the literary language.

The appearance of phonetic variants is associated not only with intralinguistic factors. Phonetic virants of anthroponyms arise under the influence of extralinguistic factors. Among them, the most important are the bilingual environment, psychological features and fashion for names.

Телнең иҗтимагый күренеш булуы гомуми тел белеменең төп нигезләмәләреннән берсе, ягъни тел бары тик бергә тупланып, үзара төрле мөнәсәбәтләрдә булган кешеләр арасында гына яши, димәк ул җәмгыятьтә генә барлыкка килә һәм яши ала дигән сүз. Җәмгыятьнең асылы исә иҗтимагый үсеш, тарихи вакыйгаларга бәйле үзгәреш кичерүеннән гыйбарәт, аның белән бергә тел дә үзгәрешләргә дучар булып тора, ягъни тел дә, җәмгыятьнең аерылгысыз һәм иң мөһим элементы буларак, статик түгел, ә динамик табигатьле. Тарихи рәвештә кешелек җәмгыяте төрле телдә аралаша, аңлаша торган кабилә, халыкларга бүленеп корылган һәм һәр тел билгеле бер кануннарга, кагыйдәләргә буйсынып яши. Әлеге кануннар җыелмасы тел белемендә *норма* төшенчәсе белән билгеләнә. Норма – ул кануни рәвештә гомум кабул ителгән мәҗбүри тәртип. Бер генә тел дә гомум кабул ителгән нормадан башка яши алмый, норма – һәр тел яшәешенең төп шарты һәм нигезе. Бу хакта француз тел галиме, структурализм тарафдары А. Мартине болай дигән: “Әгәр дә даими рәвештә тел шартларын саклауга юнәлтелгән иҗтимагый йогынты башкарылып тормаса һәм үзара аңлашу өчен зарур булган өзлексез регламентлар булмаса, һәр кешенең аерым теле тиз “бозылыр” иде (ягъни аңлашылмаслыкка әйләнер иде). Без башкалар безне аңласын өчен дөрес сөйләшәбез” (Мартине, 1960 : 62-63).

Лингвистик аспекттан чыгып караганда, *норма* төшенчәсенә түбәндәгечә аңлатма бирелә: тел элементларының (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә) бертөрле гомум кабул ителгән кулланылышы (Князев, 2005: 227).

Тел структурасына бәйле рәвештә тел белемендә норма берничә төргә бүлеп өйрәнелә: орфографик норма, орфоэпик норма, лексик норма, морфологик норма, синтаксик норма, стилистик норма, пунктуацион нормалар.

Безнең тикшеренү объекты – хәзерге татар сөйләм теле. Димәк, әлеге язмада игътибарга орфоэпик норма алына. Орфоэпия – ул телнең әйтелеш нормаларын тасвирлау (Сәлимов, 2004: 3), әйтелеш нормасы исә сөйләмнең

---

[4] Хезмәт № 17-14-16012 фәнни проект кысасында РФФИ һәм Татарстан Республикасының финанс ярдәме белән башкарылды.

[*] Prof., Dr., Kazan Federal University, Kazan.

әдәби телгә тәңгәл булуы дигән сүз. Моннан чыгып, орфоэпик норма – сүзләрне һәм басымны дөрес әйтү кагыйдәләре булып чыга.

Тикшеренүебезнең максаты – хәзерге татар сөйләм телендә антропонимнар әйтелешендәге үзенчәлекләрне ачыклау, аларның норматив һәм фонетик вариантларын өйрәнү. Бу юнәлештә антропонимнарны тикшерү аерым әһәмияткә ия дип саныйбыз, чөнки хәзерге сөйләмдә барган фонетик үзенчәлекләр, кеше исемнәренең сөйләмдә иң еш телгә алына торган берәмлекләр икәнен исәпкә алсак, беренче чиратта, аларда чагылыш таба. Әлеге мәкаләдә без әдәби норма һәм норма вариантлылыгын хәзерге татар сөйләмендә кулланыла торган антропонимнар материалында карыйбыз.

Без, норма дигәндә, әдәби телне күздә тотабыз. И.Б. Бәширова билгеләвенчә: “һәр әдәби тел үзенең дифференциаль билгеләре белән характерлана” (Бәширова, 2009: 52). Аларга галимә традициялелек, диалектлардан өстен булу, эшкәртелгән булу, норманың булуы, норма вариативлыгы, функциональ-стилистик вариативлыкны кертә.

Норманың булуын, тел белгечләре фикеренчә, ике фундаменталь үзенчәлек хасил итә: вариантлар булуы һәм булган вариантларны бәяләү (Князев, 2005: 227).

Вариантлар булу, үз чиратында, теге яки бу әйтелешне сайлау мөмкинлеге булу дигән сүз. Мәшһүр галимәбез Ф. Сафиуллина хезмәтендәге моңа нисбәтле юллар тикшеренүебез өчен зур әһәмияткә ия: “Тел дә, сөйләм дә иҗтимагый табигатькә ия, ләкин аралашу процессында сөйләм индивидуаль форма ала. Димәк, тел сөйләмдә индивидуаль формада чагылыш таба, һәр кеше телнең гомуми системасыннан үзенә кирәкне сайлап ала, билгеле бер күләмдә аны үзгәртә, вариантлар таба” (Сафиуллина, 2001: 8).

Вариантлылык телнең фундаменталь үзенчәлекләреннән санала һәм ул тел берәмлекләренең барысы өчен дә хас күренеш. Вариантлылык дигәндә, тел берәмлекләренең төрлечә бирелеше,модификациясе, тел нормасыннан читләшүе күздә тотыла. Антропонимик системада вариантлылык башка төр берәмлекләргә караганда киңрәк таралыш тапкан. А.В. Суперанская билгеләвенчә, вариантлылык ялгызлык исемнәренең асылына салынган. Бу аларның апеллятив, төшенчә белән бәйләнеше көчсез булганлыктан һәм телнең мөмкинлекләренә (бер үк фактларны, күренеш һәммөнәсәбәтләрне төрлечә бирү ысуллары) бәйле барлыкка килә (Суперанская, 1969: 171).

Татар исемнәрендәге вариантлылыкның иң киң таралган төре, , фонетик вариантлылык санала. Ул графикага бәйле барлыкка килә (Татар лексикологиясе, 2017: 85).

Без хәзерге сөйләмдә татар антропонимнарының кулланылышын тикшерү барышында исемнәрнең телдә яшәп килгән фонетик вариантларын игътибарга алып эш иттек. Әлбәттә, һәр исемнең дә варианты булмаска да мөмкин, кайбер исемнәр телдә бердәнбер формада кулланылып килә, бу, нигездә, төрки-татар исемнәренә карый торган үзенчәлек дигән нәтиҗәгә килдек. Мәсәлән: *Айсылу, Таңсылу, Илсөя, Илсылу, Чулпан, Арслан*.

Хәзерге көндә кулланылышта булган татар исемнәренең билгеле бер өлешен алынма исемнәр тәшкил итә, гәрчә соңгы елларда борынгы төрки-татар исемнәрен күбрәк кушу тенденциясе күзәтелсә дә. Татар телендә алынма сүзләрне язуда график принципка нигезләнеп куллану кабул ителгән, әмма сөйләмдә бу кагыйдә еш кына сакланмый һәм алынма исемнәрнең татарчалаштырылган вариантлары хасил була. Бу, беренче чиратта,

оригинал исем-атамаларны телебезнең төп законы булган сингармонизм законына буйсындыру һәм басымның соңгы иҗеккә куелуы белән билгеләнә. Мисал өчен: *Рали'на – Рәлинә', Ди'на – Динә', Фле'ра/Флю'ра – Флүрә', Альми'ра - Әлмирә', Ками'лла - Камилә', Рифа' – Рифә', Зари'на – Зәринә', Рами'л – Рәми'л, Мали'к – Мәли'к, Альфре'д - Әлфри'д* һ.б.

Икенче төркем исемнәрнең вариант формалары барлыкка килүе тартык авазларның чиратлашуы күренеше белән аңлатыла: *Фәнзия – Фәнҗия, Илүзә – Илүсә, Рифгать – Рифкать, Нәкыйф – Нәкыйп, Гаптрахим – Габд(е)рәхим, Әсгать – Әсхәт.*

Өченче төркем исемнәрнең вариантлары сузык авазлар чиратлашуы нәтиҗәсендә барлыкка килә: *Замирә' - Зәмирә', Розалия' – Рузалия', Резеда' – Резидә' - Ризидә', Эльми'ра – Ильми'ра, Земфи'ра - Зимфи'ра, Фоа'т - Фуа'т, Нури' – Нуры'й, Лена'р – Лина'р, Фердина'нд – Фирдина'нд, Рафаэ'ль – Рафаи'л*.

Исем вариантларының дүртенче төркемен исем составындагы бер авазның төшеп калуы барлыкка китерә: *Данияр – Данир, Фәһим – Фәим, Рәмзил – Рәмзи, Рәмил – Рәми.*

Шулай ук тикшеренү барышында ачыкланган түбәндәге үзенчәлек игътибарга лаек, ул экстралингвистик факторлар белән билгеләнгән дип саныйбыз: алынма исемнәрне сингармонизм законы таләбенә буйсындырып һәм басымны соңгы иҗеккә күчереп “татарчалаштыру”, нигездә, олы һәм урта буын вәкилләрендә күзәтелсә, яшь буын вәкилләрендә алынма, аеруча рус теле аша чит телләрдән кергән исемнәрне оригиналга якын рәвештә куллану тенденциясе өстенлек итә, мисал өчен: *Зарина, Алина, Динара, Залия, Адель, Альберт, Рафаэль, Аскар* һ.б. Безнеңчә, бу билгеле бер дәрәҗәдә дөньякүләм глобальләшү күренеше тәэсире булып тора, шул ук вакытта хәзерге татар яшьләренең күбесе билингв шәхес булуы белән, күпчелегенең чит телләрне, аеруча Европа телләрен өйрәнүе, ирекле сөйләшер дәрәҗәдә белүе белән аңлатыла.

Хәзерге сөйләм телендә татар антропонимнарының татар орфоэпик нормаларына мөнәсәбәтле кулланылышы түбәндәге тезисларда чагыла:

1) бер яктан, төрки-татар чыгышлы исемнәрнең барысы диярлек һәм алынма исемнәрнең күпчелеге татар орфоэпиясенең иң төп кануны булган сингармонизм законына буйсынган рәвештә кулланыла;

2) икенче яктан, аларның әлеге таләпкә җавап бирмәгән фонетик вариантлары да бертигез дәрәҗәдә татар сөйләм телендә яшәп килә;

3) исемнәрнең тартык һәм сузык авазларның чиратлашуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән вариантлары да телдә параллель рәвештә актив кулланылып килә, әмма кайбер очракларда аерым шәхескә карата вариантларның берсе генә берегеп калу, әлеге фонетик вариантның нәкъ менә аны билгели торган идентификацион күрсәткеч буларак кулланылу фактларын да билгеләргә мөмкин (мәсәлән, *Замирә - Зәмирә, Нури – Нурый, Зе'мфира - Зимфира'* )

4) аваз төшеп калу нәтиҗәсендә барлыкка килгән фонетик вариантлар татар сөйләмендә иң аз өлешне тәшкил итә, бу очракта орфоэпик норма буларак тулы вариантын санарга кирәк дип исәплибез, чөнки күзәтелгәнчә, кыскартылган форма күбрәк диалекталь һәм гади сөйләм өчен хас күренеш булып тора.

Гомумән алганда, татар антропонимнарының вариатив формалары булу телнең үз эчендәге лингвистик сәбәпләре белән билгеләнгән: сингармонизм законына буйсыну, соңгы иҗекнең басымны үзенә алуы, тартык

һәм сузык авазларның чиратлашуы, авазларның төшеп калуы. Шул ук вакытта татар антропонимнарының вариатив формалары булу экстралингвистик факторлар белән дә билгеләнә: хәзерге сөйләм вәкилләренең күпчелегенең билингв шәхес булулары, өстәвенә, күпчелекнең урыс теленә өстенлек биреп, күбрәк аңарда аралашу тәэсире дә үзен сиздерми калмый – алынма исемнәр оригиналдагыча яки оригиналга якын рәвештә кулланыла, бигрәк тә бу яшьләр сөйләме өчен хас лингвистик күренеш.

## ӘДӘБИЯТ

Баширова И.Б. История татарского литературного языка: письменно-традиционная норма и вариативность / И.Б. Баширова // Научный Татарстан. – № 4. – 2009. – С. 50-54.

Князев С.В., Пожарицкая С. К. Современный русский литературный язык: фонетика, графика, орфография, орфоэпия: Учебное пособие для вузов / С.В. Князев, С.К. Пожарицкая. – М.: Академический Проект, 2005. – 320 с.

Мартине А. Принцип экономии в фонетических изменениях: проблемы диахронической фонологии / А. Мартине – М.: Изд-во иностр. лит-ры, 1960. – 301 с.

Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш / Ф.С. Сафиуллина. – “ТаРИХ” нәшр., 2001. – 296 б.

Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге. / Х.Х. Сәлимов. – Казан: “Яңалиф” нәшр., 2004. – 192 б.

Суперанская А.В. Структура имени собственного. Фонология и морфология. – М.: Наука,1969. – 206 с.

Татар лексикологиясе. өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – Т. III. – 536 б.

# ХАТЛАРЫМНЫ БЕР УКЫРСЫЗ... (И.САЛАХОВНЫҢ ШӘХСИ АРХИВЫННАН)

# (WHEN MY LETTERS ARE READ… (FROM THE PERSONAL ARCHIVES OF I. SALAHOV))

**Leila GARIPOVA***
**Fatima MINNULLINA****

## SUMMARY

The letters of I. Salakhov,which are kept in the archive of the Institute of Language, Literature and Art of the Republic of Tatarstan Academy of Sciences, contain many interesting things for recreating a more objective and complete view of Tatar literature. Studying letters of the writer will allow to expand a circle of creative interests of the national literature. Each letter bears not only the prints of its epoch, but I. Salakhov himself is revealed as a bright, unrepeatable personality. He is one of the writers, whose not only life, but also the creative path is rich in dramatic events.

Татар әдәбияты мәйданында “Күкчәтау далаларында”, “Имәннәр тамыр җәйгәндә”, “Дала дулкыннары”, “Колыма хикәяләре” кебек күләмле романнары белән киң танылган татар язучысы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, ТР Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Низам улы Салахов (1911-1998) Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә һөнәрчеләр гаиләсендә туа. Башта мәдрәсәдә, аннан татар мәктәбендә белем алганнан соң, 1928 елда Казан педагогия техникумына укырга керә, укуын тәмамлагач, «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» газеталарында, «Ялкын» журналында әдәби хезмәткәр булып эшли. Хәрби хезмәттә булып кайтканнан соң, Казан дәүләт педагогия институтының тел һәм әдәбият факультетына укырга керә, шушы чорда аның «Ярату» пьесасы, «Дуэль» повесте, шигырьләре тупланган “Постта” исемендә китаплары басылып чыга. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, Ялтага дәваланырга барган яшь язучыны, Казанда нәшрият бастырасы җыентыкка Галимҗан Ибраһимовтан кулъязма алып кайтырга җыенуы өчен, 1937 елның 25 октябрендә кулга алалар. Аны «халык дошманнары» белән яшерен контрреволюцион элемтә тотуда, аларга арадашчы булып хезмәт итүдә гаеплиләр һәм ун елга ирегеннән һәм аннан соң биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә дигән гаделсез хөкем карары чыгарыла. И.Салахов сигез айлап Казанның Плөтән һәм ел ярым Тобол шәһәре төрмәсендә утыра, аннары Колыманың алтын приискаларына «хезмәт белән төзәтү» лагерьларына озатыла. Шунда И.Салаховка хөкем карарының мөддәте беткәнче өзлексез авыр хезмәт, рәнҗетелүләр белән тулы тоткынлык мәхшәрен кичерергә туры килә. Язучы сәламәтлеген какшата, аварияга эләгеп аягын имгәтә, күзләренә зарар килә. 1947 елның 25 октябрендә азат ителгәч тә, аңа Казанда яки туган шәһәре Күкчәтауда яшәргә, матбугатта иҗади хезмәтләре белән катнашырга рөхсәт

---

* Candidate Philol. Science, Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov, Tatarstan Academy of Sciences, Kazan.

** Candidate Philol. Science, Institute of Language, Literature and Art named after G. Ibragimov , Tatarstan Academy of Sciences, Kazan.

ителми, ул, Күкчәтаудан җиде чакрым ераклыктагы Кызыл Яр дигән авылга гаиләсе белән күченеп, райпотребсоюз ашханәсенә буфетчы булып эшкә урнашырга була. 1956 елның 25 апрелендә И.Салаховны гаепләү эше СССР Югары судының Хәрби коллегиясе тарафыннан яңадан каралып, 1938 елның 12 маендагы хөкем карары нигезсез дип табыла һәм әдипкә бөтен гражданлык хокуклары, шул җөмләдән матбугатта әсәрләрен бастыру хокукы да кире кайтарыла (Әдипләребез, 20091:314-315).

Шул чорда ук И.Салахов үзенең атаклы документаль роман-хроникасын — «Колыма хикәяләре»н дә яза башлый. Әсәр укучылар һәм әдәби тәнкыйть тарафыннан тоталитар режимның кешелексез сәясәтен, үз халкына каршы юнәлтелгән явыз гамәлләрен, җинаятьләрен фаш иткән, Сталин зинданнарында, концлагерьларыңда хаксызга һәлак ителгән миллионлаган репрессия корбаннарына мәрсия булып яңгыраган тарихи документ буларак кабул ителә (Мингазова, repository.enu.kz). Озакламый романның русчага тәрҗемәсе дә чыга, аерым өзекләре радиотапшыруларда яңгырый, әсәр буенча эшләнгән сәхнә варианты узган гасырның туксанынчы елларында Казан Яшьләр театры тарафыннан да куела. «Колыма хикәяләре» китабы өчен И.Салахов 1990 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була, 1992 елда аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә (Әдипләребез, 20091:314-315). Язучының әдәби эшчәнлеге, катлаулы тормышы турында филология фәннәре докторы Л.Минһаҗева хезмәтләрендә тулы яктыртыла. Галимә Ибраһим Салахов иҗатын өйрәнеп, филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсе алу өчен диссертация яклый. 2002 елда аның «Ибраһим Сәләхов» исемле монографиясе басылып чыкты (Минһаҗева, 1999).

И.Салахов исемен атауга, иң беренче, нык ихтыярлы, көчле, сабыр һәм түземле кеше килеп басса, икенчедән, аның нәкъ менә атаклы “Колыма хикәяләре” искә төшә, шул салкын Колыманың җанөшеткеч төрмәләрендә кешеләрнең ыңгырашуы, газаплы әрнүләре, туң җанлы адәмнәрнең иләмсез тавышларын ишеткән күк буласың... Күпме имгәтелгән кеше язмышлары, бинахакка юкка чыккан меңнәрчә исемнәр... Әлеге әсәр матбугатта басыла башлагач, китап булып дөнья күргәч тә, язучыга бик күп хатлар агыла: берәүләр югалган туганнарының язмышын ачыкларга тырыша, икенчеләр чын мәгънәсендә тарихи документ булган әлеге әсәре өчен язучыга рәхмәтен белдерә. Күпме хат, күпме йөрәк авазы... Язучы һәрбер хәбәргә, хатка җавап бирергә тырыша, саклап бара. Шул рәвешле, зур архив туплана, елдан-ел тулылана, байый.

Ибраһим Салахов архивы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгенә 1995 елда кайтарыла. Аны Казакъстанның Күкчәтау өлкәсендәге Кызыл Яр авылыннан институт хезмәткәре Зөфәр Мөхәммәтшин алып кайта. Әдип вафатыннан соң, аның башка шәхси архив материалларын Күкчәтау шәһәре татар мәдәни үзәге хезмәткәре, язучыга һәрчак ярдәм итеп торучы Әския ханым Әхмәтшина 1999 елда И.Салаховның васыяте буенча Мирасханәгә тапшыра (Бәдретдинов, 2016) һәм алар нигезендә 156 нчы санлы зур фонд оештырыла.

Фонд искиткеч бай, кыйммәтле. Монда язучы әсәрләренең төрле вариантлары, кульязмалары, көндәлек дәфтәрләре, язышкан хатлары һәм башка күп төрле документлар белән танышырга мөмкин. Язучы үзе исән чагында ук архивы өчен борчылган, аны урнаштыру юлларын эзләп,

сөйләшүләр алып барган һәм нәкъ менә ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсенә тапшыру теләген җиткергән.

Фондта иң зур өлешне хатлар алып тора. “Әле сиңа килгән хатлардан зур гына бер өлеш төзеп, аны “Казан утлары”нда бастырып чыгарасы иде. Мөгаен, хатлар арасында моңарчы без белмәгән, белә алмаган, тарихчыларның күзеннән читтә калган газиз милләттәшләребезнең Сталин тәбеләрендә һәлак булганнарның исемнәре, якты гамәлләре бардыр. Сиңа килгән хатлар, романда телгә алынган исемнәр кебек үк кадерле исемнәрне дөньяга чыгаралардыр дип ышанам. Алар синең архивта сүзсез калмасыннар иде инде. Гомумән, егәрең барында син бу җәһәттә үтәргә мөмкин булганнарның барын да башкарып чыга алсаң иде!..” *(ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. – 156 нчы фонд, 3 нче тасв*). дип яза А.Гыйләҗев үзенең бер хатында. Гомумән, Аяз Гыйләҗевнең И.Салахов архивында бик күп хатлары саклана. Аяз Гыйләҗев язучының күп кенә әсәрләре корректурасын укып, аңа һәрдаим булышып килә, кирәкле урында төзәтмәләр кертеп, ахырдан нәшриятлар белән сөйләшүләр алып бара, хикәя-романнарын бастырып чыгаруда зур ярдәм итә.

И. Салахов А.Гыйләҗевка язган бер хатында һәрбер язучының, шул исәптән үзенең дә архивы, мирасы, архивындагы һәрбер хаты өйрәнелеп, укучыга барып җитәр дигән фикерен әйтә. Ләкин А.Гыйләҗев зурга өметләнмәскә куша, аның йөрәк әрнүе, җан ачысы белән әйтелгән сүзләре гыйбрәтле: “Әдипләрнең архивы, алар вафатыннан соң калган мирас материаллары мине байтактан борчый. Язучы вафат була, дөньялыктан күчә, мирас комиссияләре төзеп, аларны матбугатта белдерәбез. Шуның белән барлык эш сүнеп кала шикелле... без хәзер бик арзанлы эйфорияләр болытына уралып: “уяндык, яшибез!” — дип сөрән салып шапырынсак та... чынлыкта татар бүген битарафлык йокысында. Нәкъ элеккечә гамьсезлек дулкыннарында, ваемсызлык сазлыгында. Шушы очсызлык, кадерсезлек тоташтан дәвам итә икән, бездән килгән хатлар, куен дәфтәрләре кемгә кирәк?Тарих мәйданына безне аңлый, кадерле торган буыннар килер дип кем күрәзәлек итә ала?..” (*ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты ЯһММҮ. – 156 нчы фонд, 3 нче тасв*).

И.Салахов хатлары – әдәби процесс эчендә яшәгән шәхес хатлары. Аларда һәм аның архивында сакланган башка кешеләрнең хатларында шул чорның иҗтимагый, мәдәни һәм әдәби тормышындагы кызыклы фактлар, күренекле язучы-шагыйрьләрнең, әдәби процесска якын кешеләрнең теге яки бу мәсьәләгә ачык фикерләре, ялганга, икейөзлелеккә корылмаган ачыктан-ачык бәяләре чагылыш таба: “Озак дәвам иткән авыр тынлыгым өчен кичер”, ди А. Гыйләҗев бер хатында. – “Татар китабының язмышы кыл өстендә. Китабың укучыга барып җитми икән, бу инде инкыйразның иң ачысы. Татар – китапка мәхәббәте белән танылган милләт иде. Инде бөтен милли сыйфатларыбызны тарихның кайсы тирән катламнарыннан эзләп табарбыз да, ничек итеп халыкның суык җанын җылытырбыз” (*ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты ЯһММҮ. – 156 нчы фонд, 3 нче тасв.)*. Үзенең китабы чыгу уңаеннан язучы Ә.Еники И.Салаховка хат юллый: “...тынычланырга иртәрәк әле – тәнкыйтьчеләр сүзен ишетәсе бар. Ә тәнкыйть ул бик хикмәтле нәрсә, фокусник шикелле төрлечә китереп чыгарырга мөмкин. Тик бер хакыйкать бар: яңа әсәрне халык яратып кабул итсә, аны инде бернинди тәнкыйть тә юкка чыгара алмый. Шуңа ышаныйк!”.

“Безнең татар язучыларының күбесенең тарихи йөзе әсәрләрендә генә кала. Юбилейларны баштанаяк язып, кинога төшереп калдыру турында яшьләр уйламый. Язучылар союзында да бу мәсьәләдә бик мәшәкатьләнмиләр. Ә бит иң беренче, бу аларның бурычы бит!” *(ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты ЯһММҮ. – 156 нчы фонд, 3 нче тасв.*) - ди Зәкия Садыйкова классикларыбыз Х. Туфан, М. Җәлил хакында язган бер хатында.

Салахов хатлары белән таныша барган саен, аның тагын бер ягы ачыла: ул кешеләргә игътибарлы, мәрхәмәтле, югары культуралы интеллигент булган, кулдан килгәнчә ул үзенә мөрәҗәгать иткәннәргә, башлап язучы яшьләргә ярдәм кулын сузган, хатларына һәрдаим җавап биреп барырга тырышкан. Бу аның көндәлекләреннән, куен дәфтәрләреннән күренә – нинди хәбәр алынган, кайсына җавап бирәсе, кемне котлыйсы бар.

1965 елдан Казакъстанда “Семей таңы” дигән, аңа кадәр “Казакъ теле”, “Кызыл дала”, “Семей правдасы” исемнәрендә йөргән газета чыга. Әлбәттә, газетаның хәле төрле елларда төрлечә була. 1992 елда аның кушымтасы буларак татар телендә “Галиябану” газетасы чыга башлый. Газетны дөньяга чыгару, нәшер итү бик авырлык белән бара. Редакторы булган Наилә Абдулкәримова язучы И.Салаховның авторитетына таянып, аның югарыдагылар белән сөйләшүен үтенә. Әлбәттә, язучы ярдәм кулын суза. Газетаның беренче елларындагы авырлыклар – бина бирелмәү, бирелгәннән соң да җимерек хәлдәге йортны аякка бастыру эшләре, кәгазь кытлыгы һ.б. хатларда ачык чагылыш таба. Әдипнең классик шагыйребез Хәсән Туфанга язган хатыннан бер өзек китерәсебез килә:”Исәнмесез, хөрмәтле Туфан ага! Хәерле көн. Бүген «Казан утлары»ның 7 саны килде. Ачтым, сезнең шигырьләр. Укып чыктым. Тагын укыйсы килде. Кабатлап укыдым. Күңел дулкынлана башлады. Нәрсәнеңдер, бик еракта калган кадерле хатирәнең ахырын хәтерләгәндәй булдым... Үзем дә сизмичә «Багышлаулар...»ны тавышланып укый башлаганмын... Таң алдыннан кошлар сайравы аеруча яхшы, моңлы һәм зәвыклы була...

Мин үземнең туган телемнән, моңымнан, әдәбияттан, Казаннан ерак... Кәккүк кебек ялгыз... Шуның өчен минем ялгыз бүлмәдән туган тел тавышы, таң алдындагы кошлар сайравы кебек, аеруча яхшы яңгырый. Бигрәк тә сезнең акрын, басынкы, уйларга тирән авыр тавыш...

Нинди хатирә, нинди соң ул югалтканым? Нинди?
Әй, син, исемә төшми...
«Әй, машинист,
Каула паровозны
Уралымны өзелеп сагындым!
Әллә минем уйлар авыргамы
Әкрендегез инде, вагоннар?»

Мин бу юлларны 1927 елда «Безнең юл»да укып, дога итеп кабатлап, Казанга килгән идем.

«Урал эскизлары» минем иман шартым булды”. Бу юлларны укыганда әдипнең Туфанга булган олы ихтирамы, хөрмәте дә, халкына, иленә мәхәббәте, кайчандыр ашкынып, зур хыяллар белән килгән Казанын сагынуы да, гомумән, рухи халәте, эчке бер сызлануы да сизелә.

Шунысы аянычлы — төрле фаҗигаләргә тарыган язучыга тыныч тормышта да тиешле игътибар җитмәгәнлеген күрәсең. Төрмә-лагерьларда сәламәтлеген югалткан И.Салахов дәвалануга мөмкинлеге, акча булмавыннан зарланып, кат-кат төрле оешмаларга гариза-үтенечләр язып

карый. Ләкин күп җирдән бернинди дә җавап ала алмый, кайсыберләре исә кире кагыла. Гариза-хатлар язучының иҗат эшен тоткарлаган, рухи көчен алган, киеренке халәттә яшәргә мәҗбүр ителүен дә чагылдыралар. Мондый халәт Салаховның китаплары матбугатта басыла башлагач, китап булып чыккач та күренә. Язучының әсәрләре дөнья күргәч, аларны төрле телләргә тәрҗемә итү эше башлана. Ләкин күп авторлар моны язучының рөхсәтеннән башка эшлиләр, икенчеләр исә, тәрҗемә эшенә алынып та, вазыйфаларына салкын карыйлар яки төрле сәбәпләр аркасында читләштереләләр. Салахов, әлбәттә, моңа бик әрни, язучыларга, Язучылар союзына хатлар юллый башлый, ләкин, аяныч, җаваплылыкны үз өстенә алырга теләмәгән, бер-берсенә сылтаган хатлар чылбыры барлыкка килә. Салкын төрмә газапларыннан исән калган кешенең тыныч тормыштагы күңел газаплары, әрнүләре ераkларга барып ташлана да, хәл ителә алмыйча, яңадан кире әйләнеп кайта...

Язучы архивында повесть-романнарының беренче вариантлары белән дә танышырга мөмкин. Мәсәлән, “Имәннәр тамыр җәйгәндә” романының күп өлеше (хәтта бүлекләп) романнан төшерелеп калдырыла. И.Салахов күп әсәрләрен гарәп шрифтендә яза: “Мин хәзерге рус алфавитына нигезләнгән яңа татар әлифбасын белмим дә, белергә дә теләмим. Ул бит, без төрмәдә утырганда – 1938 елда Бөек юлбашчыбызның бөек “тәгълимәте” нигезендә төрки халыкларга көчләп тагылды ич. Бу алфавитны кабул итмим, бары тик үзебезнең тулы яңгырашлы гарәп әлифбасында гына язам. Ярый, бик ярсып, үзенчә яздың, ди. Ә соң ул язганны кем укый алыр. Яшьтәшләрең китә бара. Язу машинкасында бастыру мөмкинлеге юк. Менә бит аяк астында тагын бер тоткарлык”, ди ул һәм кирилл хәрефләрендә яза башлый. Ләкин кулъязмалары авыр укыла, күп әсәрләре нәшриятлардан кире кайтарыла. Аның язмаларын Газизә Гыйззәтуллина, Гайшә Сираҗетдиновалар – язучының якын дуслары, гарәп шрифтеннән кириллицага күчерәләр, машинкада бастыралар, үзләренә ярдәмгә башка кызларны да табалар һәм шул рәвешле, бик күп урау юллар аша, кулдан-кулга күчә-күчә, озак көннәргә, айларга, елларга сузылса да, әсәрләре халык кулына килеп ирешә.

Язмышында күп фаҗигалар күргән һәм шуларны яңадан йөрәгендә, күңелендә яңартып язарлык көч тапкан бу олуг шәхеснең архивы, мондагы һәрбер хат, документ аның тормышын, иҗатын тагы да тулырак күзалларга, язучының үзен дә аңларга ярдәм итәләр.

### ӘДӘБИЯТ


Әдипләребез: Библиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том / төз. Р.Н. Даутов, Р.Н.Рахмани. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 735б.

Бәдретдинов Х. Ибраһим Сәлахов аркадашы / / Мәдәни җомга, август, 2016.

Мингазова Л.И. Художественное отображение Казахстана в творчестве Ибрагима Салахова // repository.enu.kz

Мингазова Л.И. Ибраһим Салахов: тормышы һәм эшчәнлеге. – Казан: Матбугат йорты, 1999. – 176 б.

Мингазова Л.И. Личность с большой буквы: И.Салахову 100 лет // Казан утлары. - 2011.- № 8. - С. 160-163.

Мингазова Л.И. Татарская интеллигенция в романе И.Салахова "Калымские рассказы" // История политических репрессий и сопротивления несвободе в СССР: Сборник методических разработок учителей РТ: по итогам 8 и 9-го респуб. конкурса учителей в 2009-2011 уч.г .- Казань: ТГГПУ, 2011. - С. 71-81.

ТР ФА Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге. – 156 нчы фонд.

# A STUDY OF TATAR – RUSSIAN CODE SWITCHING IN TATARSTAN ARTIST'S INSTAGRAM

**Elzara GAFIYATOVA***
**Nailya MINGAZOVA****

**SUMMARY**

The article deals with the analysis of Code-Switching. The study reported in this paper centers on the functions motivating code switching in social life – Instagram page. The data for the article was collected from Instagram page of Tatar artist (female) from the beginning of January till the end of March 2018 (more that 700 posts were analyzed). The author comes to the idea that code-Switching (CS) is very common among multi - or bilinguals who switch between different languages communicating with each other. The study presents a literature review of the world science, describes the development, establishment and history both abroad and in the Russian sciences, examples of real-life situations faced by modern people. The results of the experiment are sketched on the diagram and presented with the examples in Tatar language. The author came to a conclusion that the most common functions for this study are "Habitual Expressions" and "Lack of registral competence". In the course of the work the following methods were used: analysis of the problem based on the study of linguistic, philosophical, psychological, pedagogical, cultural, methodological literature. The author hopes that the materials of the study may be useful worldwide by educators and researchers involved in professional linguistic research and training.

The use of code switching has increased in almost all aspects of social life in the republic of Tatarstan during the last five years, such as economy, science, technology, law, literature, and as well as entertainment. The first person who began to use social network was The President of the Republic. Therefore, many Tatarstan artists use code switching in their communication activities as the most convenient way of communication. Traditionally, the Tatarstan artists' usually share their daily life stories and their activities, concert programs through the social networking.

Instagram helps the Tatar artists to share and exchange information, news, ideas with their friends and their fans by posting in it. The article aims to answer the following research questions: 1. What are the functions of code switching used by Tatar artists in Instagram?, 2. Why do Tatarstan artists use code switching in their Instagram pages?.

The study used the data that was directly taken from the Instagram (personal pages that is in open access). In this case the tatar artist's Instagram was analysed. The artists name is Ilsia Badretdinova, she is a singer, presenter, master of ceremomies and also an actor. This page is chosen because she often posts Insta events and she is very active in using social media especially Instagram, she had 103 K followers when we started doing the research and the number has increased till 110 k during 5 weeks. This research is the first attempt to fill the gap by revealing the functions for code-switching in tatar communication.

Without going into details we are going to discuss some of the most influential lines of research in the study of code-switching (herein after CS).

---

* Assoc. Prof. Dr. Kazan Federal University, Kazan.
** Assoc. Prof. Dr. Kazan Federal University, Kazan.

According to Nomura (2003), speakers may not be aware that code-switching has occurred in their communication or be able to report which language they have used during a particular topic after the conversation. Few researchers have addressed the problem of Tatar CS. For example, in the study on Crimean Tatar and Russian CS, Oksana Tyshchenko-Monastyrska [9] focuses on both the grammar and the functions of examples in her data. Based on speech samples gathered from bilingual suburban and village setting, she applied Myers-Scotton's matrix model, finding common instances of prototypical discourse marker usage. In addition, she found the functional aspects of CS were more apparent "when larger units like clauses are being code-switched" (p. 552). She further finds differences based on speaker generation and gives examples of the speech of older, middle-aged and younger speakers, noting that Tatar is preferred by the older generations, whereas for middle-aged and younger speakers, Russian tends to be more common, tendencies largely determined by speaker comfort levels with the two languages. Lastly, she notes that for all speakers, the most common CS functions were topic-change and ease of expression in conversation (p. 554). In the research paper of Solnyshkina M. I. and Khairullina A. R. [14] "Code switching of Russian-Speaking Tatars" the authors point out that "the insertions are mainly represented by nouns, pronouns, particles, adverbs; island-switches are predominantly nominated by verbs". Information gained from the study will help to provide insight on how and why code-switching occurs not only in spoken but also written form.

The motivations, functions and reasons of code-switching have been studied extensively by a number of researchers from various linguistics perspectives. Based on the concept of functional specialization by Jakobson (1960) and Halliday et al. (1964), Appel and Muysken (2006) listed six main functions of code-switching: referential, poetic, metalinguistic, expressive, phatic, and directive functions. Malik (1994) in discussing the sociolinguistics of code-switching of the language situation in India explained ten reasons for speakers to code-switch: 1. Lack of facility: When certain concepts in a variety are not available in the other, bilingual speakers switch code to express themselves and at the same time avoid unnecessary misunderstanding and loss of intended meaning. 2. Lack of registral competence: Bilinguals may find difficulties in choosing appropriate words in the target language for specific topics and choose to codeswitch when they are not equally competent in the two languages. 3. Mood of the speaker: Code-switching takes place when bilinguals are in different moods such as angry, anxious or nervous. Although the intended words are available in both languages, bilinguals may code-switch when the words in the other language seem to take less effort and time to be used at that particular moment. 4. To amplify and emphasize a point: Bilinguals may code-switch on selected parts of a speech to make sure that listeners know what to highlight and focus on in situations such as an argument. 5. Habitual expressions: Code-switching also happens commonly in fixed phrases such as greetings, commands, requests, apologies and discourse markers. This may suggest strength to a speech such as warning or threat. 6. Semantic significance: Used as a verbal strategy, code-switching can convey important and meaningful linguistic and social information. 7. To show identity with a group: Code-switching is used to signify shared values and experiences by people of a same group or culture. Hence, words and phrases are retained in their original languages to represent a sense of belonging and familiarity to the group.

According to our research the first post was dated to the 16$^{th}$ of November, 2015 year. Nowadays she has more than 700 posts concerning different parts of

her life. The funding of this study has indicated that four of the six functions can be used to explain the occurrence of code switching. We can say that the most often used functions in her posts according to Malik's functions, are, Lack of facility, Habitual expressions, Lack of registral competence, Mood of the speaker. Below is the diagram that indicates the classification of functions of code switching in Insta page of Ilsia Badretdinova.

The numbers from 10 till 70 in the diagram means the number of posts in Insta page, 10 is equal to 100.

Here are some examples of the research, e.g: [Vot poperla tak poperla/ The thougts flooded] – all words in Russian; [Patamushta uramda/ because outside]; [Mena nichekter irten iogere bashlarga ide… Tolko kish kone salkin!!!/ How to start running in the morning … ONLY it is cold in winter]; [Imesh irten torgach ta ike stakan su echsen, organism shunduk uayna/ if you drink 2 glasses of water, it means that the organism weaks up]; [Kiemge akkan super kleini nichek betererge ul?/ How to remove the glue from the dress], [Bashkortstanda bugen uge!/ Today in Bashkortstan already ]; [Vse (smile sign) Vse (smile sign) Vseeeee (emoticon)/ Finished]; [Beznen torkemde baby bar!!!/ A baby was born].

Code switching is widely spread in bilingual communities. This article has demonstrated that there can be different reasons for CS in the professional sphere. We have seen that not only words and phrases but even whole sentences can be code-switched.




## REFERENCES

Appel, R., & Muysken, P. (2006). Language contact and bilingualism. Amsterdam University Press.
Malik, L. (1994). Sociolinguistics: A Study of Code-switching. New Delhi: Anmol.
Nomura, M. (2003). Bilingualism and multilingualism: A study of code switching. The Bulletin of the International Student Center, Kobe University, 8. Retrieved from http://www.lib.kobe-u.ac.jp/handle_kernel/00523015
Tyshchenko-Monastyrska, O. (2012) Code-switching in Crimean Tatar. Proceedings in Dilleri ve Kültürleri Yok Olma Tehlikesine Maruz Türk Toplulukları konulu 4. Uluslararası Türkiyat Araştırmaları Sempozyumu, 2012, pp. 549-555.
Solnyshkina M.I., Khairullina A.R. (2015) Code switching of Russian-Speaking Tatars. Bulletin of Cherepovets State University, 1, 56-59.

# XIX ГАСЫРНЫҢ СОҢГЫ УТЫЗЪЕЛЛЫГЫНДА ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР ҮСЕШЕНДӘ К. НАСЫЙРИ ҺӘМ И. ГАСПРАЛЫ

## (K. NASYRI AND I. GASPRYNSKIY IN THE DEVELOPMENT OFCRITICAL THOUGHT IN THE LAST THIRD OF THE XIX CENTURY)

**Takhir GILAZOV***

**SUMMARY**

Tatar literary criticism is one of the branches of literary study. Tatar literary criticism was formed as a science in “golden century”, in XX $^{th}$ century. But its traditions goes back to middle age of Tatar literature. After exploring this branch of literary study scientists suggested the theory of developing Tatar literary criticism which consist of some periods. The formation of Tatar literary criticism takes the beginning from “middle age” till XX century. Nevertheless, a first period of Tatar literary criticism begins with 19$^{th}$ century. This period is closely connected with some changes, reforms in tatar-muslim world: culture, way of thinking and literature. Moreover, the age of enlightenment brought its adjustments. All Tatar elite began to interest, explore the west-russian culture. Scientists understood the importance, influence of Europe culture and its literatury traditions on formation of not only Tatar but whole Turkic literature. All Tatar enlighteners understood the value of culture and a temporary publishing house for youth, new generation. That is why they put all forces for forming official publishing houses in Tatar language. Autocracy of power were against the idea of forming the official publishing house in Tatar language. Nevertheless, one of the Tatar enlighteners, scientist, writer Kayum Nasyri(1825-1902) began to publish desktop calendars in Tatar language. Begin with 1879 year Kayum Nasyri dedicated himself to literary and scientific world. After that in Bakchisarai(1882) under the edition of Ismagil Gasprynskiy published the “Tarjeman” newspaper. This newspaper serve a literary, spiritual purposes of Turkic-Tatar world. Kayum Nasyri through his desktop calendars and articles in “Tarjeman” newspaper gave the theoretical basis of Tatar literary criticism. Above all, Kayum Nasyri fixed some historical materials about writers and his creations.

So, the 19$^{th}$ century is the century of formation of Tatar literary criticism, its theoretical basis and practical implementation. 19$^{th}$ century is the period when Tatar literary criticism became a science, the brunch of Tatar literary study.

Татар әдәби тәнкыйте әдәбият гыйлеменең бер тармагы булып тора. Тәнкыйди фикер тарихы, урта гасырларны иңләп, борынгы чорларга барып тоташса да, ул, фән буларак, татар әдәбиятының “алтын чоры”нда, ягъни XX гасыр башында гына барлыкка килә. Әдәбиятчы галимнәр, тәнкыйди фикер үсеше тарихын өйрәнеп, аның берничә баскычын аерып чыгаралар. Әдәби тәнкыйтьнең фән буларак формалашуга әзерлек дәвере хронологик яктан борынгы заманнан алып XX гасыр башына кадәрге чорны үз эченә ала. Әмма тәнкыйди карашларның мең елдан артык тарихи үсеш юлында XIX гасырның соңгы утызъеллыгы бер баскыч буларак каралырга хаклы. Әлеге баскыч XIX гасырның урталарыннан татар-мөселман дөньясында, аның иҗтимагый фикерендә, мәдәниятендә һәм матур әдәбиятында башланган үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнгән. Татар мәгърифәтчеләре мәдәниятне, аның төрле

* PhD (Philology), Kazan Federal University, Kazan.

структур элементларын, шул исәптән вакытлы матбугатны да милләт яшәешендә әһәмиятле чара дип карыйлар. Шулай ук татар милләте күтәрелешендә Европа мәдәниятенең тәэсирен нык тойган төрек мәдәниятенең һәм сүс сәнгатенең әһәмиятен тирән аңлыйлар. Шушы максаттан алар, шәркый традицияләргә таянып, көнбатыш-рус һәм төрек мәдәниятен өйрәнүгә керешәләр.Мәгърифәтчеләр милли мәгарифне, татар фәнен үстерү, татар телендә рәсми төстә газета һәм журналлар чыгару өчен көрәшә башлыйлар. Патша самодержависенең милли-колониаль сәясәте татар зыялыларының вакытлы матбугат булдыру теләгенә каршы төшсә дә, бу хәрәкәтнең аерым уңай нәтиҗәләре дә була. Ә вакытлы матбугат тәнкыйть җирләшүдә мөһим шартлардан санала.

Татар әдәби тәнкыйтенең тәүге ныклы адымнары XIX гасырның икенче яртысында татар мәдәнияте һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган атаклы энциклопедист галим, мәгърифәтче, язучы һәм фикерче Каюм Насыйри (1825-1902) гыйльми һәм тәнкыйди эшчәнлегендә ясала. Мәгълүм булганча, Шәрекътән, Урта гасыр татар әдәбиятыннан килгән традицияләрне Көнбатышның фәнни-гыйльми практикасы белән кушу омтылышы аның хезмәтләрендә күзәтелә. Күренекле әдәбиятчы, телче, тәнкыйтьче, педагог, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Җ.Вәлиди (1887-1932) үзенең “Татар әдәбияты барышы” (1912) дигән хезмәтендә К.Насыйрины халкына хезмәт итү теләге белән татарның уяну чорында чыккан “реформатор” дип атый. “Каюм Насыйри, - дип яза Җ.Вәлиди, - иң элек безнең татарлыгыбызны аңлады вә аны үзенең әсәрләре белән башкаларга да аңлатмакчы булды” (Вәлиди, 2010: 133). Шулай ук күренекле әдәбият һәм тел галиме, тәнкыйтьче, публицист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Г.Ибраһимов (1887-1938) исә “бөек реформатор” К.Насыйрины Гарби Европаның әдәби-мәдәни тәҗрибәсеннән файдалануда “юл ячучы”, “беренче сукмакны салучы” буларак ассызыклый (Ибраһимов, 1978: 483). К.Насыйри күпьяклы эшчәнлегенең татар халкы тарихында уйнаган ролен тирән аңлаган милли зыялылар аны зурлап “Каюм баба” дип атаганнар.

Әлбәттә, К.Насыйри, телебезне гыйльми һәм гамәли яктан тикшереп, татар лингвистик фәнен нигезләүгә, татар тарихын барлауга, татар галәмендә, беренчеләрдән булып, этнография, фәлсәфә, математика, география, медицина, юриспруденция, игенчелек һ.б. фәннәрдән методик әсбаплар язып, милли мәгарифне үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә. Болардан тыш ул - халык педагогикасына нигезләнеп, шәрык һәм гареб фикер ияләреннән файдаланып язылган күп кенә тәрбия китаплары һәм хезмәтләр авторы да. Кешене рухи һәм физик тәрбияләү нисбәтеннән бүген дә актуальлеген югалтмаган фикерләр әйтеп калдыра. К.Насыйри белем һәм тәрбия бирүнең берлеген, акыл һәм тәҗрибәнең тыгыз бәйләнештә торуын раслый: “ Һәрбер нәрсәнең чиге... бардыр. Әмма гакылның чиге һәм соңы юктыр... Гакыл белән тәҗрибә бер-берсенә ярдәмче булмакта җир белән су кебектер. (Мәгълүм ки), су белән җир бер-берсеннән башка бернәрсә (дә) үстерә алмыйдыр...” (Насыйри, 2004, 2 т.: 6).

К.Насыйри – татар әдәбият белеме һәм фольклористикасы тарихында да мәгълүм урын тота. “Художестволы әдәбият өлкәсендә дә Насыйриның тарихи әһәмиятле һәм универсаль хезмәтләре бар. Ул, бер яктан, тәрҗемәче <... >, икенчедән, әдәбият тарихчысы да, фольклор җыеп, аны гыйльми нигездә әзерләп бастыручы һәм үзенә кадәрге татар шагыйрьләренең әсәрләренә игътибар итеп, аларны тикшерә башлаучы галим дә. Әдәби

тәнкыйть өлкәсендә дә башлангыч хезмәтләрне ул бирә" (Гайнуллин, 1948: 26).

К.Насыйриның фарсы телендәге ядкәрдән тәрҗемә ителгән "Кабуснамә" (1881) китабының "Шигырь вә шагыйрьләр әхвале бәянында" дип аталган бер бүлегендә шигырь үзенчәлекләре, сүз-сурәт мәгънәсе, укучыларга төбәлгәнлеге һәм аңлаешлылыгы турында әйтелгән фикерләре кыйммәткә ия. Автор карашынча, шигырьнең төп күрсәткече ритм һәм рифма гына түгел, ә төзеклек, хыял һәм образлылыктан башка шигырь була алмый. Образ, сүз-сурәт аша белдерелгән фикер, гәүдәләнгән хис-кичереш тә аның асыл табигатен билгели. Илһам, хис һәм таланттан башка шигырь язып, иҗат итеп булмый: "И угыл, әгәр шагыйрь булып шигырь әйтмәк касд итсәң, җәһед ит ки, шигырьдә сүзең рәүшан (нурлы, ачык) булсын, саклан ки, гамиз (мәгънәсез) булмагай... Бәс, шигырь һаман вәзен вә кафия генә түгелдер: хыялсыз, вә тәртипсез, вә сәнгатьсез шигырь әйтмә" (Насыйри, 1975, 2 т.: 63).

"Фәвакиһел җөласә фил әдәбият" ("Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимеше", Казан, 1884) дигән китабының кырыгынчы, соңгы бүлеге дә тел, әдәбият тарихы һәм әдәбият мәсьәләләренә багышланган. К.Насыйри башта халык авыз иҗаты жанрларын аерым чыгара, аларның үзенчәлекләрен күрсәтә. Шулай ук матур әдәбиятның әһәмиятенә, аның кешене тәрбияләү һәм әхлак төзәтү вазифасына туктала, әдәби күренешләргә шактый киң аңлатмалар бирә. Анда XVIII гасыр әдәбиятыннан XIX гасыр татар мәгърифәтчелек әдәбиятына күпер салучы Г.Утыз-Имәни һәм мәгърифәтче шагыйрь Г.Кандалый иҗатлары гыйльми- тәнкыйди күзаллана. Соңгысының күренекле поэмаларыннан "Сәхипҗамал", "Бәдыйга", "Фәрхи"не үз китабына урнаштыра. Әдип әсәрләрен тел һәм төзелеш ягыннан фәнни шәрехләү омтылышын ясый. Аныңча, Кандалый шигырьләре метрика системасында булып, гарәп шигырьләр үлчәве – бәхерләр белән язылганнар. Яңа чыккан китапларга рецензияләр язганда, ул аларның техник ягын, эчтәлек һәм формасын яхшырту юнәлешендә киңәшләр бирә.

К.Насыйриның чирек гасыр дәвамында нәшер ителгән өстәл календарьларында әдәби тәнкыйтькә караган материаллар дөнья күрә. Шулай итеп, аның әдәби-гыйльми эшчәнлегендә моңа кадәр синкретик, үзара керешкән хәлдә яшәгән әдәбият белеме фәне татар әдәби тәнкыйтенә һәм әдәбият теориясенә аерыла башлый. Аерым алганда, әдәби тәнкыйтьнең жанрлары, аларның сыйфатлары, тәнкыйть принциплары һәм алымнары ачыклана башлый. Мәсәлән, рецензия, тәгъзия, мәкалә һ.б.ларның беренче үрнәкләре языла. Ул бу төр эшчәнлегендә тәнкыйть материалларын бәяләү югарылыгына күтәрелә. 1885 елгы календаренда ул Шиһап Мәрҗанинең "Гылаләтез-заман фи тарихи Болгар вә Казан" китабын тәнкыйть итеп чыга. Анда Ш.Мәрҗани Хисаметдин Мөслиминең "Таварихы Болгария" исемле китабына субъектив якын килеп, тарихи нигезсез әсәр дип бәяләгән була. К.Насыйри исә тарихи, әдәби истәлекләргә берьяклы якын килү белән килешеп бетми һәм "Әттәфтише вәттәхакем" ("Тикшерену һәм нәтиҗәләр ясау") тәнкыйди мәкаләсе белән аңа каршы чыгып, Мәрҗани теленең аңлаешсыз булуын, сүзләрнең тарихи этимологиясен билгеләүдәге төгәлсезлекләрен күрсәтә."Тәфтиш әл-китаб әл-матбуг" (Яңа басылган китапларны бәяләү), "Әттәфтише вәттәхакем" ("Тикшерену һәм нәтиҗәләр ясау") кебек язмалары татар әдәбиятында беренче әдәби тәнкыйть мәкаләләре, тәүге рецензияләр буларак карала (Гыйлаҗева, 2012: 51). Мондый рухлы хезмәтләрендә автор тарафыннан әсәрләрне идея эчтәлеге һәм сюжет-композицион, сәнгатьлелек ягыннан яхшырту таләпләре дә куела.

1883 елда Бакчасарай шәһәрендә - танылган җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, фикер иясе Исмәгыйль Гаспралы (1851-1914) мөхәррирлегендә дистә еллар дәвамында төрки-татар, мөселман халыкларының рухи-мәдәни, әдәби ихтыяҗларын канәгатьләндереп килгән “Тәрҗеман” (“Переводчик”) газетасы нәшер ителә башлый. Бу газета битләрендә, беренчедән, әдәбият белеме, шул исәптән тәнкыйтьнең дә нәзари мәсьәләләре яктыртылган, икенче яктан, күренекле әдипләр турындагы библиографик язмаларга, әдәби әсәрләргә урын бирелә; публицистик мәкаләләр һәм, һәр санда диярлек, яңа басылып чыккан төрле жанрдагы китапларга рецензияләр тәкъдим ителә.

Шунысы кызыклы һәм гаҗәп: “Тәрҗеман” газетасы битләрендә “Тәнкыйди язмалар”, “Тәнкыйть” рубрикасында әдәби тәнкыйть, аның үзенчәлеге һәм предметы мәсьәләләрен кузгаткан язмалар 1890 елларда ук күренә башлый. Мәгълүм булганча, укымышлы Зөһрә Акчурина-Гаспринская (1862-1903) ире Исмәгыйль Гаспралыга журналистлык эшчәнлегендә төп ярдәмчеләрнең һәм киңәшчеләрнең берсе була. Аның ярдәмендә “Тәрҗеман” битләрендә татар телендәге аерым материаллар ирекле тәрҗемә белән рус телендә һәм, киресенчә, русча текстлары, татарчалаштырылып, милли телдә дөнья күрә. «Зөһрә ханым “Тәрҗеман” газетасының аеруча авыр беренче авыр елларында И.Гаспралының уң кулы булды. Мөселманча гына түгел, русча да белемле булган ханым беренче 5-6 елда бөтен контора һәм экспедиторлык эшен алып бара. <    > Үз ире-мөхәррирнең бик зур әхлакый таянычы булу аның тагын олы бер казанышыннан санала» (Мостафа Давыдович, 1903: 22 апр.) Шундыйларның берсе – 1896 елның ике санында басылган “Тәнкыйть турында” язмасы. Башлам өлешендә тарих, поэзия, повесть, мәсәл хакында мәгълүматлары булган мөселманнарның кеше фикеренең яисә сәнгать әсәренең хакыйкый мәгънәсен билгели торган “үлчәм” – тәнкыйть хакында хәбәрсезлыгы искәртелә. “Тәнкыйть – теге яки бу әсәрнең хакыйкый матурлыгын һәм хакыйкый файдалылыгын бәяли торган үлчәм һәм бизмән” (Гаспралы, 1896: 7 гыйн.) (сүзгә-сүз тәрҗ. – *Т.Г.*). Тәнкыйть гүзәллек күренешен яхшырак яктыртучы, кеше эшчәнлеген дөрес шәрехләүче нурга тиңләнә. Әдәби тормышта тәнкыйтьнең мөһим урын тотуы ассызыклана. Автор карашынча, тәнкыйть – билгеле кануннары һәм методлары булган белемнәр һәм эзләнүләр системасы. Бәяләү объектлары, предметлары, хасиятләренә нигезләнеп, тәнкыйтьнең дини, тарихи һәм әдәби тармаклары күрсәтелә.

Әдәби тәнкыйтьнең генетик тармаклары Аристотель һәм Платонга барып тоташып, аларның поэзия, драма һәм сәнгать әсәрләренә нисбәтле тәнкыйтьне кулланулары әйтелә. Борынгы грек һәм римлеләрнең эстетик казанышлары ауропалылар тарафыннан үзләштерелеп, һәр рухи, язманың, сәнгати иҗатның матурлык, *максатчанлык* (целесообразность. – *И.Г.*), тышкы форма һәм әһәмияте ягыннан төрле яклап тикшерелүе һәм бәяләнүе, ягъни әдәби тәнкыйтьнең функциясе киңәю ассызыклана. Мәкалә авторы әдәби тәнкыйтьнең төрле мәдәниятләрдә хосусый үсеш үзенчәлекләрен билгели. Гареб мәдәниятендә әдәби мәктәпләр һәм эстетик өйрәтүләр үзгәреше төсендә үскән тәнкыйтьнең Россиядә, үз хакимиятен киңәйтеп, әдәби мәсьәләләрне хәл итүдән тыш, тарихи һәм җәмгыяви өлкәләрне иңләве билгеләнә. Рус тәнкыйди фикеренең культура-тарих мәктәбенең кагыйдәләрен һәм кануннарын якын итүе күрсәтелеп, матурлыкның нигезен ачуга караганда, иҗтимагый үзаң тарихына йөз тоткан рус тәнкыйтенең тормышчанлыгы хакында нәтиҗә ясала. Автор мөселман мәдәнияте үсешен

Рус әдәби-эстетик казанышлары контекстында карап, мөселман әдәбияты һәм көнитешендәге күренешләрне бәяләүдә, Көнбатышныкына караганда, рус тәнкыйте принципларының уңайлы һәм туры килүен ассызыклый.

В татарском языке их четыре степени: положительная, сравнительная, превосходная и уменьшительная степень. Например: *сары* «желтый» (положительная ст.) →*сарырак* (сравнительная ст.) «желтее, желтей, пожелтей» образовано от корневого слова *сары* и суффикса *-рак →сап-сары*(превосходная ст.) «желтейший» образовано от корневого слова *сары* и

* Postgraduate M. Akmullah Bashkir State Pedagogical University, Ufa.

префикса *сап-* → *саргылт* «желтоватый» (уменьшительная степень) образовано от корня *сары* и суффикса -*гылт*.

В персидском языке сравнительная степень прилагательных образуется синтетически прибавлением формообразующего суффикса تر- (-tar) к основе положительной степени: زیبا (zibā / красивый) – زیباتر (zibātar / красивее)» (Малых, 2011: 131-132): این گل از آن گل زیباتر است (in gol az ān gol zibātar ast / этот цветок красивее, чем тот другой). Аналитическая форма сравнительной степени в персидском языке образуется только от наречий. Большая степень выражается прибавлением форм بیشتر (более): من رمان را بیشتر از قصه دوست دارم (man romān rā bishtar az ghese dust dāram. / Роман мне нравится больше, чем рассказ), и меньшая степень интенсивности признака выражается аналитически прибавлением форм کمتر (менее): من به آلمانی کمتر از انگلیسی تسلط دارم (man be ālmani kamtar az inglisi tasalot dāram. / Я могу говорить по-немецки менее, чем по-английски), но в современном персидском языке эти формы (особенно меньшая степень) редко употребляются. В русском языке синтетическая форма употребляется в сравнительных конструкциях в единстве с формой родительного падежа объекта сравнения и аналитическая форма – в единстве с союзом чем, в персидском языке обе формы – с предлогом از (az) перед объектом сравнения: دوستم از من قویتر است- (Dustam az man ghavitar ast. / Мой друг сильнее меня). В персидском языке превосходная степень прилагательных образуется синтетически прибавлением суффикса –ترین (-tarin) к основе положительной степени: زیبا (zibā / красивый) – زیباترین (zibātarin – красивейший) или аналитически путем прибавления слов از همه (az hame / всех, всего) к форме сравнительной степени (از همه زیباتر – всех красивее). С помощью суффикса –ترین (-tarin) превосходная форма образуется лишь от качественных прилагательных, например: تالستوی شناخته شده ترین نویسنده روس در میان ایرانیان است (Tālstoy shenākhteshodetarin nevisandeye rus dar miāne Irānian ast. / Л. Н. Толстой – самый известный русский писатель среди Иранцев). В персидском языке образование превосходной степени от наречий возможно только аналитически, например: او از همه سریعتر میدود (U az hame saritar midavad. / Он/она бежит всех быстрее).

Сегментация речевого потока состоит в выделении из словоформ наименьших значимых единиц, морфов. Морфы с тождественными значениями объединяются в одну единицу языка – морфему. Вся совокупность морфем данного языка образует морфемный, или морфемно-морфологический уровень.

Спорным вопросом является выделение языковых единиц морфемно-морфологического уровня. Часть лингвистов выделяет в качестве языковой единицы этого уровня морфему. Другие ученые считают, что морфемы и их связи должны изучаться в единстве с выполняемыми ими функциями. Поэтому они включают в состав единиц этого уровня морфемы, дериватемы и граммемы. Слово является узловым элементом языка. Оно разными своими сторонами имеет отношение к другим единицам языка и к другим языковым уровням. Слово не только носитель лексического значения, оно одновременно и морфологическая единица, образованная по определенным правилам. Поэтому словоформы - это морфологические образования, составляющие морфемно-морфологический уровень.

Морфологический уровень языка может рассматривать и другие части речи, которые могут образовать метафоры, где открываются другие уровни языка в основном семантический и синтаксический. Метафоры рассматриваются и через призму конкретизирующей связи слов в

предложении. В конкретизирующей связи одно слово поясняет, конкретизирует понятие, выраженное основным словом. Аналогичным образом строится метафорическое словосочетание. Однако в метафорическом словосочетании между компонентами устанавливается тесная взаимосвязь за счет метафоризации компонентов, составляющих данное словосочетание.

В языкознании метафорические словосочетания изучались с разных позиций: исследовались вопросы смысловой связи между компонентами, морфологического выражения компонентов метафор, средств связи между компонентами.

В татарском языке на основе метафорического переноса значений возникают прозвища типа ***Куян*** *Хәмите* (Заяц Хамит), ***Әтәч*** *Нәгыйме* (Петух Нагим). Данные формы прозвищ образуются на основе конкретизирующих отношений между компонентами по тюркскому изафету.

Каждая эпоха порождает свою систему метафор, построенных на конкретизирующем виде связи в предложении. Например, ***гомер аждаһасы*** (дракон жизни) (Навои), ***гөнаһ туе*** (свадьба греха) (М. Колый), ***ваемсызлык иле*** (букв. страна безразличия) (З. Насыйбуллин). В этих метафорах, как видно, отображаются значительные явления в жизни общества (на примере ***гөнаһ туе*** выражается идеология суфизма).

На основе пояснительного вида связи возникают своеобразные метафорические конструкции, аналогичные приложениям русского языка. Например: *җир*-***Ана*** (земля-Мать); *Идел*-***Йорт*** (Волга-Дом); *Урал*-***бабай*** (Урал-дед); ***болганчык су***-*җыр* (мутная вода-песня) и др.

В татарском языке широко распространены конструкции пояснительных отношений, где в роли пояснительной части выступает метафорическое выражение, находящееся в постпозиции по отношению к поясняемому слову. Например, *җил*, ***сыбызгы***, … (ветер, свистулька); *җил*, ***морҗа сандугачы***, ... (ветер, соловей дымохода) (Һ.Такташ) (Нугуманова, 2009: 15-16).

Семантическая сфера «Человек как психическое существо» является важным объектом метафоризации. Но в то же время лексика этой сферы не является источником метафоризации, т.к. человеку не свойственно сопоставлять предметы и явления мира с элементами своей психической деятельности.

Среди метафор, отражающих психическую деятельность, можно выделить глаголы, характеризующие умственные способности человека, процессы восприятия, память, воображение, эмоции, настроения, моральные и нравственные качества. Между этими группами провести четкую грань невозможно. Но в этом случае метафоры можно классифицировать по их семантической роли в предложении. Первую группу составляют идеальные психические концепты: «желания», «чувства», «мысли», «настроения» и т.д. — ***фикер ялтырады*** (мысль блеснула), ***уйлар кайный*** (мысли кипят). В роли объекта метафоризации выступают различные семантические сферы: психическая деятельность сопоставляется с процессами материального мира, физическими процессами: ***хисләр уңа*** (чувства линяют), ***ачу таша*** (обида переполняет) — перенос от Материального мира к Человеку как психическому существу, с действиями животного мира: ***уйлар безелди*** (мысли жужжат), ***теләкләр оялый*** (желания гнездятся) – перенос от Животного мира к Человеку как психическому существу; психические состояния ассоциируются с физическими процессами: ***уйлар сикерә*** (мысли прыгают), ***кәеф күтәрелә*** (настроение поднимается); социальные действия переходят в область психических: ***хисләр патшалык итә*** (чувства царствуют), ***мәхәббәт тормышны яктырта*** (любовь освещает жизнь) – перенос от Человека как социального существа к Человеку как психическому существу.

Метафора есть сокращенное сравнение. Сравнение, как грамматическая форма, как словесное обозначение и образа и обозначаемого, заключает в себя метафору, а не другие тропы

В заключении отметим, что морфологические средства выражения категории сравнения русского, персидского и татарского языков отличительны по своему строению, в основном это связано грамматическими формами вышеуказанных языков.

**ЛИТЕРАТУРА**

Алиреза, В., Щлэр, И. Структурный сопоставительный анализ категории сравнения и способы её выражения в русском и персидском языках // Филологические науки. Вопросы теории и практики № 11 (53) 2015, часть 3 – С. 47-49.

Гарипов, Т. М., Нугуманова, А. А. Проблемы корневых слов в тюркских языках // Проблемы словообразования в тюркских языках: материалы конференции – Казань: Фикер, 2002. – С. 65-70.

Конюшкевич, М. И. Категория сравнения и её место в системе языка // Вопросы функциональной грамматики: 2001. – Вып. 4. – С. 82-94.

Киекбаев Дж. Г. Сингармонизм в словах, заимствованных из арабского и персидского языков // Учитель Башкирии, №2. 1957 – С. 24-28.

Малых Л. М. Статус категории сравнения в современных лингвистических исследованиях // Вестник Удмуртского университета. – 2011. – Вып. 2. – С. 105-110.

Нугуманова А. А. Антропоцентрик фразеологик берәмлекләрнең кайбер үзенчәлекләре = Некоторые особенности антропоцентрических фразеологических единиц // Система непрерывного образования: школа-педколледж-вуз: сборник материалов региональной научно-практической конференции, посвященной 125-летию со дня рождения Г. Тукая -Уфа: БГПУ им. М.Акмуллы, 2011 -С. 112-114.

Нугуманова А. А. Лексико-грамматические и стилистические особенности метафор в татарском языке. – Уфа: Вагант, 2008. – 147 с.

Нугуманова, А.А. Метафоры в татарском языке: лексико-грамматический и стилистический аспекты / автореферат диссертации на соискание ученой степени кандидата филологических наук / Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова академии наук Республики Татарстан. Казань, 2009 – 27 с.

Нугуманова А. А. Работа над словом на практических занятиях по татарскому языку (Текст) / А.А. Нугуманова // Система непрерывного образования: школа-педучилище-педвуз материалы всероссийской научно-практической конференции. 2002. С. 167-169.

Нугуманова А. А. О синестезии в татарском языке // Сохранение и развитие родных языков в условиях многонационального государства: проблемы и перспективы: материалы II Международной научно-практической конференции – Казань: КФУ, 2009. – С. 120-122.

Огольцев В.М. Модели компаративного словообразования: учеб. пособие по спецкурсу. Пермь, 1978. 64 с.

Рубинчик Ю.А. Грамматика современного персидского литературного языка. – М., 2001. – 600 с.

Мәхмутов М. И., Хәмзин, К. З., Сәйфуллин, Г. Ш.. Гәрәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. (татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре) – Казан: “Иман” нәшр., 1993. – 448 бит, I том.

Мәхмүтов М.И., Хәмзин, К.З. Сәйфуллин Г.Ш. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. (Татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре) – Казан:“Иман” нәшр., 1993. – 409 бит, II том.

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ШАРТЛЫ-МЕТАФОРИК СУРӘТЛЕЛЕК

# (UNREAL IMAGE AND METAPHOR MEANS IN MODERN TATAR DRAMA LITERATURE)

**Alfat ZAKIRZYANOV***

## SUMMARY

Due to changes in social and political life of the society a special social, spiritual and cultural situation have occurred on the edge of XX and XXI centuries. At this period in tatar drama literature there is a special esthetical variety. On the one hand it has all meanings and points of view of the past, on the other, seeking something new, this variety finds itself in different cultural phenomenon. All this has made the authors to create a new type of a hero together with unusual means and ways of contradictory life-being depicting.

One can notice weaving of romantic and realistic scenes, using new means and methods by the authors, and attention to a personality of a human-being, his spiritual experiences. In plays that are on the stage, such philosophical questions as impossibility of comprehension and explanation of reality, weakness of a human-being, impermanence of life, it`s meaning are shown. For example, Amanulla and R. Zaidulla in order to understand severe contradictions of reality use both realistic and mythological depicting, unreal images, metaphor and language facilities. Unreal image and metaphor means in modern tatar drama literature.

Хәзерге татар драматургиясендә тормыш-чынбарлыкны әдәби чаралар аша чагылдыру, аның үзенчәлекләрен укучы-тамашачыга җиткерү юлларын, алымнарын эзләү бара. Аның нигезендә, бер яктан, җәмгыятьтәге иҗтимагый-сәяси, социаль-мәдәни процесслар, икенче яктан, һәр милли әдәбиятның эчке үсеш закончалыклары, өченче яктан, башка әдәбиятларда, аеруча, рус-Европа сүз сәнгатендә урын алган әдәби-эстетик, фәлсәфи табыш-нәтиҗәләр ята. Билгеле инде, аларның тәэсире бер төрле түгел һәм була да алмый. Язучының шәхесенә, иҗат стиленә бәйле әлеге шарт-сәбәпләрдән берәрсе өстенлекле урын алып, еш кына иҗат индивидуальлеген дә билгели. Әлеге үзенчәлекләр XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы сәхнә әдәбиятында аеруча киң чагылыш таба. Хәзерге татар драматургиясендә барган эзләнүләрнең бер үзенчәлеге булып әдипләрнең реалистик һәм романтик күренешләр үрелеп барган һәм әлеге кысаларга гына сыеп бетмәгән яңа алым-чараларга мөрәҗәгать итүе һәм кеше шәхесенә, аның рухи кичерешләренә игътибар арту тора. Соңгы елларда дөнья күргән сәхнә әсәрләрендә яшәешнең әхлакый, социаль-иҗтимагый, милли мәсьәләләре белән бергә, чынбарлыкның аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин булмаган, кешенең көчсезлеге, гомеренең чиклелеге, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи сораулар да өйрәнү объекты итеп алына. Үзенең башлангычыннан алып, татар драматургиясендә комедия жанры өстенлек итә. Дөрес совет чорында драма жанры да игътибар үзәгендә булып, аның

---

* Head Of The Department Of Literature, Doctor Of Philology, G. Ibragimov`s “A Language, A Literature and An Art” Institution, Kasan, Russia.

җитди казанышларга ирешә. Әлеге үзенчәлек XX гасыр ахырында да саклана. А.Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, татар драматургиясе үзгәртеп корулар чорында да сатираны алгы планга чыгара. Бу исә китап укучы һәм тамашачыларның көндәлек сорауларына җавап рәвешендә, яшәештәге җитешсезлекләргә килешмәүчәнлеге белән аңлатыла (Ахмадуллин, 2012: 505).

Татар сәхнә әдәбияты нигездә реализм һәм романтизм юнәлешендә үсеш-үзгәреш кичереп килә. Әмма бу аның традицион булмаган алым-чаралардан баш тартуы дигән сүз түгел. Ә инде XX гасыр ахырында яңа, авангард эзләнүләр эзлекле, системалы төс алып, әдипләрнең максатчан рәвештә модернизм һәм постмодернизм юнәлешләренә хас форма-сурәтләргә мөрәҗәгать итүе белән очрашабыз. Рус әдәбиятыннан аермалы буларак, татар пьесаларында модернизм, постмодернизм алымнары реализм элементлары белән кушылып, үзгә бер синтез хасил итә. Моның нигезендә татар әдәбиятының, шул исәптән драматургиянең милләт язмышын, аның үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген җитди фәлсәфи проблема итеп куюы һәм шуны чагылдыру өчен яңа юллар-чаралар эзләве ята. Й.Нигъмәтуллина язганча, “милли темага, тарихи үткәнгә кызыксыну арту, дөнья һәм рус сәнгатендәге стиль, форма һәм идеяләрнең милли традицияләр үзенчәлегеннән һәм хәзерге чорның әдәби-эстетик таләпләреннән чыгып үзгәрүе” (Нигматуллина, 2002: 22) хәзерге драматургиянең яңарышына китерә. Шул рәвешле, хәзерге татар фәнендә модернизмның (төрле стильләрнең синтезы һәм аларның реализм белән катлаулы мөнәсәбәт-бәйләнеше; урта гасырлар романтик әдәбиятының аерым традицияләре активлашу; әдипләрнең актив рәвештә архетипларга, мифологемнарга, фантастик һәм шартлы формаларга, символларга мөрәҗәгать итүе; әдәби алым һәм сурәтләү предметы буларак “уен” ны, шулай ук “нулевая композиция”, ин-янь принцибын куллану; автор концепциясен шартлылык һәм билге-символ аша чагылдыру тенденциясе; милли теманың мөһим проблематика буларак алгы планга чыгуы; күптөрлелек, чикләнгәнлек һәм чиксезлек кебек фәлсәфи проблемаларга йөз тоту; әдипләрнең фәлсәфилеккә, хикмәтле сүз әйтүгә, притча жанрына теләп мөрәҗәгать итүләре) һәм постмодернизмныж (үткән мәдәниятнең “эзләрен” яңадан тудыру; “натура”ны алыштырган “мәдәният”нең коллаж рәвешендә бирелүе; хәзергене үткән белән бәйләү мөмкинлеге биргән синкретик формаларга омтылу; авторларының парадоксальлеккә түгел, ә реальлеккә йөз тотуы; бер әсәр чикләрендә төрле темалар, әдәби алымнар, стильләр, төрле әдәби-тарихи традицияләрнең очрашуы күрсәтелү; әсәр чынбарлыгы һәм реаль чынбарлыкның аерып куелуы; үз дөньясы хакында сөйләүче язучы-автор урынын язучы-скриптор (кәгазьгә төшерүче) алу; рус яки Европа әдәбиятындагы мондый алымнардан аермалы буларак, лириклыкка омтылу; эпитетлар һәм детальләштерү алгы планга чыгу, үзәгендә хисчәнлек яткан “шизоанализ” алымына, коллажга, пародия тудыруга) төрле алым-чараларын аерып чыгару күзәтелә (Закирҗанов, 2014: 36-37). Ике гасыр чигендә киң танылу алган пьесаларның күбесендә кеше шәхесенең төрле якларын ачуга бәйле кызыклы, гыйбрәтле һәм үзенчәлекле эзләнүләрне күрәбез. Моның бер сәбәбе булып, Г.Л.Нефагина билгеләп үткәнчә, әлеге алымнарның реалистик нигезгә каршы килмәве, бәлки тормышның автор концепциясен тыгызлау чарасы булып хезмәт итүе тора (Нефагина, 2003: 113). Мисал өчен, метафора булып килгән вакыйга-күренешләр ярдәмендә җәмгыятькә бәя бирү (З.Хәким “Кишер басуы”, Ф.Бәйрәмова “Вакыйга юләрләр йортында бара”);

чынбарлыктан ерагайтылган тормыш моделе төзү (М.Гыйләҗев “Баскетболист”); сызлануга, аңсызлыкка бәйле чиктәш халәтне сурәтләү (Т.Миңнуллин “Тәнзиләкәй”, З.Хәким “Шайтан куентыгы”); архетипларга, мифологемаларга мөрәҗәгать итү (М.Гыйләҗев “Бичура”, Р.Хәмид “Актамырлар иле”, Р.Зәйдулла “Ашина”); әдәби алым һәм сурәтләү предметы буларак “уен”ны файдалану (З.Хәким “Җүләрләр йорты”, Аманулла “Әлепле артистлары”); ике дөнья күренешләрен шартлы алымнарда сурәтләү (М.Гыйләҗев “Бичура”, З.Хәким “Шайтан куентыгы”); милли үзенчәлек буларак лиризмның көчәюе (Д.Салихов “Үтеп барышлый”, “Өзелгән йөзем”); пьесаларда фәлсәфи эчтәлек киңәю (Т.Миңнуллин “Шәҗәрә”, “Дивана”, З.Хәким “Гасыр моңы”), аллегорик күренешләрдән файдалану (И.Юзеев “Ак калфагым төшердем кулдан...”, З.Хәким “Чапты атым Казанга”); финалның ачык калуы, интеллектуаль драма төренә йөз тоту (Т.Миңнуллин “Хушыгыз”, Аманулла “Җәйге кырау”); көнкүреш хәл-күренешләре, детальләре аша яшәешнең актуаль проблемаларын күтәрү (Т.Миңнуллин “Шулай булды шул”), әсәрләрдә гаҗизлек мотивының киң урын алуы (Р.Хәмид “Актамырлар иле”, Т.Миңнуллин “Саташу”, Д.Салихов “Чукрак”); заман героен тасвирлау, татарның олы характерын тудыру омтылышы (Т.Миңнуллин “Мулла”сында Әсфәндияр, З.Хәкимнең “Телсез күке”сендә Зариф, Р.Зәйдулланың “Үлеп ярату”ында Мөхлисә Бубый); күпчелек әсәрләрдә фаҗигалелек төсмере персонажларга үтеп керү (З.Хәким “Бит”, Д.Салихов “Алла каргаган йорт”, И.Зәйниев “Суган чәчәге”, Р.Зәйдулла “Саташкан сандугач” һ.б.).

Хәзерге драматургиядә шартлы-метафорик һәм шартлы-мифологик алымнарга мөрәҗәгать итү белән Р.Хәмиднең “Актамырлар иле”, М.Гыйләҗевнең “Бичура”, “Баскетболист”, З.Хәкимнең “Су төбендә сөйгәнем”, “Кишер басуы”, “Җүләрләр йорты”, Аманулланың “Җонлы кеше”, Р.Зәйдулланың “Пачпортлы шүрәле” һ.б. пьесаларда очрашабыз. “Андый әсәрләрдә “фарс элементларына, пародия алымнарына мөрәҗәгать ителә, шартлылык еш кына фантастика, абсурд дәрәҗәсенә җиткерелә, уен алымы яратып кулланыла” (Йосыпова, 2008: 439). Безнең игътибар үзәгендә Аманулланың “Җонлы кеше” һәм Р.Зәйдулланың “Пачпортлы шүрәле” комедияләре булып, аларда шартлылык һәм метафорик алымнарның әдәби функциясен ачыклау максат булып тора.

Ике автор да шактый охшаш сюжетка мөрәҗәгать итә. Аманулла әсәрендә авыл көтүчесен урманнан чыккан Җонлы кеше буларак кабул итеп, шуңа бәйле абсурд хәлләр башланса, Р.Зәйдулла әсәрендә урманнан чын Шүрәлене тотып кайталар һәм ул авыл тормышын тулысынча үзгәртә. Аманулланың «Җонлы кеше» сатирик комедиясе үзәгендә – үткән гасырның 90 еллары башындагы татар авылы. Автор аның гаять авыр, каршылыклы хәлен сурәтләп, үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез бәйләнешендәге җитди сөйләшүгә алып килә. Гсырлар дәвамында сакланып килгән язылмаган кануннар югалып, әхлакый кыйммәтләр бозылган хәлдә, татар авылының киләчәгенә, димәк ки, татар милләтенә дә җитди куркыныч яный дип кисәтә Аманулла. Моның сәбәпләре турында уйланып, түбәндәгеләрне аерып чыгара: “1) совет системасының өстән кушканны үтәүне күздә тоткан эш стиленең соңгы чиккә килеп җитүе; 2) колхозның гомум милеккә нигезләнүе һәм беркемнең бернәрсә өчен җавап бирмәве; 3) кешедә үз хезмәте нәтиҗәсе өчен тырышу, яхшырак эшләү теләгенең юкка чыгуы, чөнки «эшләсәң дә түләмиләр, эшләмәсәң дә»; 4) үзебезнең рухи йомшаклыгыбыз, мәнсезлегебез, кемнәндер, нәрсәдер көтеп яту, кушканны гына эшләүгә гадәтләнү” (Закирҗанов, 2011: 158). Шундый шарт-сәбәпләр аркасында

кешеләр күңелендә киләчәккә өмет-ышаныч сүнгән, алар әхлаксызлык сазлыгына кереп баткан. Аманулла әлеге күренешләрне тагын да үтемлерәк итү өчен ышануы кыен булган, абсурд хәленә җиткерелгән хәлләрне сурәтләп үтә. Болар яшәешнең бөтен тармагында, аерым алганда, аерым кешедә, гаилә тормышында, дини ышануларда да очрый. Авыл кешеләренә тагы да тулырак бәяне агроном Әхтәм бирә: «Ут төртеп яндырырга гына кирәк бу авылны. Беркемгә бернәрсә кирәкми! Беркем берни эшләми! Крестьян балалары бит сез, каян килгән сезгә шулкадәр ялкаулык?» Татар авылы гомер-гомергә татарның яшәү рәвешен, иң матур гадәт-сыйфатларын, әхлагын саклап килсә, хәзер инде ул әлеге бурыч-вазыйфаны үтәүдән читләшә бара, икенче яктан, дистә еллар дәвамында яшәп килгән система үзенең хезмәт яратуы белән дан алган халыкны ялкаулыкка өйрәтеп, битарафка әйләндерүгә дә ачыла.

Колхоз рәисе Наил болай яшәп булмауны аңлауга килә һәм аннан чыгу юлын эзли. Ул чорда газета-журналларда кат-кат сөйләнгән вакыйга моңа этәреш бирә. Шотландиянең Лох-Несе күлендә зур кәлтә Несси яши икән, нигә әле татар урманында ниндидер бер зат яшәмәскә тиеш, ди. Шул рәвешле авыл урманында «Җонлы кеше» пәйда була. Бу рольне авыл көтүчесе Мәннән башкара. Биш кеше башлап җибәргән «уен»га әкренләп бөтен авыл кушыла. Чынбарлыкның ямьсез, күңелсез, эчпошыргыч, хәтта фаҗигале яклары әлеге «уен»ны төрләндерә, баета һәм урыны белән кайда «уен», ә кайда яшәеш дөреслеге икәне бутала да. Әсәрдәге вакыйга-күренешләрне, геройларны бер фокуска туплап торучы Җонлы кеше берничә вазыйфа башкара. Берсе – халыкның беркатлылыгыннан ачы көлү. Автор, кеше ышанмастай әйбергә ышануларын күрсәтеп, халыкның томаналыгын, көтү хәлендә булуын ача. Икенчесе – авыл халкының үз асылын, традицион яшәү рәвешен югалта баруын күрсәтү. Җонлы кешене ярымкыргый итеп тасвирлап, автор «Башкалар да шул хәлдә түгелме соң?» дигән сорауны куя. Читтән кайтканга күрә «килмешәк» дип аталган, урмандагы Җонлы кешедән – Мәннәннән – алар берни белән дә аерылмыйлар. Өченчесе һәм иң мөһиме – яңача уйлауга, үзгәрешләр башлауга этәргеч бирү. Халкыбызның үзәк тамыры нык, ул үзендәге кимчелекләргә көлеп карый белә һәм шуның белән билгеле бер чистарыну кичерә, ди автор. Ә инде тормыш-яшәешне үзгәртүне һәркем үзеннән башларга тиеш. Җонлы кешене күрергә кунаклар килү алдыннан авылда зур эшчәнлек башлана. Әсәр ахырында инде үзгәргән авылны күрәбез: Тәфкил эчүен ташлаган, туган як музее эшли, музыка мәктәбе ачарга йөриләр һ.б. Гомумән, Аманулла комедия жанрының асылын, көлү эстетикасын яхшы белеп яза. Халыкчан юмор, ирония , киң планда халыкның көлү культурасына таянуы әсәрне гаять тормышчан һәм эмоциональ яңгырашлы итә.

Р.Зәйдулла “Пачпортлы шүрәле” комедиясендә XX гасырның 90 еллары татар авылын сурәтли. Гомер-гомергә тел-милләт сагында торган авыл бүген ни хәлдә? Ул нәрсә белән һәм ничек яши? Әлеге сорауларны эчтән торып ачыклау өчен автор кызыклы сюжет таба: ике ир урманнан Шүрәле алып кайта. Әлеге кап-кара йонлы, зур гәүдәле затны авылның тол хатыннары бигрәк тә үз итә. Әнә шул рәвешле, фантастика алымнары кушылган уен башлана. Ул исә арттырылган, баетылган халәттә җәмгыятьтәге күп санлы проблемаларны ачып сала. Алар исә, уен ярдәмендә арттырылып, гротеск төсен ала. Авылда эшсезлек, ирләр акча эшләү өчен теләсә кемгә ялланырга әзер, рухи кыйммәтләр алышыну әхлаксызлык күренешләренең бермә-бер артуына китергән, эчкечелек соң чиккә җиткән

һ.б. Бу исә үзара мөнәсәбәтләргә дә үтеп кереп, кешеләрдә битарафлыкны, киләчәккә ышанмауны үстергән.

Автор Шүрәле образын төрлечә уйната: әнә аны үзендә кунак итү өчен хатын-кызлар чиратка язылган, Казаннан килгән журналист газетага чыгарган, академиклар да кызыксына ди. Р.Зәйдулла абсурд хәлне чын итеп кабул итүчеләрдән көлә, эш-гамәлләрен фай итә. Шүрәленең милләт символы булуына кат-кат игътибар итү дә яшәештәге җитди мәсьәләләрне милләт фаҗигасе дәрәҗәсенә күтәрегә китерә. Автор аны кеше исемнәреннән үк башлый. Катнашучылар барысы да чит илдән кергән исемнәр йөртә. Күршеләр булган Замир һәм Люция белән Альберт һәм Лениза мөнәсәбәтләрендә көнчелек, бер-берсен узып баю теләге хәттин ашкан. Авыл башлыгы Роберт Кимович мисалында да өстәгеләрнең халыкны талавы, ил байлыгын читкә сатып акча эшләү теләге генә ачыла. Җәмгыятьтәге гаделсезлек, ялган, үзара көнләшү, һәрнәрсәнең сату-алуга корылу – болар татар халкына хас иң матур сыйфатларның югала баруын, кешелек кыйммәтләрен әхлаксызлык күренешләре алыштыруын, авторның тирәнтен борчылуын аңлата. Шүрәлегә бәйле рәвештә, хатын-кызларның икейөзлеләнүеннән көлүдә, аларның тормыш драмасы ачыла.

Р.Зәйдулла татар психологиясен дә ача, аның үз-үзен, телен, традицияләрен саклап, киләчәге өчен көрәштән читләшүен дә тәнкыйтьли. Татар халкының мифологиясеннән килүче Шүрәле турында К.Насыйри болай дип яза: "Шүрәлеләр урманда тора һәм алар ялгыз гына яшәмиләр. Алар татарларга кеше кыяфәтендә күренәләр. (...) Әгәр урманда аларга татар очраса, алар аны кети-кети уйнарга чакыралар; әгәр дә ул күнсә, аны үтергәнче кытыклыйлар. Ләкин татар шүрәлене алдалый ала; ул аны ничек алдалый соң? Балта белән ярган агачка кул тыгып уйната да, шүрәле, аңгыралыгы аркасында, шунда ук һәлак була" (Насыйри, 2005: 260). Татар фольклорында һәм әдәбиятында "урман сарыгы" дип бәяләнгән зат авылның кешелексез якларына бәя бирә, аларны киң мәйданга чыгарып күрсәтә, шуның белән бу хәлдән котылу юлларын эзләргә чакыра. Шүрәлегә "пачпорт"ясатып, аны Россия гражданины итү, М.Җәлил һәйкәле белән газетадагы Шүрәле сурәтен тәңгәлләштерү яисә партиягә алып, депутат итәргә җыенуда "хуҗасына һәрвакыт тугрылыклы булган безнең татар" өчен әрнү чагыла. Ә инде бик күпләрнең идеалы буларак күзалланган Шүрәленең эчеп-исереп беркемгә кирәксезгә әйләнүендә һәм аны кире урманга илтеп кую теләгендә хыялларның юкка чыгуы, киләчәккә ышаныч бетү кебек сызланулы фикер дә калкып чыга.

Шулай итеп, хәзерге татар драматургиясенең төрле өлкәләрендә җитди эзләнүләр барып, алар форма-эчтәлектә дә, идея-проблематикада да чагылыш таба. Авторлар төрле алым-чаралар ярдәмендә яшәешнең үзенчәлекле якларын укучы-тамашачыга җиткерү юлларын эзлиләр. Алар арасында шартлылык, шулай ук метафора булып килгән хәл-күренешләр аша яшәешнең актуаль проблемаларын калкытып кую киң урын ала. "Шартлылык, чынбарлыкны үзгәртеп күрсәтү, хәл-күреншләрне бәяләүдә чиктәш ситуацияләр тудыруны көчәйтү аша, заманча ситуацияне үзгә, гадәттән тыш арттырылган сурәттә күрү мөмкинлеге бирә" (Загидуллина, 2017: 185). Аманулланың Җонлы кеше" һәм Р.Зәйдулланың "Пачпортлы Шүрәле" комедияләрендә әлеге алымнар милли тормышның кимчелекле якларын фаш итеп, җитди әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләрне бөтен кискенлеге белән куюга, укучы-тамашачыга җиткерүгә ирешелә.

## ӘДӘБИЯТ

Ахмадуллин А.Г. Татарская драматургия: история и проблемы. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2012. – 511 с.

Загидуллина Д.Ф. Современная татарская проза (1986-2016 гг.): основные тенденции историко-литературного процесса. – Казань: Изд-во Академии наук РТ, 2017. – 246 с.

Закирҗанов Ә.М. Традицияләргә тугрылык // Рухи таяныч: әдәби-тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – Б.157-168.

Закирҗанов Ә.М. Татар әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләре: уку-укыту әсбабе. – Казан: Отечество, 2014. – 156 б.

Йосыпова Н.М. Соңгы еллар татар драматургиясе // Хәзерге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2008. –Б. 436-443.

Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда, 3 том. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – 384 б.

Нефагина Г.Л. Русская проза конца XX века: Учеб.пособие. – М.: Изд-во “Флинта”, изд-во “Наука”, 2003. – 320 с.

Нигматуллина Ю.Г. “Запаздалый модернизм” в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – 176 с.

# БАТЫРЛАР ТУРЫНДА ӘКИЯТЛӘР

## (THE HEROIC TALE)

**Ilseyar ZAKIROVA***

**SUMMARY**

In Tatar folklore there is a special kind of fairy tales, in which feats of heroes-alyps – heroic fairy tales are described. These tales are close in their content and structure to the works of the folk epic and occupy an intermediate position between magical - fairy tales and heroic epic. The difference between heroic fairy tales and other genre varieties of a fairy tale is expressed in the fact that the main character – a hero achieves a fantastic goal thanks to physical strength. The duel with Diu / Azhdaha requires the hero to manifest great physical strength. The composition scheme of the heroic fairy tale is as follows: the beginning (epic), the epic part (the outset, the development of events, the culmination, the denouement), the ending. The characteristic origin suggests an installation on fiction, also designed to attract attention and interest of listeners. Widespread in Tatar heroic tales were motivated by the miraculous birth, fabulous rapid growth and heroic childhood hero. In heroic fairy tales, the echoes of mythological representations of the people have been preserved. Events develop in parallel worlds. The fight, the bogatyr's fight with the fairy-tale monster occupies a central place in heroic tales. The motivation for the battle is the rescue of the princess, or the people kidnapped by Diu, the salvation and liberation of the sacrificed girl from Azhdaha. Bogatyrskie tales of the Tatar people have parallels in international subjects about snakebearing and are versions of heroic tales of Turkic peoples. At the same time, in the specifics of the diverse artistic and pictorial devices, the national peculiarity of Tatar tales is manifested. The main idea of the Tatar hero stories is the law of the victory of good over evil and injustice.

Батырлар турындагы әкиятләр тылсымлы әкиятләрнең бер төркемен тәшкил итә. “Батырлар турында әкиятләр” дигән атама рус фольклорындагы героик эпосның иң архаик төренә карата кулланылган “богатырская сказка” терминыннан тәрҗемә итеп ясалган. В. Жирмунский бу терминны әкият жанры белән эпос арасында торган героик характердагы “әкияти-мифологик” эпоска, Б. Путилов керткән термин белән әйтсәк, “архаик эпос”ка (Путилов, 1975: 168, 170) нисбәттә куллана (Жирмунский 1974: 222-224). “Әмма батырлар турындагы архаик әкият (вариант – “каһарманнар әкияте”) героик типтагы тылсымлы әкият белән аеруча тыгыз бәйләнештә була, “классик” тылсымлы әкият генезисында да катнаша. Икенче яктан, әгәр архаик каһарманнар әкияте героик эпосның формалашуында башлангыч чыганак буларак катнашкан икән, “эпик батырлар турындагы әкиятләрне” инде каһарманнар әкияте эволюциясенең соңгы бер баскычы итеп карарга мөмкин” (Неклюдов, 1975: 82-83). Тагын шуны өстәп әйтергә кирәк: “эпик батырлар турындагы әкиятләр” арасында героик эпос җирлегендә, ягъни әлеге төр эпос-дастаннар трансформацияләнү нигезендә барлыкка килгәннәре дә бар.

* G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art of the Tatarstan Academy of Sciences, Kazan.

Татар фольклористикасында да каһарманнар әкиятеннән башлангыч ала торган мондый әсәрләрне “батырлар турындагы әкиятләр” дип атау кабул ителгән.

Татар фольклорының батырлар турындагы әкиятләре аерым җыентыклар булып басылып чыкмаса да, фәндә әлеге төр әкиятләрнең үзенчәлекләрен анализлауга җитди генә омтылышлар ясалды. Ф. Урманчеев, конкрет мисаллар китереп, батырлар турындагы әкиятләрнең башка тылсымлы әкиятләрдән аермасын һәм героик дастаннар белән уртак якларын күрсәтеп, “татар халык иҗатында шактый киң таралган бу төр әсәрләрне дастани әкиятләр дип атарга мөмкин” дип яза (Урманче, 2005: 102).

Батырлар турындагы әкиятләрнең төп үзенчәлеге – зур физик көчкә ия геройның батырлыгын тасвирлаган маҗарыларны тасвирлауга героеның гадәттән тыш физик көчкә ия булуы тумыштан ук килә. Аерым әсәрләрдә бу сыйфат геройның гадәти булмаган юл белән дөньяга килүенә нигезләп аңлатыла. Шуңа бәйле рәвештә әкият сюжеты булачак каһарманның озак еллар буена балалары булмаган карт белән карчык гаиләсендә тууы белән башланып китә. Бу мотив төрки, гарәп һәм фарсы халыкларының фольклорында һәм классик әдәбиятында очрый.

Геройның тууы гадәти түгел. Кайбер әкиятләрдә герой хәтта анадан да тумый. Мәсәлән, “Камыр батыр” әкиятендә балалары булмаган карт белән карчык булачак геройны камырдан әвәлиләр. Камырдан ясалган балага җан керә. Әкиятнең вариантларында әби белән бабайга менә шул рәвешле балалы булырга нинди дә булса кеше, очраклы рәвештә төн кунарга кергән карт яки нинди дә булса сихерче өйрәтә. “Камыр батыр” әкиятенең бер вариантыннан мисал китерик:

“Көннәрдән бер көнне бер карт килгән дә:

- Әгәр дә ходай бала бирсен дисәгез, камыр изегез дә, шул камырдан бала кыяфәтле нәрсә әвәләп, мич юллыгына куегыз, иртә белән торгач шул камырны актарып карагыз, – дигән.

Картлар, бу сүзгә бик сөенешеп, теге карт кушканча, камыр әвәләгәннәр дә төнгә мич юллыгына куеп калдырганнар. Иртәгәсен торып, камырның тышын ватып карасалар, ни күзләре белән күрсеннәр: камыр эчендә бик матур, бик таза бер ир бала ята икән”.

Икенче вариантта картлар үзләре шул рәвешле бала ясап карау уена киләләр: “Бер заман болар исәпләделәр, уйладылар да камырдан бер ир бала сыны ясап куйдылар. Әби чыгып китте сыер саварга, бабай чыгып китте утын ярырга.

Керсәләр, исләре китте, акыллары таралды: камыр сыны, малай булып, кәҗә бәтиләре белән уйнап йөри”.

Геройның тууында илаһи һәм сихри көчләр катнаша. Шул ук вакытта атаның бала туудагы роле еш кына кирәкле бирәр әйберне табуга кайтып кала. “Баһадир Зәрәннек” әкиятендә (“Таңбатыр” әкиятенең варианты) *герой* ата-анасы балык ашаганнан соң *дөньяга килә*. Ата, балыкчылар яллап, алардан кирәкле балык тотуларын гына таләп итә.

Кайбер әкиятләр геройның бердәнбер яки төпчек ул булуын хәбәр итү белән башланып китә. Төпчек ул гаиләдә өченче (“Тимеркендек”, “Алтын алма”, “Таңбатыр” һ.б.), унберенче (“Унберенче Әхмәт”), кырык беренче (“Кырык беренче малай”, “Кырык беренче батыр”), йөзенче (“Йөзми”) бала булырга мөмкин.

Без сүз алып бара торган әкият героеның тумыштан ук көчле булуы аның батыр балачагы, ягъни бала вакыттан ук башкалардан көче-җитезлеге

белән аерылып торуы белән дә раслана. Мәсәлән, “Таңбатыр” әкиятендә геройның балачагы түбәндәгечә сурәтләнә: “Үсеп җитү белән, болар уйнарга чыгалар. Яшьләр арасында болардан да көчле берәү дә булмый. Уйнаган вакытларында кешенең кай җиреннән тотсалар да, умыралар да алалар, ди, болар. Кәшәкә-шаралы уйнаганда да, болардан да оста уйнаучы юк, көрәшә башласалар да, кешене имгәтми калдырмыйлар, ди, болар”. Ә ”Әйгали батыр” әкиятендә булачак герой бишектә ятканда ук үзенең көчен күрсәтә: “Бала тугач, аны бишеккә салганнар. Патша бишектә яткан баланың битенә чапкалый икән. Битенә чапса да, бала бер дә еламаган, көлеп җибәргән. Патша, моңа гаҗәпкә калып, әлеге бишектә яткан балага үзенең бармагын йомдырган. Бала атасының бармагын йомып алган, патша бармагын көчкә генә тартып алган”. Шул рәвешле әкиятнең башлам өлешендә үк геройның гадәти булмавы күрсәтелә. Гадәти булмаган, еш кына могҗиза ярдәмендә туган геройның батырлыклар эшләргә әзер булганлыгы аңлашыла.

Батырлар турындагы әкиятләр арасында могҗизалы туу мотивы югалган, я булмаса башка торле экспозициягә нигезләнгән әсәрләр дә очрый. Бу әкиятләр патша кызының яки берәр әйбернең урлануын хәбәр итүдән башлана.

Кагыйдә буларак, сюжет алга таба геройның Дию урлап киткән кызны яки эзләп табуы кыен булган әйберне эзләргә китүе белән дәвам итә. Традицион эпик мотив – үзенә аталган кәләшне эзләү мотивы татар халкының батырлар әкиятләрендә сирәк очрый. Әмма әкият гадәттә геройның үзенә кәләш табуы һәм өйләнүе белән тәмамлана.

Батырлар турындагы әкиятләр – мифологик ышанулардан калган мотивларга һәм шуларга бәйләнешле эпизодларга яки сюжетка нигезләнгән әсәрләр. Гадәттә мондый төр әкиятләрдә вакыйга ике дөньяда – җир өстендә, ягъни бу дөньяда һәм теге яки үлеләр дөньясында бара. Герой Дию тарафыннан урланган патша кызларын эзләп шул дөньяга үтеп керә. Ул дөнья белән бу дөнья арасында гади кеше үтә алырлык юл юк, кемдер үтә алган очракта да,ул кире кайтмый. Икенче дөнья җир астында, су төбендә, дәрья аръягында, карурман эчендә яки тау артында урнашкан итеп тасвирлана. Бу ышану төрки халыкларның, шул исәптән татар халкының да космогоник карашлары белән туры килә.

Батырлар турындагы әкиятләрдә каһарман герой мифологик персонажга – Дию пәрие яки Аждаһага каршы көрәшә. Дию күп башлы, коточкыч зур гәүдәле, кеше ашап һәм, әйткәнебезчә, кешеләрне үз җиренә урлап алып кайта торган куркыныч зат итеп сурәтләнә (“Өч сарай”, “Баһадир Зәрәннек”, “Утыз ул”). Еш кына Диюләр магик көчкә дә ия, алар башка сурәтләргә керә ала. Җир астында, урманда яки тау артында яшәүче Диюдән аермалы буларак, әгәр шушы сыйфатларга ия зат су астында – дәрьядә яки күлдә яшәсә, ул, күпчелек очракта Аждаһа дип бирелә. Янә, Диюдән аермалы буларак, ул кызларны урлап алып китми, гадәттә аңа патшалыктагы һәм, чират җиткәч, патшаның үз кызларын корбан итеп бирәләр. Бу очракта герой теге дөньяга кызны коткарырга бармый, ә корбанын алырга килгән Аждаһаны үтереп, кызны коткарып кала (“Батыш исемле батыр турында әкият”).

Батырлар турындагы әкиятләрдә геройның төп дошманын ачык көрәш мәйданында җиңүе тасвирлана. Бу эпизод, бер әкияттән икенчесенә күчә барып, уртак эпизодка әйләнгән. Мәсәлән, “Таңбатыр” әкиятендә шушы көрәш тасвирламасының яхшы сакланган бер мисалы:

“Шуннан шобага салалар – кемгә алдан сугарга килеп чыга. Дию пәриенә алдан сугарга килеп чыга. Иң элек дию пәрие китереп бәрә

Таңбатырга. Таңбатыр тубыгыннан җиргә кереп бата. Аягын җирдән тартып алып, Таңбатыр сугып җибәрә тегеңәргә – дию пәриенең аягы тезеннән җиргә бата. Дию пәрие торып сугып җибәрә, Таңбатыр тезеннән бата. Таңбатыр яңадан сугып җибәрә, дию пәрие биленнән бата. Дию пәрие кабалана-кабалана чыга даТаңбатырга китереп суга, Таңбатыр биленнән бата, чыгарга тырышып карый – чыга алмый. Дию әйтә:

- Чык-чык, борча, ди, нишләп ятасың туфракта? – ди. Таңбатыр:

- Кайгырма, ди, борча чыгар ул, менә син ничек чыгарсың икән! – ди.

Шулай ди дә, бөтен көче белән бер селкенеп җибәрүе була, сикереп чыга бу. Дию каршына килеп баса да, кизәнеп, диюгә сугып җибәрә, дию муенынннан җиргә бата. Шуннан Таңбатыр әйтә:

- Чык, күсәк, ди, нишләп ятасың анда? – ди.

Дию пәрие тәмам хәлдән тая. Таңбатыр, кылычын алып, дию пәриенең башын өзеп төшерә, гәүдәсен өстерәп чыгарып, вак-вак итеп тураклый да әрдәнә итеп өеп куя".

Батырлар турындагы әкиятләрдә төрле чор катламнары сакланып калган. Иң борынгы чор әкиятләрендә геройның төп дошманы Дию, Аждаһа, Ялмавыз һәм үзе бер карыш, сакалы меӊ карыш дип аталган мифик затлар булса, стадиаль яктан соңрак чорга караган яки трансформацияләнүгә дучар булган әкиятләрдә төп дошман сыйфатында илбасар патшалар тасвирлана. Мәсәлән, "Алпамша"да исеме әлеге әсәр исеме белән туры килә торган төп герой һәм аның каһарман сыйфатларына ия булган хатыны Сандугач (вар. Карлыгач) үз җирләренә яу белән килгән чит патшага каршы көрәшәләр. "Алпамша" әсәре ( вар. "Алпамыш" үзбәк, каракалпакъ, казакъларда классик героик эпос-дастан жанрына карый торган версияләр рәвешендә сакланган. Татарларда исә, дастан сыйфатларын саклаган версияләр белән бергә, билгеле бер дәрәҗәдә әкиятләшкән, дөресрәге, дастан белән әкият арасында торучы эпик әсәр рәвешен алган вариантлар да бар. Менә шуңа күрә дә бездә әлеге әсәрнең бер үк вакытта әкияткә тартым дастан үрнәге буларак та каралу сәбәбе аңлашыла да.

"Дутан батыр" әкиятендә дә (сүз уңаенда әстик: казакъ фольклорында "Дутан батыр" әсәре, трансформацияләнмичә, дастан буларак сакланып калган) каһарман геройга ике урында ике тапкыр дошман явын кайтарырга туры килә һәм, булачак кәләше Көнекәйне алып кайту өчен, батыр ике патша белән алыша. Димәк, героик эпос-дастан сюжеты җирлегендә барлыкка килгән әлеге әкияттә дә геройның төп дошманы –явыз социаль типлар һәм баскынчы яулар.

Батырлар турындагы әкиятләрдә төп герой җиңүгә үзенең физик көче ярдәмендә ирешсә дә, аңа үзенең максатын тормышка ашырырга ярдәм итүче геройлар бар. Мондый герой улына ат һәм кораллар биргән ата булырга мөмкин. Еш кына батырның атасы үлгән булып, ат-коралларны ата кеше кабер сакларга яки дога укырга килгән кече улына тапшыра. Батырның юлдашлары да аның ярдәмчеләре була ала. Алар да табигый булмаган сәләткә яки көчкә ия батырлар буларак тасвирланалар. Ачыклап әйткәндә, мондый геройлар тиз йөгерергә, һава торышын үзгәртергә, ерактан күрергә, төз атарга һәм башка сәләтләргә ия итеп бирелә ("Дутан батыр", "Аю-Әппәз", "Кырык уллы кеше") һәм батырга нәкъ аларның ярдәме кирәк була. Юлда очраган карт, карчык һ.б. да геройга төрле ярдәм күрсәтә ала ("Аю батыр", "Утыз ул").

Татар әкиятләрендә геройга ярдәм күрсәтүче персонажларның тагын берсе – убырлы карчык. Бу образ – татар халык әкиятләрендәге иң популяр

мифологик образларның берсе. Исеменнән үк күренгәнчә, һәрчак тискәре образ булырга тиешле кебек, Әмма татар әкиятләрендә убырлы карчык берничә функция үтәргә мөмкин. Батырлар турындагы әкиятләрдә ул геройга юл күрсәтә, киңәш бирә. Герой эзләп барган Диюне яки кызны, кәләшне, югалган әйберне кайдан табарга икәнен өйрәтә ("Сихерле алма", "Турай батыр").

Төрле кошлар, ерткыч хайваннар да геройның ярдәмчеләре булырга мөмкин ("Батыш исемле батыр турында әкият"). Кошлардан Каракош, Сәмруг геройга, ике дөнья чиген үтеп, бу дөньяга кайтырга ярдәм итә. Гадәттә, герой әлеге кошның балаларын Аждаһа-еланнан коткарып кала. Шуңа рәхмәт йөзеннән кош геройны җиргә – кешеләр дөньясына кайтара ("Камыр батыр").

Батырлар турындагы әкиятләрдә без югарыда атаган персонажлар арасында геройның төп ярдәмчесе, әлбәттә, – аның аты. Ул, гади ат кына булмыйча, канатлы ат та булырга мөмкин. Хуҗасы кебек үк, мондый ат ике дөнья арасында сәяхәт итәргә сәләтле. Атның ярдәмче буларак функцияләре моның белән генә дә бетми, ул геройга киңәшләре белән дә ярдәм итә ("Баһадир Зәрәннек", "Дутан батыр").

Каһарманга Диюне җиңәргә булышлык күрсәтә торган тагын бер персонаж – герой коткарачак һәм өйләнәчәк кыз. Ул үлемсез Дию җаны кайда урнашканын белә, аны юк итәргә булыша. Яки геройга көч кертә торган су эчертә, шул рәвешле ярдәм итә.

Геройның туганнары, күпчелек очракта аңа каршы зыян эшләп, кече энеләренә дошманлык кылучылар рәвешендә тасвирлана. Кагыйдә буларак, алар геройны икенче дөньяда үләргә калдыралар.

Батырлар турындагы әкиятләрнең күпчелеге геройның үзенә кәләш табып өйләнүе, патша булып тәхеткә утыруы белән тәмамлана.

Сөйләгәннәргә нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: димәк, үзәгендә батыр-каһарман образы торган әлеге төр әсәрләр күпмедер дәрәҗәдә классик тылсымлы әкиятләрнең сыйфатларын да дәвам итәләр икән. Әмма шул ук вакытта алар эпосның каһарманнар әкияте дигән архаик төренә якынлыклары белән аерылалар. Чөнки мондый әкиятләрнең баш герое гиперболоик алымнар ярдәмендә үзе дә гаҗәеп батыр итеп сурәтләнә ("... күрешим дисә, кешенең кулын имгәткән, атланыйм дисә, атның билен сындырган" – "Турай батыр", "Әйгәли батыр ташны алып бер кыскан иде, су чыкты, икенче кыскан иде, таш комга әйләнде" – "Әйгәли батыр"). Дошманы белән көрәшкәндә, герой үзенең физик яктан да, рухы белән дә гадәти булмаган көчен янә дә раслый ("Дутан батыр дошман гаскәренең арасына ач арыслан шикелле барып керде. Кайсын кылыч белән чаба, кайсын аты белән таптата. Дошман явы Дутанның каһәреннән, кычкырган тавышыннан коты алынып кача башлады. Дутан батыр, артларыннан куа-куа, гаскәрне кырып бетерде" – "Дутан батыр". Яки: "Алпамша яр буенда яткан унбишәр-унсигезәр аршынлы бүрәнәләрне ала да күтәреп-күтәреп бәрә башлый. Шуннан соң патшаның бөтен гаскәрен тар-мар китереп ташлый. Бөтен кораллы гаскәрне бүрәнәләр белән бәреп, кырып бетерә" – "Алпамша"). Ахыр килеп, аның үзенә тәгаенләнгән кораллары да гаять зур ("Алпамшаның алмас кылычы бер селтәнүдә 60 чакрым ераклыктагы кешеләрне кырып сала, юкка чыгара иде" – "Алпамша", 1 нче вариант). Монда, билгеле, классик әкиятләргә хас тылсымлы предметларның урыны-урыны белән батырлар турындагы әкиятләргә дә яраштырылуы, рудимент-калдык сыйфатында булса да дәвам итүе сизелеп тора. Бу яктан, тылсымлы әкиятләрнең әлеге ике төре арасындагы чикнең чагыштырмача шартлы булуы ачыклана.

Батырлар әкиятләренең соңгы язып алынган вариантлары XX гасырның 60-70 елларына карый. Аларда тарихи вакыйгалар уңаеннан, яшәү рәвешенә бәйле рәвештә кергән үзгәрешләр дә очрый. Мәсәлән, соңгы вариантларда Камыр батыр Дию янына патша кызын коткарыр өчен бармый, Диюне алышып-көрәшеп түгел, маңгаена чиертеп үтерә. Таңбатыр исә кат-кат үзенең "кан коеп, көрәшеп алган җиңү"е турында искәртә. "Таңбатыр" әкиятенең "Өч сарай" дип аталган бу варианты 1950 елда Апас районының Олы Болгаер авылында язып алына. Бөек Ватан сугышы беткәнгә бары биш ел вакыт узган, әкиятче әлеге әкиятнең эчтәлеген сугыш вакыйгалары белән чагыштырып, халыкның сугыш тәҗрибәсенә бәйләп кабул иткәне яхшы сизелә. Җиңүнең кан кою исәбенә яулануын искәртү нәкъ шул хакта сөйли. Әкиятченең Диюне үтерүгә бәйле яңа элементлар өстәвендә әлеге мифик образның ул заманда үлем символына әверелгән фашизм яки Гитлер белән чагыштырылуы һәм аның юк ителүе чагыладыр кебек.

Йомгак ясап шуны әйтергә мөмкин. Батырлар турындагы әкиятләр тылсымлы әкиятләрнең бер төркемен хасил итә. Бу әсәрләрдә герой бары үзенең гадәти булмаган физик көче белән җиңүгә ирешә. Батырлар турындагы әкиятләрдә геройның эпик биографиясенә, балачагын тасвирлауга да урын бирелә. Аларның күп санлы вариантлары булуы, татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә таралуы әлеге әсәрләрнең популярлыгын күрсәтә.

## ӘДӘБИЯТ

Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. – Л.: Наука, 1974. С.222-224.

Неклюдов С.Ю. Богатырская сказка. Тематический диапазон и сюжетная структура // Проблемы фольклора. – М., 1975. – С.82-83.

Путилов Б.Н. Типология фольклорного историзма // Типология народного эпоса. – М., 1975. – С.168, 170.

Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б.98 – 102.

# О ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИИ И ПАРЕМИОЛОГИЧЕСКОМ ФОНДЕ ЯЗЫКА

## (ON CULTURAL LINGUISTICS AND PAREMIOLOGICAL VOCABULARY)

**Radif ZAMALETDINOV***
**Gulnara ZAMALETDINOVA****

**SUMMARY**

Author of the article examines the mechanisms of interaction in designing language world picture and paremiological vocabulary, which happens to be one of the options conceptualizing it.

The author describes the concept of the world picture focusing on the fact that the knowledge a man possesses about the world, exists in his mind in the form of a world picture. Different sciences study the language world picture. Its comprehension is achieved through semiotic, cultural and linguistic analysis. Cultural Linguistics is engaged into the research, as scientists are actively referring to the paremiological vocabulary of a particular language. This allows to reconstruct the most important stereotypes of national mass consciousness. Paroemias allow us to identify a culturally conditioned component of linguistic meanings, as well as to consider the cognitive mechanisms in forming most important cultural stereotypes. Paremiological units constitute the cognitive basis of the national language world picture. Turkic-Tatar paroemias account to over a millennial history. They represent a generalized centuries-old life experience of people, feature emotional evaluation of people’s actions and phenomena related to their activities.

Taking into account that paroemias feature folklore origin, they also share great heuristic potential for linguocultural research. For folklore is an important existence form of traditional ethnic culture, connecting different aspects of spiritual life, rituals and traditional types of labor activity of the people. In the meantime, borrowed paroemias present lesser heuristic value for Cultural Linguistics. As they allow us to draw conclusions to the aspects that are realized as a result of the translation of foreign cultural meanings rather than to a universal and a general human component of the national culture.

В 50-е годы XX века одним из магистральных направлений антропологической науки стало изучение картины мира, из которой впоследствии развилась когнитивная антропология. Концепция картины мира в рамках этой науки была сформулирована Р.Редфильдом. По его определению, картина мира – это видение мироздания, характерное для того или иного народа, представление членов общества о самих себе, своих действиях и активности в мире. Если концепция “национального характера” касается прежде всего взгляда на культуру со стороны внешнего наблюдателя, то картина мира, напротив, предполагает исследование взгляда представителя определенной культуры на внешний мир. С.В.Лурье отмечает, что “концепция “картины мира” подразумевает интерпретацию

* Prof., Kazan Federal University, Kazan.
** Assoc. Prof., Kazan Federal University, Kazan.

культуры, выявление оттенков, характерных только для нее, применении к исследованиям метода эмпатии (сопереживания)" (Лурье, 2003: 200).

Для того, чтобы изучить отдельную культуру, исследователю необходимо взглянуть на нее глазами носителей именно этой культуры и увидеть очевидные для него смыслы отдельных элементов этой культуры, связи между этими элементами, научиться говорить о культуре в тех категориях и с теми акцентами, которые естественны для носителя культуры. Именно этот ракурс осмысления культуры и высвечивает антропологическая парадигма в языкознании.

Языковая картина мира является одним из способов структурирования знаний об объективной действительности. Все знания человека о мире, полученные им в течение жизни, существуют в его сознании в виде картины мира, которая определяет отношение человека к реальности, оказывает влияние на нормы поведения, становление системы ценностей, социально детерминированных императивов и запретов, на стратегию жизнедеятельности и способы осознания человеческой субъективности.

Шамионова Рахимя Зиннятовна (1951 г.р.) из села Средняя Терешка Старокулаткинского района проинтонировала несколько мунаджатов, услышанных от своей матери, а также строфы из книги «Бәдәвам». В этой деревне сохранилась и широко используется местными жителями рукописная тетрадь с мунаджатами, среди которых «Ана васыяте» (наставление матери), «Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран» (жалоба матери), «Рамазан ае мөнәҗәте» (мунаджат, посвященный месяцу Рамазан), «Болгар мөнәҗәте» и другие. В этой же тетради был обнаружен текст книги «Бәдәвам».

Подобного рода рукописные тетради мы встретили и у жителей других деревень исследуемых районов Ульяновской области. Образцы разных жанров книжного пения активно исполняются в период мусульманских праздников, на встречах родственников во время поминовения усопших.

Полученные экспедиционные материалы, в настоящий момент находящиеся в стадии подробного анализа, расшифровки и нотации, планируются к дальнейшей публикации.

Изучение и сохранение для последующих поколений традиции книжного пения, музыкального фольклора татар-мишарей, обладающих неисчерпаемым богатством, позволит прочувствовать самобытные и общечеловеческие основы духовности всего татарского народа и его культуры.

**ЛИТЕРАТУРА**

Ахмаров Г.Н. О языке и народности мишарей // Известия общества археологии, истории и этнографии. – Т. XIX. – Вып. 2. – Казань, 1903. – С. 91-160.

Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы: Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Саранск, 2003. – 286 б.

Исхакова-Вамба Р.А. Татарское народное музыкальное творчество (Традиционный фольклор). – Казань, 1997. – 264 с.

Макаров Г.М. Дәрвишләрнең сөхбәтендә: бәетләр һәм мөнәҗәтләр. – Казан, 2011. – 159 б.

Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов: мишарский диалект татарского языка. – Москва, 1978. – 269 с.

Мухаметов И.Р. Книга Мухаммеда Челеби «Мухаммадия» в контексте татарско-турецких литературных взаимосвязей: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 2006. – 26 с.

Нигмедзянов М.Н. Народные песни волжских татар. – Москва, 1982. – 136 с.

Нургаянова Н.Х. Современное бытование жанра баита в традиционной культуре татар-мишарей Ульяновской области // Искусство и художественное образование в контексте межкультурного взаимодействия. Материалы VI Международной научно-практической конференции. – Казань, 2017. – С. 175-182.

Сайдашева З., Ярми Х. Татарско-мишарские песни. – Москва, 1979. – 77 с.

Сайдашева З.Н. Татарская музыкальная этнография. – Казань, 2007. – 224 с.

Сарварова Л.И. Музыкально-поэтическая культура татар-мишарей: к вопросу о стилевой специфике традиции // Истоки и эволюция литератур и музыки тюркских народов. Материалы международной конференции. – Казань, 2014. – С. 303-306.

Татарская энциклопедия: в 6 т. / Гл. ред. М.Х. Хасанов. отв. ред. Г.С. Сабирзянов. – Казань, 2008. – Т. 4: М. – П. – 768 с.

Шарифуллин Ш.К. Борыңгы халык моңнары. – Казань, 1988. – 21 б.

Шарифуллина Н.М. Мунажат как жанр в свете традиции книжного пения // Вестник КазГУКИ, 2014. – №4-1. – С.50-52.

Шарифуллина Н.М. Традиция книжного пения татар-мишарей Ульяновской области // Народная и профессиональная музыка Поволжья и Приуралья. Сборник трудов. – Москва, 1991. – С. 22-33.

Kovrikova E.V. and Nurgayanova N.Kh. Spiritual musical and cultural traditions of the tatars in the music of Shamil Sharifullin / 3rd International Multidisciplinary Scientific Conference on Social Sciences and Arts SGEM 2016, www.sgemsocial.org, SGEM2016 Conference Proceedings, Aug 24-31, 2016, Book 4 Vol. 3, pp. 63-70.

# TATARLARIN KULLANDIKLARI HAFTA GÜNLERİ ADLARI

# (DAYS OF THE WEEK IN TATAR LANGUAGE)

**Fanuza NURİYEVA***

**SUMMARY**

The article describes days of the week in Tatar language, their significance in people's lives. These names penetrated into Tatar language through the Muslim scholarship, Persian names for the days of the week became literary norm. There is diversity for the names of the week in dialects of Tatar language. Popular names present valuable material for covering cultural and historical issues in the regions where Tatars live. Was revealed the existence of various calendar systems in the different historical epochs among Tatars, which contributed to the use of Muslim and popular names of the days of the week. In the common language of Tatars, the peculiarities of counting the weekly time were preserved.

Zaman, insana doğrudan gözlem için verilmemiştir. Zamanın sırlarına ulaşmanın en önemli anahtarı dildedir, çünkü orada gündelik bilincin asırlık deneyimi yer almaktadır. Takvim birimlerini anlamlarına göre tanıtmak, netleştirmek ve onların sözlük tanımlarını tamamlamakla ilgili pratik değere sahiptir. Araştırma sonuçlarının sözlükçülükte uygulanmasının bir perspektifi "Tatar milli takvimi" sözlüğüne bahsedilen konuların dahil edilmesidir.

Eski Türk döneminden günümüze kadar ortak Türk zaman sistemi bulunmaktadır. "24 saatlik gün" düşüncesi yoktur. "Işıklı gün" - 'güneş' anlamındaki kün kelimesini, "gece" - tün kelimesinden ayrı düşünmüşler, gündüz ve geceleri ayrı olarak kabul etmişlerdir. Bütün bu kavramlar oldukça nettir, çünkü gece karanlık, gündüz - "tek güneş" olarak belirlenmiştir. Modern folklorda bulunan efsanelerdeki inançlarda bunlar 'doğan' ve 'ölen' canlılar olarak kabul edilmektedir (bugün bile Türk dillerinin hepsinde tog – 'doğmak' fiili güneş doğuşunu anlatıyor). Güneş sabah doğuyor, akşam ölüyor ve ertesi gün tekrar doğuyordu (Bazen, 1986: 361-362).

Eski Türk anıtları dilinde kün kelimesi iki anlamda kullanılmış: a) gün doğumundan batımına kadar olan zaman aralığı ve b) güneş.

Eski ve Orta dönem Türk anıtlarında kün kelimesi çoğunlukla gündüzleri ifade etmek için kullanılır. Orhun yazıtlarındaki kün 'gün', sadece *kün batsıq 'batı, gün batımı'*, *kün ortusy 'yarı gün tarafı, güney'* gibi sözcüklerde güneş anlamını taşımaktadır, eski Uygurcada kün 'gün', Maniheycede *künteṇri 'güneş tanrısı', MK 'güneş, gün'* (Mudrak, 1997: 77). Altın Orda anıtları dilinde ise *kün* kelimesi iki anlamda kullanılmıştır. Mesela: *Мәшриқ йолыны күн унутмыш (HŞ, 78s-19)"güneş Doğu'ya yolunu unutmuş"; түнне қарартып күнне йарутты (HŞ, 114s-11) "geceyi karalatıp, günü aydınlattı"; түни күни Хақ бирлә болсаң (NF, 65s-13) "gece gündüz Allah ile olursun";әгәр күн туғмаса йақты қылгай (MN, 29s-3)" güneş doğmazsa bile, dünyayı aydınlatır" vb.*

Tatar dilinin şivelerinde 'güneş'in anlamı bugüne kadar aktif kullanılmaktadır. *Kön 1*. miş., m.kar., t.ya., Iş., mam., içk., k.uf., şrl., sib. *koyaş* "güneş": *Көнгә чыгып йөрмәсәң, өйдә утырган кеше шулай инде. – шрл. Көн*

* Prof., Dr., Kazan Federal University, The Republican Center for Development of Traditional Culture

*пешергән, тенә печән йийгаг. – лмб. Карыйм айга, карыйм көнгә, карыйм таң йолдызына. – тмн. Иртә көн чыга, кич төшә. – м.кар. Көн цыкмаган әле. Алар көнгә пешмәгәннәр. – эчк. Көн туганда эшкә китәбез. Көн байыр чакта кайттык кисә. – к.уфм.* һ.б. (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 327). Tatar edebi dilinde kön 'gün' anlamına gelmektedir ve gün doğumundan güneşin batımına kadar olan zamanı yansıtmaktadır.

Makalede Tatarcada hafta günlerinin adları, insanların hayatında onların taşıdıkları önemi ve dilde önemli bilgiyi toplamış oldukları yansıtılmaktadır.

Türk dillerinde hafta günleri adlarını karşılaştırmalı şekilde A.N. Samoyloviç, K.M. Musayev araştırmışlardır. Tatar dilinde haftanın günleri H.Gali (1912), L. Zalyay (1947), V.M. Berkutov (1987), H. Badigi (2001), T.H. Hayretdinova (2004) araştırmalarında yer almıştır.

Türk dil biliminde A.N. Samoyloviç ilk olarak, haftanın günleri adlarının ortaklığı nedeniyle birçok alanlar tespit ederek Türk dillerinde haftanın günleri adlarıyla ilgili ilk sınıflandırmayı yapmıştır. Türk dillerinde hafta günlerinin müslüman adları Kaşgarlı Mahmud'un sözlüğünde yer almıştır. Kaşgarlı, önceden Türklerde haftanın herhangi bir günü yoktu, hafta İslam'ın gelişiyle bilinmeye başladı diye yazmıştır. A.N. Samoyloviç te araştırmalarında bunu anlatıyor: «Orta Asya'daki Türk halkları İslam'ın gelişi ile Farsça aracılığında müslüman hafta günleri adlarını özümsemişlerdir: Cuma *adina, azina,* Cumartesi *şembe,* Pazar *yek-şembe,* Pazartesi *dü-şembe,* Salı *se-şembe,* Çarşamba *çar-şembe,* Perşembe *penç-şembe* (Samoyloviç, 2005: 259). Tatar edebi dilinde hafta günleri bugüne kadar neredeyse hiç değişmemiştir, sadece önceden kullanılan Cuma yerine Arapçadan '*jomga*', hafta anlamında *'atna'* kelimelerini kullanmaya başlamışlardır.

V. M. Berkutov araştırmalarında Tatarların farklı tarihi dönemlerde farklı takvim sistemlerinin varlığını ve bunun da onlarda iki farklı (müslüman ve milli) hafta günleri adlarının kullanılmasına yol açmasını göstermektedir (Berkutov, 1987: 20). Gerçekten, Tatar dilinin şivelerinde edebi kullanılışta olan hafta günlerinden bir süre sapmalarını bulabiliyoruz. Milli adlar, Tatarların yerleştiği bölgelerde kültür ve tarih konularını yansıtmakta zengin kaynak olmaktadırlar.

'Düşembe', yani Pazartesi edebi Tatar dilinde haftanın ilk günü anlamına gelmektedir, konuşma dilinde ise bu kelimenin fonetik değişkeleri olan *teşenbe (lmb.), töyşembe (sib.)* bulunmaktadır. Şivelerde ise *'başken', 'tuganken'*. 'tündi' varyantları vardır. Mesela, *başken* miş., trh. *düşembe. Сез башкендә бездә булырсызмәле* – мәл. *Башкеннеме сың килделәр, бушкенгә китмә келиләр* (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 105). Başkön miş., trh., perm., astr. düşembe. *Йулга башкөн чыксаң яхшы инде* (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009:106). Туганкөн *перм.* (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 651). "*yeni doğan gün*". 'Başken' kelimesinin kökenini H. Gali haftanın başlangıcı ile bağlar (Gali, 1912: 13). *Baş* kelimesi *baş* ve *başlangıç* anlamlarında kullanılmaktadır. Tam olarak, A.N. Samoyloviç ilk günü "Ebeveyn Günü" olarak belirler (Samoyloviç, 2005: 403; Berkutov, 1987: 23). Dağ tarafında yaşayan Podberezinsk Kreşin Tatarlarında eski 'tundi kön' adı korunmaktadır (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 160). Anlaşılan, bu isim de 'baş, büyük, ilk gün' anlamına gelmektedir. Türk dillerinde "ilk, ilk doğan" anlamında kullanılan eski kelime "tun" (alt. "tun pala") bilinir (Berkutov, 1987: 23). Benzer bir model, Çuvaş dilindeki tünti kon "yeni doğmuş bir gün" anlamında bulunur. İdil Bulgarları'nın mezar taşı yazıtlarında Ärnä Baši, «haftanın başlangıcı, yani Pazartesi" kelimesi bulunmaktadır (Hakimzyanov, 1978: 84). Diğer birçok Türk dillerinde Pazartesi haftanın başlangıcı olarak belirlenmiştir: Kar.g. yihbaskin, Kar.t. yehbaşkün, Kar.k., Kbalk. yuhbaşkün, (cp. k.balk. ıyık hafta) (Musayev, 1975: 270).

Tatar edebi dilinde haftanın ikinci günü olan Farsça 'sişembe' yani Salı günü, konuşma dilinde 'şişembe' olarak kullanılmaktadır. Genel Türk adlandırmalarında 'boş gün', 'atlangan gün, 'utlarigün' şeklinde geçmektedir. 'Boş gün' kökeni ile ilgili olarak H. Gali eskiden insanlar, haftada bir gün mutsuz gün (yaman kün) olduğuna inanmışlar, o gün hasat toplamamalı, ekim başlamamalı, uzun yolculuğa çıkmamalıymış vb. diye belirtmiştir (Gali, 1912: 13). Bilgilere göre bizim günlerimizde de Salı günü önemli işler yapmak için kötü bir gün sayılmaktadır. Mesela, *ker yuarga kaytsam, bögen boş gün iken* (Hayretdinova, 2004: 364). Perm ve Kreşin ağızlarında Salı gününü anlatmak için "atlangan gün, atlaңgaңgün" (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 62), "utlarigün" (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 686) kelimeleri kullanılmaktadır. V.M. Berkutov N.I. Aşmarin görüşüne dayanarak *utlari* kelimesinin atın eski bir adı olma ihtimalini göstermektedir (Berkutov, 1987: 23). Salı gününü böyle bir adlandırma Çuvaşlarda 'ıtları kun', ata binildiği bir gün olarak korunmaktadır (Fedotov, 1962: 225-256). Türk dillerinde Salı gününü anlatan büyük bir çeşitlilik vardır: Kar.t. *orta kun,* Kar.g. *orta kin,* Karaç. *gurge,* Balk. *geuurge kun*, Kumuk. *talatgun,* Ktat., Kar.k. Salı vb. (Musayev, 1975: 271).

Tatar edebi dilinde *çerşembe "çarşamba"* haftanın üçüncü gününü temsil etmekte, konuşma dilinde *çerşenne* Srg. (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 502) kelimesi de bulunmaktadır. T.H. Hayretdinova'ya göre, coğrafik veya dini ayrılmış tatarlarda (Perm, Kreşin) Çarşambanın Mecusi gelenekleri yansıtan adları kalmıştır: Perm- 'gankün', 'kankün', Mordvin-Karataylarda 'kankün', Kreşinlerde 'kankün, yani kanlı gün olarak geçmektedir (Hayretdinova, 2004: 365). İdil Bulgarları'nın mezar taşı yazıtlarında Çarşamba *'hankün'* olarak adlandırılmıştır. F.S.Hakimzyanov görüşüne göre bu Mecusi kurban kesme geleneğinden geriye kalan adlandırmadır (Hakimzyanov, 1978: 83). Kan / han kelimelerini görünümlerine göre etymologize edersek, kan kelimesini temsil ediyor diyebiliriz, çünkü eski Türk kavimlerinin dilinde Çarşamba 'kanlı gün' olarak adlandırılmıştır. Böyle bir adlandırma bugüne kadar Çuvaşlarda *yun kün*, Başkurtlarda ise *kan kün* olarak korunmuştur. Çarşambanın 'kanlı gün' anlamına gelen benzer ismi Mordvinlerde 'verji', Marilerde 'vurgeçe', Udmurtlarda 'virnunal' olarak kullanılmaktadır. Araştırmacılar bu tesadüfleri Orta İdil boyunda ortak dini ve mitolojik inanç ve takvim varlığı ile açıklar. Bu inançlar Hazar Hanlığı'nın dönemine, uzak geçmişe aittir, Karaim. *kan/han kun*, *hayın kun,* Arm.-Kıpç. *han kyn* 'kanlı gün' (Musayev, 1975: 272-273; Hakimzyanov,1978: 83-84; Fedotov, 1962: 168). Bazı Tatar agızlarında Çarşamba gününü böyle adlandırma atalarının Mecusi geleneklerinde kurban kesme geleneği olması ile anlatılmaktadır. Mesela, Kazan ilinin Mamadış ilçesinde yaşayan Kreşin Tatarları tarafından sıyır kurmanı (kurbanlık dana) ve koyun kurmanı (kurbanlık koyun) yapılmaktadır (Magnitskiy, 1881: 28).

Tatar edebi dilinde haftanın dördüncü gününü anlatan Farsça 'Penceşembe' yani Perşembe gününün Sibirya şivelerinde *peyşembe* fonetik değişkesi de kullanılmaktadır. Konuşma dilinde 'atna kiç', keçe atna' varyantları kullanılmaktadır. Birinci bileşen 'keçe' 'küçük'+atna kelimesi ise Farsça 'Cuma'dan alınmıştır. Örnekler: atnakiç dua edeceğim. İdil Bulgarları'nın mezar taşı yazıtlarında Perşembe 'küçük cuma günü' olarak adlandırılmaktadır. Perşembe gününün böyle adlandırılması Başk. *kese azna,* Çuv. *keçen erne,* Karaim. *kitserne* olarak karşılaştırılabilir.

Arapçadan Cuma anlamını taşıyan 'jomga' Tatar edebi dilinde haftanın 5. gününü anlatmakta, şivelerde *yoma, joma* varyantları kullanılmaktadır. Konuşma dilinde (Mişer şivesinde) atna kön (hafta günü) kullanılmaktadır: *Атна көнгә*

*каршы кечатна җуwам идән-сәкеләрне һәрвакыт; Мин атнакөн төштем, базар түгел..* Kreşinlerde Cuma 'Tatar atnası' (Tatar Cuması), 'olo atna' (büyük Cuma) olarak adlandırılmaktadır. Kazan Tatarları Cumayı 'atna' (hafta) ya da 'jomga' (Berkutov, 1987:24; Hayretdinova, 2004: 366) olarak adlandırmaktadır. Günümüzde Tatar edebi dilinde 'atna' kelimesi bütün hafta, yani yedi günü (haftayı) içeren sayım anlamında kullanılmaktadır. Kırgızlar haftayı 'jeti kun', Farslar ve Özbekler 'hafte' (yedi anlamındaki 'haft') olarak adlandırmışlardır. Bu, eskiden Tatarların hafta sayımını Cumadan Cumaya yaptıklarını doğrulamaktadır (Berkutov, 1987: 24). İdil Bulgarları'nın mezar taşı yazıtlarındaki *ärnä kön* Farsçadan 'adina' kelimesinden alınmıştır. Farsçadan gelen *adina* bazı dillerde Cuma anlamını taşımaktadır: Or.Çuv. ernekun «cuma», Tat. *atna kön*, *olo atna* «büyük Cuma», Mar. *kugu arnya* «büyük Cuma», Karaim. aynya kin. Böylece Bulgar ve Hazar Hanlıklarının olduğu yerlerde Cuma gününün adlandırılması aynıdır sonucuna varılabilir. 'Atna' kelimesinin 'hafta' anlamına kadar genişlemesi nispeten geç bir görüngüdür (Hakimzyanov, 1978: 84).

Farsçadan '*Cumartesi'* anlamını taşıyan *şimbe*, Tatar edebi dilinde haftanın altıncı gününü anlatmakta, Sibirya şivelerinde *şembe* fonetik değişkesi de kullanılmaktadır. Konuşma dilinde 'atna yartı' (hafta yarısı), 'cıma artı' (cuma ertesi), yoma artı (cuma ertesi) şeklinde kullanılmaktadır. 'Atnarası' yani hafta arası anlamında Mişer ve Astrahan ağızlarında yayılmıştır. Perm ve Krasnoufimsk Tatarlarında 'korokön', Mordvin-Karataylarda 'arakön', minz. - 'bazar aldı' (Pazar öncesi) kullanılmaktadır (Hayretdinova, 2004: 368). Pazar günü anlamına gelen Farsça 'Yekşembe' kelimesi, Tatar edebi dilinde haftanın 7. günü anlamında kullanılmaktadır. Şivelerde *jeksembi* fonetik varyantı, konuşma dilinde 'baş kiç', 'bazar kön', ursatna (Rus haftası) kullanılmaktadır. Ср: *Башкиц якшәмбе кич. Башкиц базар кен киңбула ул, башкен алды. Башкич* (чст., чпр.) якшәмбе. *Баш кич, атнакичне үтеләр йөри торган көн диләр (*чст.) *Урсатна көн ялмы сездә дә* (тмн). *Базар бәр. якшәмбе көн, базар көн Базар саен мунча йагадырыйык* (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 2009: 105).

A.N.Samoyloviçin ortaya koyduğu gibi müslümanlarda Pazar 'bazar könö' (Pazar günü), yani gezme günü Hristiyan etkisiyle açıklanabilir (Samoyloviç, 2005:264). A.N.Samoyloviç Kasimov Tatarlarında 'bazar könö' (Pazar günü) Perşembe, Kazan ili Spassk ilçesi ve Sember ili Buinsk ilçesinde yaşayan Mişerlerde ise Çarşamba olarak kullanıldığını belirtmiştir (Samoyloviç, 2005: 263).

Tatar konuşma dilini öğrenmek hem milli hafta günlerinin adlarını hem de hafta günlerini sıralama özelliklerini açıklamaya yardım etmektedir.

Tatar dilinde hafta günleri hakkında yapılan araştırmalar Tatar edebi dilinde hafta günlerinin Farsça adlandırılmış olduklarını göstermektedir. Hafta günlerinin böyle adları bugüne kadar yazılı anıtlarda korunmaktadır. Böylece, Tatar dilinde, haftanın yedi gününün adlandırılması vardır. Tatar diline İslam eğitimi, yani din, kültür, edebiyat ile geçmiş olan müslüman hafta günlerinin adları edebi bir dil statüsünu almıştır.

İdil Bulgaristan'ı epigrafik anıtlarında, Tatar dilinin şive ve ağızlarında hafta günleri adlarının Farsça adları ile birlikte tarihsel gelişim sürecinde gelişmiş milli adları da kullanılmaktadır. Araştırmacılar Tatarlarda İslamiyet'i kabulünden sonra haftanın Cumadan Cumaya olduğu konusunda hemfikirdirler. Böyle zaman bölümü 'atna', yani hafta olarak adlandırılır. 'Atna', yani Cuma kelimesinin anlamı Eski Türkçedeki *adina* 'Cuma', *adina namazi* 'Cuma namazı' (Tatar telenen zur dialektologik süzlege, 1969: 11) ve Tataristan'ın Chistopol bölgesi Tatar Tolkiş köyü yakınında bulunan mezar taşındaki Bulgarca *ärnä kőn* (1348) ile denk gelmiştir (Hakimzyanov, 1978:142-143). Tatar dilinin Orta şivesinin bütün

ağızlarında atna kiç, keçe atna ‘Perşembe’, atna kön ‘Cuma’ kelimeleri sistematik şekilde korunmuştur. Hafta günlerinin bazıları Hazar Hanlığı dönemi ile bağlantısını korumaktadır, mesela, *kan/han kun ‘kanlı gün’.*

Eski Bulgarlar Eski Türk döneminde bile haftanın ortası olan 3. günü Çarşamba (Mişerlerdeki bazar kon, yani Pazar günü) olarak adlandırmış olabilirler. Bu, eskiden Tatarların atalarında haftanın yedi günlük değil, sadece beş günlük olduğunu göstermektedir. Böyle zaman sıralaması muhtemelen yavaş yavaş kullanılmaya başlanmıştır, ilk olarak takvim beş, sonra ise yedi günlük haftalardan oluşmuş olabilir.

## KAYNAKÇA

Ahmetyanov R.G. O drevnem agrarnom kalendare narodov Povoljya i Priuralya. ‘Tezisı dokladov itogovoy nauçnoy sessii za 1972 god’ – Kazan, 1973. -S. 45-48.

Bazen L. Kontseptsiya vozrasta u drevnih tyurkskih narodov// Zarubejnaya tyurkologiya. Vıp.İ. Drevniye tyurkskiye yazıki I literature. M., 1986.- S. 361-378.

Berkutov V.M. Narodnıy kalendar i metrologiya bulgar-tatar. – Kazan: Tat. knij. izd-vo, 1987. – 95 s.

Gali H. Yıllar, aylar ve könner// Şura. 1912. - № 13.

Magnitskiy V.K. Materialı k obyasneniyu staroy çuvaşskoy verı. Kazan.- 1881. – 28 s

Malov E.A. Svedeniya o mişaryah. – 1884, t.4, s.52.

Mudrak O.A. Vremya, otrezki vremeni, sezonı// Sravnitelno-istoriçeskaya grammatika tyurkskih yazıkov. Leksika. M.: Nauka, 1997. – s. 67-84.

Musayev K.M. Leksika tyurkskih yazıkov v sravnitelnom osveçenii. M., 1975. – s. 268-283.

Nurıeva F.Ş. Xesen Gali yazmalarında Tatarça ay atamaları // Idel buyı xalıkları tradizıon medeniyeti. 2018.- b.282-288.

Samoyloviç A.N. Tyurkskoye yazıkoznaniye. Filologiya. Runika. M.: Vost.lit., 2005.- 1053 s.

Tatar telenen zur dialektologik süzlege/ töz. F.S. Bayazitova, D.B. Ramazanova, Z.R. Sadıkova, T.H. Hayretdinova. – Kazan: Tatar.kit.neşr., 2009.- 839 s.

Tatar telenen zur dialektologik süzlege.- Kazan, 1969. – 644 s.

Fedotov M.R. O nazvaniyah dney u çuvaşey// Uçenıyı zapiski ÇNİİ. – Vıp. – Çeboksarı, 1962.

Hayretdinova T.H. Tatar tele dialektlarında atnadagı kön isemnere// İnsani fenner: ezlenü hem tabışlar. – Kazan: Fiker, 2004. - s. 363-369.

Hakimzyanov F.S. Yazık epitafiy voljskih bulgar. – M., 1978. – s. 83-84.

# Г. ИСХАКЫЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТЕЛЕ: ЭЧЕМЛЕК АТАМАЛАРЫНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

## (THE LANGUAGE OF THE WORKS OF G. SHAKY: FEATURES OF THE USE OF THE DRINKS NAMES)

**Raushaniya NURMUKHAMETOVA***

## SUMMARY

Folk experience of making drinks like folklore is passed down from generation to generation. Since ancient times, people made a variety of thirst-quenching, refreshing, invigorating drinks. Popular tatar drink is tea, also in various cases they made sherbet, sosla, kvass, etc. Mention of some occurs even in some ancient written monuments and dictionaries of past centuries. Despite the fact that food, especially drinks, is not very often the subject of inspiration of Tatar writers, there are works in which the theme of the food plays an important role. The mention of food, the description of the dinners, breakfasts, and holiday feasts tells us about the life and customs of the time, according to this we can trace the history of food culture. This article examines the names of drinks based on the works of the outstanding Tatar writer G. Ishakki. The source of collecting factual material to the article were novels and short stories written by G. Iskhaki in the period 1912-1916., namely "Sunnetche babay" (Performer of rites), "Kiyew" (in-law), "Ul ikelene ide" (He doubted), "Ostazbike" (the Wife of the Mullah), etc. No one reader can remain indifferent to the features of Tatar tea drinking, national ordinary and festive table of Tatars described in vivid examples which give a rich reliable material for scientific research.

Мәгълүм булганча, сыеклык кеше организмы өчен гаять мөһим. Аның бөтен тереклек дөньясында беренчел дәрәҗәдә әһәмияткә ия булуын һәркем аңлый, шуңа да ул ризык белән бергә йөри, бергә кулланыла. Татар телендә туклану әйберләре атамаларын җыеп атау өчен нәкъ менә *аш-су, ашамлык-эчемлек, ашау-эчү* кебек сүзләр йөрүе дә шушы фикерне дәлилли кебек.

Гомумән алганда, **эчемлек** – эчү өчен махсус әзерләнгән сыеклык (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 714). Сүзнең тамыры – “эч-”, ул, Р. Әхмәтьянов фикеренчә, “эч” (теләсә кайсы әйбернең эчке өлеше мәгънәсендә) сүзенең корреляты дип карала, ягъни *эчү – эчкә алу* дигән сүз (Әхмәтьянов, 2015: 516). Галим әлеге фигыльнең күп кенә төрки телләрдә очравы турында да әйтеп үтә.

Эчемлек атамалары татар телендә бик күптән барлыкка килгән. Мисал өчен, Алтын Урда чоры язма истәлекләрендә шул мәгънәдә “ичим” сүзе һәм башка кайбер эчемлек атамалары кулланылган (Нуриева, 2015: 245). XIX гасыр сүзлекләрендә дә *эчемлек* сүзе белән беррәттән, эчемлекләрне белдергән күп кенә сүзләр теркәлгән (Юсупова, 2008: 158). Әлеге атамалар без тикшергән сүзлекләрдә һәм хезмәтләрдә дә урын алган (Нурмөхәммәтова, 2009: 87).

Төрле эчемлекләр әзерләүгә караган халык тәҗрибәсе, фольклор кебек үк, буыннан буынга тапшырылып килә. Әлеге аш-су атамаларын,

* Candidate of Philology, Kazan Federal University, Kazan.

мәгълүм классификацияләр буенча, исерткеч һәм исерткеч булмаган төрләргә бүләләр.

Элек-электән татарлар сусауны баса, ризыкны тәмләндерә, бәйрәм табынын күркәмләндерә, кәефне күтәрә торган эчемлекләр әзерләгәннәр. Шуңа бәйле рәвештә, бу хезмәттә дә эчемлек атамалары икегә бүлеп каралды һәм фактик материал Гаяз Исхакыйның XX гасыр башында иҗат иткән әсәрләре («Сөннәтче бабай» (1912), «Кияү» (1912), «Ул икеләнә иде» (1914), «Остазбикә» (1915), «Кәҗүл читек» (1916)) буенча барланды (Исхакый, 1998). Әлеге эштә татар теле лексикасындагы «Ризык» лексик-семантик төркеменең «эчемлек атамалары» сегменты формалашуга караган нәтиҗәләр ясау өчен ныклы дәлилләр тупланды.

Алкогольсез эчемлек атамаларыннан Г. Исхакый әсәрләрендә иң күп кулланылганы – **чәй**. Бу аңлашыла да, татарлар элек-электән һәм хәзер дә чәйне иң күп һәм яратып эчүче халыклардан санала. Татар халкында чәй эчү белән бәйле күп кенә үзенчәлекләр бар, аларның кайберләрен язучы шактый киң яктырткан (алга таба әсәр исемнәре кыскартып биреләчәк: «Сөннәтче бабай» – СБ, «Кияү» – К, «Ул икеләнә иде» – УИИ, «Остазбикә» – О, «Кәҗүл читек» – КЧ):

- чәй эчү ризык кабул итү, ашау вакытын да билгеләп белдерә (иртәнге чәй, көндезге чәй, аулак чәе һ.б.): Ирләр *чәй* эчәргә утыргач кына, кодагыйны югары өйгә алып менгәч кенә, ул ярыктан беренче мәртәбә карады (О). Иртә белән *чәй*гә утыргач та тагын шул уй башка төшеп, Сәгыйдәне куркытып йибәрде (О). Яхшы каршы алдылар, белен берлән *чәй* эчерделәр (СБ). Кунаклар янына *иртәнге чәй*гә ак он сумсасы, ак он коймагы белән муллалар да чакырылды (К). *Чәй яны*нда да Садыйк абзый бик йомшак кылынып, йомшак сүзләр сөйләнеп утырды (К);

- татарлар элек-электән *кара чәй*не яратып эчкәннәр, әмма Г. Исхакый әсәрендә *яшел чәй* атамасы да күзгә чалынып китте: <…> Ишан хәзрәт килгәндә генә бер-ике бөртек кенә салына торган *яшел чәй*дән ярты кадак кына чәй... (К). Мисалдан аның ул вакытта кадерле, сирәк кунакларга гына куела торган бик затлы чәй булуы аңлашыла;

- *чәй* сүзе төрле йола атамалары составында да очрый (килен чәе, кияү чәе, бәби чәе, чәй мәҗлесе һ.б.): Сәгыйдә тын алырга, хәл җыярга өлгермәде, "бисмилла" дип бер ягыннан олуг тутасы, икенче ягыннан карт җиңгәсе тотып, аны кодагыйларның *чәй мәҗлесе*нә китереп бастырдылар... (О). Икенче көнне иртүк *кияү чәе*нә Сәгыйдәне алырга килгән атка утырып баргач... (О);

- татарларда чәйгә аерым урын хәстәрләнә (чәй урыны, чәй өстәле / табыны): Озын өстәл өстенә *чәй урыны* хәзерләнгән (УИИ). Кызлар укып бетергәч, абыстай *чәй урыны*н үзе хәзерли (О);

- чәй суы аерым чишмәдән алып кайтыла (чәй суы): Кайсылары күрше Закир бабай коесыннан абыстайның сыерларына су китерәләр; кайсылары ындыр арты чишмәсеннән мулла абзыйга эчәргә *чәй суы* алып кайталар (О);

- чәйне бал, җимеш, лимон белән, сөтләп һ.б. эчәләр: Әни чәй ясады. Әти бал кашыгым белән *бал* алып бирде (КЧ). Атны җигеп, хәзрәткә дип бер савыт *кәрәзле бал* алып, юлга чыктым (СБ). <…> Җәймәләр уртасында зур бер калай савытта ап-ак *бал* (УИИ). Иң ахырдан ясап чыгарылган *лимунлы чәй* бирелде (К). Кайнаган самавыр алдында карчыгыны *йимешләп чәй* эчкән көенчә тапты (СБ). Картка бер сүз дәшмәенчә, *кәҗә сөте* алып кереп*, чәенә салып* эчә башлады (СБ). Мәтрүшкә чәе авырганда дәва буларак кулланыла: Күрше Гадилә әби берлән бергә самавыр куеп, *мәтрүшкә* дә эчертте (СБ);

- чәй янына өйдә пешерелгән күптөрле татлы камыр ашлары куела: Чәй янына баягы *как-төш* чыгарылды (К). Ике якта, ике тәрилкәдә катырылган *как-төш*. Икешәр тәрилкәдә *кош телләре* (УИИ);

- язучы әсәрләре буенча хәллерәк кешеләр табынына кибеттән алынган тәм-томнар (конфет, варенье, мармелад, сохари һ.б.) куела башлавын искәртергә була: Пөхтә генә чынаяклар тулы поднос, өстәл янына бер-ике тартмада *кәнфит*ләр, *мармалад*лар. <…> Берничә савытта *варенье*лар. Бер тәрилкәдә *сохари*лар, бер тәрилкәдә базар *печение*се. Садыйк үзе аның алдына *мармалад*ны төртте. Хәмитнең алдында чәкчәк торса да, аны читкәрәк алып, бер ягына *сохари*, бер ягына *печение* куйды. Балны үз алдынарак тартып, аллы-гөлле *помада*ны Хәмиткә таба йибәрде. Искергән *пирожный*лар килде. Хәмит үзе барып бер савыт *шикалад* та алып килде (УИИ). Әти миңа *перәннек* тә алып кайта (КЧ).

Башка төр алкогольсез эчемлек атамаларыннан ешрак очраганы – төрле **җимешләрдән ясалган сулар**, алар, контекст буенча фикер йөрткәндә, компот, сок мәгънәләренә туры килә булса кирәк: Әле бит муллаларда аш артыннан бер *тәмле су* бирәләр? Шуны мин Фәридәдән сораштым, ул коры *чия* икән (К). Аштан соң мулла хатыны кеби иттереп *йимеш суы* ясарга кирәк (К). Кияү сыйларга алган мискидә элгәре пилмән китте, <…> аннан соң *чия суы* (К).

**Кофе, шоколад (какао)** кебек эчемлек атамалары Г. Исхакыйның без тикшергән әсәрләрендә сирәк очрый, әмма аларның шәһәр татарлары тормышына керә башлавы күренә: *Кофе*мы, *шикалад*мы, чәйме? Менә барысына да *кофе* килде. *Кофе*ны акыртын гына эчтеләр (УИИ).

**Ширбәт** сүзе хәзерге татар телендә ике мәгънәдә йөри: җиләк-җимештән әзерләнгән татлы су һәм җиләк-җимеш кушып ясалган исерткеч эчемлек, кызыл аракы (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге, 2005: 683). Тикшерелгән әсәрләрдә дә ул шушы мәгънәләрдә очрый: Тагы, мулла-мөәззин белән булышкач башкача: *ширбәт*е, катламасы гына йитми... (К). Телне чеметеп ала торган гына, баллы гына бер ачы *ширбәт* (УИИ).

Исерткеч эчемлекләрне гомумиләштереп атау өчен дә татар телендә **эчемлек** сүзе кулланыла. Шунысын да әйтергә кирәк, хәзерге татар телендә әлеге сүз күбрәк нәкъ менә алкогольле эчемлекләрне күздә тота. Элегрәк исә аларны аеру өчен *эчке / ычкы, эчкелек* сүзләре йөргән. Озын өстәлнең ике башында да әллә никадәр *эчемлек* шешәләре эчләрендәге кызыл, ак, саргылт төсләре белән, шешәләрнең төрле-төрле хәҗемдәге кыяфәтләре белән ашъяулыкны төрлеләндереп торалар. Алар янына тезелгән озынча бокаллар, кечкенәле-зурлы рюмкалар, эчләренә *төрле төстә эчемлекләр* тутырылган графиналар аш янында ярышып торалар (УИИ).

**Сыра** – арпа салатыннан ясала торган җиңелчә исерткеч эчемлек (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 2005: 494): Читтә генә бер өстәлдә, поднос өстенә стаканнар куелып, ун-унбиш бутылка *сыра* да хәзерләнгән (УИИ). Мулла-мөәззин белән катышкач, куас-*сыра* пешерү затсызлык була инде (К).

**Сосла** – үрдергән ашлыкны киптереп тартып, шуның онын пешереп ясаган йорт сырасы (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 2005: 478): Шул арада ишек алдына чыгып, Сөннәтче бабай да зур аякларда *сосла* күтәреп кереп: “Бәлки, хәзрәт, яратырсыз”, – дип, хәзрәтләр өчен ясаган *сосла*сыны суза иде. Бәлеш ашала, *сосла* эчелә иде (СБ).

**Квас / куас** – арыш ипиен кызарганчы киптереп, шуннан махсус ясалган эчемлек (Татар теленең аңлатмалы сүзлеге 2005: 245, 290). Бу

эчемлек татарларга рус халкыннан кергән, ул русларның элек-электән килгән, ятатып куллана торган эчемлеге. Ул шулай ук эчерткеч эчемлекләрдән саналган, төрле квасларда алкоголь күләме 1,2-2,0% тирәсе булуы билгеле. Тикшерелгән әсәрләрдән дә ул исерткеч эчемлек буларак аңлашыла: Су дисәң су түгел, *куас* дисәң *куас* түгел... Лимонлы, шикәрле, тагы әллә ниле бер ширбәт (УИИ). Мулла-мөәззин белән катышкач, *куас*-сыра пешерү затсызлык була инде (К).

Шул рәвешчә, Гаяз Исхакый әсәрләренең телендә очраган аш-су лексикасының "эчемлек атамалары" сегментын барлаганнан соң, XX гасыр башы татар телендә актив кулланылышта булган, яисә кулланылышка кереп килә торган эчемлекләр һәм аларның атамалары турында тиешле нәтиҗә ясарга була: ул чорда яшәүче татарлар чәйне яратып эчкәннәр, аерым бер вакыйгалар уңаеннан ширбәт, сосла, квас һ.б. кайнатканнар. Кайбер яңа төр эчемлекләр (кофе, шоколад, сыра) күренә башлаган һ.б. Ризык, эчемлекләр темасы Г. Исхакыйны әллә ни кызыксындырмаса да, сирәк кенә очраган атамалар, бәйрәм табыны, йолаларга бәйле күренешләр әдип яшәгән заманның көнкүрешен, кешеләрнең әхлакый йөзен һ.б. тасвирлап кына калмый, татар халкының туклану культурасы тарихын күзәтү мөмкинлеге дә бирә.

**ӘДӘБИЯТ**


Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең этимологик сүзлеге: Ике томда. II том (М-Я). – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2015. – 567 б.

Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 464 б.

Нуриева Ф.Ш. Названия пищи в тюркоязычных письменных памятниках золотоордынского периода // Филологические науки. Вопросы теории и практики. – 2015. – № 7-1 (49). – С. 143-146.

Нурмөхәммәтова Р.С. XX гасыр башы татар телендә азык-төлек һәм эчемлек атамалары (татарча-русча сүзлек материалы буенча) // Филологические исследования: Сборник научных статей. Казань: Инф.-изд. центр КГУКИ, 2009. – С. 84-87.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

Юсупова А.Ш. Двуязычная лексикография татарского языка XIX века. – Казань: Изд-во Казанск. гос. ун-та, 2008. – 410 с.

# К. БИККУЛОВ ИҖАТЫНДА М. АКМУЛЛА ТРАДИЦИЯЛӘРЕНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ (тууына 150 ел уңае белән)

# THE TRADITION OF M. AKMULLAH IN THE WORK OF K. BIKKULLOV (to the 150th anniversary of his birth)

**Liliya NURIEVA**

**SUMMARY**

This article is devoted to the study of the work of Kasim Bikkulov, who was known at the beginning of the 20th century as a poet and writer, educator, religious figure, who dedicated his life to writing and education of people. His literary heritage includes numerous poems, works of small prose, about a dozen novels. Like many famous personalities, he left a rich literary heritage, as well as work on local history, theology.

K. Bikulov actively worked on the preparation and publication of "Books for reading" for students of Tatar schools and madrassas, where he included his works aimed at familiarizing children with certain genres of literature, the world of nature and the customs of the Tatar people, the surrounding world of man. Similarly many teachers, the writer believed in the power of the impact of poetry on readers and used in their practical teaching activities educational potential of the literary text.

His numerous works and books for reading were published several times in printers working in the beginning of the century. In Soviet times, K. Bikkulov was arrested and his literary-methodological legacy of the forgotten. The relevance of the work is explained by ignorance of the literary heritage of the writer. In this regard, the article deals with poems that form the basis of creative activity of the writer and are a certain contribution to the development of Tatar educational thought of the early twentieth century. "Books to read", which contain numerous samples of poetry, reflecting the educational traditions of the second half of the nineteenth and beginning of the XX century are analyzed in this work in a comparative perspective with the work of M. Akmulla, known in the second half of XIX century poet and educator and studied in the aspect of Tatar literature.

XIX йөзнең икенче яртысында татар әдәбиятына көчле агым булып килеп кергән мәгърифәтчелек рухы шул чор язучыларының әсәрләрендә төп урынны алып тора. Бигрәк тә милләтнең киләчәген кайгырту максатында балалар тәрбияләү, акыл куәтен, белемнең кыйммәтен ассызыклау күп кенә мәгърифәтчеләрнең үзәк идея-максатларын тәшкил итә. Укымышлы мулла гаиләсендә туып-үскән Касыйм Бикколов иҗатында да нәкъ менә мәгърифәтчелек хәрәкәтенә кагылышлы уй-фикерләр өстенлек итә [Нуриева, 2016: 221]. Касыйм Бикколовның (1868-1937) әдәбият өлкәсендәге эшчәнлеге аерым игътибарга лаек.

Әлеге исем соңгы елларда әдәбиятыбыз тарихына кайтарылып, иҗаты өйрәнелә башланган шәхесләрнең берсе. Язучы 1937 елга кадәр яшәсә дә, иҗат активлыгы нигездә 1904-1918 елларга туры килә: уку китаплары да, гасыр башы авыл тормышын реалистик сурәтләгән повестьлары да шул елларда дөнья күрә. Бүгенге көндә К. Бикколовның үз заманында ике дистәдән артык китап бастырып чыгаруга ирешкән булуы билгеле, алар арасында поэзия, проза үрнәкләре дә, мәктәп-мәдрәсәләрнең аерым

сыйныфлары өчен уку китаплары да бар. Алар XX гасыр башында эшләп килгән төрле басмаханәләрдә дөнья күргән. Әлеге китапларга кертелгән фәнни-публицистик юнәлештәге кечкенә күләмле язмалары кече яшьтәге укучыларны төрле табигать күренешләре, әйләнә-тирәне танып белү юнәлешендә беренчел фәнни фикер формалаштыруга юнәлдерелгән булуы белән дә кызыклы.

К. Бикколов иҗатында XIX йөзнең икенче яртысында иҗат иткән мәшһүр шагыйрь Мифтахетдин Акмулла (1831-1895) әсәрләрендәге хис-кичерешләр, уй-фикерләр белән аваздашлыкны да, мәгърифәтче әдип традицияләренең дәвам ителүен дә күрәбез. Болар исә, гуманистик идеаллардан – мәгърифәт-белем, сафлык, гаделлек, сабырлык, миһербанлыктан гыйбарәт. К. Бикколов шигырьләрендә дә кеше шәхесен олылау, аны бәхетле итеп күрү теләге кебек сыйфатлар үзәктә тора. Мәгърифәтче әдипнең татар халкы тарихындагы роле, иҗат мирасының әһәмияте, беренче чиратта, үзеннән калдырган эше, үзе яшәгән дәвердәге урыны белән билгеләнә.

Акмулла иҗатының кыйммәтен тугандаш төрки халыкларның шул чордагы тормышын, анда барган үзгәрешләрне, аларның алдагы яшәеш белән тыгыз бәйләнешен, социаль шартларын ачу аша гына бөтен тулылыгында аңлап була. Бу чорда төрки халыклар яшәгән төбәкләрдә җитди тарихи, иҗтимагый, социаль үзгәрешләр бара һәм алар халыкның милли үзаңын формалаштыруга зур йогынты ясый. Шундый шартларда көчле дулкын булып мәгърифәтчелек хәрәкәте мәйданга килә. Ул, яшәешнең бөтен өлкәләренә үтеп кереп, җәмгыятьтә җитди үзгәрешләргә юл ача. Ислам динен реформалаштыру, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту системасын үзгәртү, алдынгы милләтләр ирешкән мәдәни казанышлар белән таныштыру, аларны үзләштерү аша милләт тәрәккъкыятенә ирешү максат итеп куела [Юзеев, 2001: 147-148].

Акмулла иҗаты әдәбият тарихында тәфсилләп өйрәнелгән шагыйрьләрнең берсе. Ул Урта гасыр әдәбиятыннан, XIX йөзнең 1 нче яртысындагы суфичылык рухы белән сугарылган шигърияттән XX йөз башындагы Яңарыш әдәбиятына күчештә күпер ролен үти, ягъни Яңа заман әдәбиятының нигез ташын салучыларның, аңа әдәби җирлек әзерләүчеләрнең берсе була. Акмулла шигырьләрендәге фикер тыгызлыгы, хөкем гаделлеге, форма камиллеге аннан соң килгән бер төркем шагыйрьләр өчен (М.Гафури, Н. Думави, К. Бикколов һ.б.) чын поэтик осталык мәктәбе булып хезмәт итә. [Татар әдәбияты тарихы, 2015: 329]

Яңа фикерләрне кеше күңеленә, аңына сеңдерүдә матур әдәбият үтемле чара булганлыктан, мәгърифәтчелек хәрәкәте, аны үз идеяләрен тарату-үткәрүдә киң файдалана. Акмулла шигъриятендә тормышны акыл, белем, әхлак ярдәмендә үзгәртеп коруны максат иткән мәгърифәтчелек идеологиясе әсәрләре тематикасын, идея юнәлешен, жанр төрлелеген, иҗат алымнарын һәм иҗат методын билгели. Аның мөһим сыйфатлары булып – халык тормышын яхшыртуны гыйлемгә, әхлак тәрбиясенә һәм тирәлек шартларына бәйләп карау, искелек һәм яңалык көрәшен чагылдыру тора.

Әлеге мәкаләдә иҗаты өйрәнү обекты булып торган К. Бикколовның әдәби-эстетик карашлары да XIX йөзнең 2 нче яртысындагы һәм XX йөз башы тарихи-иҗтимагый, социаль-мәдәни үзгәрешләр белән аерылгысыз бәйле. Халыкка якынрак булу өчен әдип чынбарлыктагы реаль күренешләргә активрак мөрәҗәгать итә. Бу исә реализмның әсәрләрендә киңрәк урын алуына китерә. Шул рәвешле, кешене көнкүреш яшәеш белән тыгыз

мөнәсәбәттә һәм белем-тәрбиягә нисбәтле сурәтләүгә нигезләнгән мәгърифәтчелек реализмы аның иҗатының да бер юнәлешен тәшкил итә. Авторның мәгърифәтчелек эстетикасына нигезләнеп, милләтнең киләчәге өчен борчылып язган “Авыл байларына хитаб” шигыре шундый характерда:

Ук тимәсә, куян үлмәс аткан берлән,
Һичбер милләт алга бармас яткан берлән.
Кулларыңнан алтыныңны чыгармыйча,
Милләткә файдаң тимәс, әйткән берлән.
Күгәрмәс ташка ягъмур яуган берлән,
Май чыкмас, кысыр сыер саугын берлән.
Сукыр мулла, аксак хәлфәдән ни файда,
Мәктәбе череп тәмам ауган берлән.

Ягъни әлеге шигырьдә тик торып кына, көч һәм мал сарыф итмичә, максатка ирешү юк, милләтне алга җибәрү мөмкин түгел дигән фикер үткәрелә. Акмулла иҗатында исә, милләтнең артталыгы хакында борчылып, шагыйрь телләрне өйрәнү кирәклеге хакында яза:

Әһле ислам йоклабрак калыр булды,
Башка милләт алга таба барыр булды...
Урысча укып кына түгел белмәк, -
Халь килсә, фырансузча белгән яхшы!..
(“Башка милләт алга таба барыр булды”)

Мәгърифәтчелек әдәбияты традицияләренең чагылышы буларак, Бикколов шигырьләрендә дә чынбарлыкка мөнәсәбәт аша гади халык тормышы киң чагыла:

Кар бетте, яз көн җитте,
Мужик сабанга китте.
Төш чагында ашарга дип,
Хатыны чумар итте. (“Авыл хәле”)

“Чыңгызхан”, “Болгар” шигырьләре аша К. Биккуловның, Акмулла кебек үк, тарихи-социаль вакыйгаларга да битараф булмавы күренә.

Сәлам улсын сиңа, Болгар,
Олуг ханнар үстердең,
Мәдәни шәһәр улдыгың
Яурупага күстәрдең. (“Болгар”)

Әлеге мисалда әдип, Болгар дәүләтен данлап, аның мәгърифәтле булуы хакында фикерләрен, аның Аурупа илләренә кадәр мәгълүм булуы хакында яза. Шагыйрьне Болгар дәүләтенең ни сәбәптән, кемнәр тарафыннан җимерелүе хакында, шулкадәр бай дәүләттән, мал-мөлкәтләрдән, мәдәният үзәгеннән бүгенге көндә һичбер хатирә булырлык әйбер калмавы борчый:

Кайда ханың, кайда малың,
Кайда бөек дәүләтең?!

“Татар кызы” шигыре исә XX гасыр башы әдипләре өчен актуаль булган татар кызлары язмышын чагылдыра: хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсе аны да бик борчый. Әлеге әсәрдә кеше күзенә күрсәтмичә, өйдә тәрбияләнеп, мәҗбүри рәвештә бай, карт кешегә кияүгә бирелгән татар кызының бәхетсезлеге, авыр күңел кичерешләре сурәтләнә.

Шагыйрьнең “Тырышыгыз балалар, кайгыртыгыз милләтне”, “Тырышыгыз, балалар, сез бит татар уллары” шигырьләре мәгърифәткә өндәү һәм һәртөрле искелек-артталыкны тәнкыйтьләү пафосы белән көчле. Чорга бәйле реаль күренешләрнең мәгърифәтчеләргә хас сурәтләүе белән

үрелеп баруы шигырьләрне эмоциональ тәэсирле, интонацион яңгырашлы итә. Аллаһы Тәгаләнең барлыгын һәм берлеген таныган К. Бикколов шул чор дини карашлардагы чикләнгәнлекне үтеп чыга һәм мәгърифәтчеләр, соңрак җәдитчеләр күтәреп алган караш-фикерләрне кайнар яклый, балаларда милли горурлык хисе тәрбияләүгә дә өстенлек бирә [Нуриева, 2017: 37]:

Актык сүзем шул сиңа:
Мәктәп юлыннан калма,
Суфиларга алданма,
Алар надан, балалар.
(“Тырышыгыз, балалар, сез бит татар уллары”)

Һәртөр наданлыкка, әхлаксызлыкка бөтен барлыгы белән әрнегән мәгърифәтче акылны зурлавы, гаделлек-миһербанлыкка мәдхия укуы белән үзенең эстетик идеалын чагылдыра. Шуның белән бергә автор милли горурлык хисе тәрбияләүне дә алга сөрә, бердәмлеккә чакыра:

Тырышыгыз балалар, кайгыртыгыз милләтне.
Иттифак бул балалар, сез – пәйгамбәр өммәте.
Фил, капландай бабагыз, юлбарыстай агагыз.
Җир селкеткән Чыңгызхан – арысландай атагыз...
Иң зур куәт иттихад (бер сүздә булу), тәмам зәгыйфтер нифак.
Артык сүз шул Касыймнан: бул, балалар, иттифак (бердәм)!
(“Тырышыгыз балалар, кайгыртыгыз милләтне”)

К.Бикколов иҗаты – халыкчан шагыйрь булуның гаҗәеп матур бер үрнәге. Образларга шактый бай булган теленең гади һәм аңлаешлы булуы да шигырьләренең халык арасында киң таралуына ишарә булып тора. Халык телендә бәет буларак яшәгән “Арыш”, “Бодай” шигырьләре – аның иҗатының халык рухына якын торуына ачык мисаллар [Нуриева, 2017: 37].

Әй, богдаем, богдаем,
Бирде сине Ходаем.
Башың тулып үсеп җитсәң,
Үзем килеп ураем.
(“Богдай”)

Әй, арышым, арышым,
Синдә минем табышым.
Синнән башка юктыр минем
Бу дөньяда тормышым.
(“Арыш”)

Әлеге шигырьләрдә кулланылган “көмеш башак”, “җәүһәр бөртек”, “алмаз урак”, “ахак сап”, “ука кеби салам”, “мәрҗән кеби арыш”, “ләил кеби яшел кыяк”, “энҗе кеби орлык”, “алтын сакал”, “көмеш салам”, “алтын башак” кебек эпитет-метафора чагыштырулар әсәрнең укылыш тәэсирен көчәйтә.

Акмулла иҗатының төп эчтәлеген мәгърифәтчелек, димәк, аң-белем өчен көрәш идеяләре тәшкил итүен калку итеп күрсәтә торган фактларның берсе сыйфатында шагыйрь әсәрләрендә Китап образы тоткан урынны күрсәтергә мөмкин. [Татар әдәбияты тарихы, 2015: 313] К. Бикколовның балаларга багышлап язылган әсәрләрендә дә Акмулла иҗаты традицияләре дәвамы ачык чагылыш табуына мисал буларак, Каләм образына мөрәҗәгать итеп, аны символ дәрәҗәсенә күтәрүендә күрәбез:

Кара савытта тора
Көмеш башлы җиз каләм.
Каләмнең хезмәте илә
Агарды ботен галәм.

Кәгазь өстен каралттың,
Бөтен дөньяны агарттың.
Ничә миллион нөсхәләр
Җир йөзенә тараттың.

Һәртөр наданлыкка, әхлаксызлыкка бөтен барлыгы белән әрнегән Акмулла иҗатында башланган акылны зурлау, гаделлек-миһербанлыкка мәдхия уку белән үзенең эстетик идеалын чагылдыру алымы үзеннән соң килгән әдипләр иҗатында да дәвам иттерелә:

Кил, зинһар, борадәрем, инсафка кил,
Куәтең канча икән – чамаңны бел!
Халь килсә, аның эшен сез дә эшләңез,
Булмаса, файда бирмәс такылтык тел!

Акмулла иҗаты халык фольклоры белән тыгыз үрелеп баруы бәхәссез: “Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт берлән”; “Әдәб дигән – мәхәббәткә сәбәп дигән”; “Карганы буяу белән тавис булмас”, Җүкәне майлау белән каеш булмас”; “Иң элек пакълау кирәк эчнең керен” һ.б. Шушы нисбәттән, К. Бикколов иҗатында да халык мәкаль-әйтемнәренә охшаш гыйбарәләрне еш очратырга мөмкин булуына игътибар итәргә мөмкин: “Сүз тыңламаган балага таяк тәэсир итмәс”, “Әдәпне әдәпсезләрдән өйрән”, “Фәкыйрьлек гаеп түгел, әмма ялкаулык бик зур гаептер”, “Гыйлем акча белән кулга кермәс, мәгәр тырышлык белән генә табылыр” һ.б. (“Балаларга кыйраәт”, 1910)

Авторның халык надан булуга, белемгә омтылмавына тискәре карашлары, мәгърифәтле булырга өндәве, татар халкының киләчәгенә булган мөнәсәбәте К. Биккуловны заманының алдынгы карашлы мәгърифәтчеләре белән бер рәткә куярга мөмкинлек бирә. Шагыйрьнең “Мәсҗет илә мәктәпнең әйтешкәне” шигыре дә шуңа мисал. Шул рәвешле, К. Бикколовның шигырьләре, мәкаль-әйтемнәргә аваздаш гыйбарәләре XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар дөньясында барган мәгърифәтчелек хәрәкәтләрен гәүдәләндерүче, шул исәптән, Акмулла традицияләрен дәвам иттерүче әдәби үрнәкләр булып тора.

## ӘДӘБИЯТ


Бертуган Биккуловлар. Әдәби-биографик җыентык / Төзүче-авт. Ф.Сәйфулл, И.Гомәров һ.б.. – Казан: Җыен, 2016. 448 с.

Нуриева Л.Ф. Касыйм Биккуловның “Ат караклары” әсәрендә мәгърифәтчелек эстетикасы // Литература и художественная литература тюркских народов в контексте Восток-Запад: материалы международной научно-практической конференции. - Казан: Изд-во Казан. ун-та, 2016. – С. 221-223.

Нуриева Л.Ф. Просветительские традиции в поэзии Касыйма Биккулова / Материалы VI Международной научно-практической конференции "Занкиевские чтения". – Тобольск: ТГПИ, 2017.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда, 3 Т. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. – 551 б.

Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII – XIX вв. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2001. – 192 с.

# OSMANLI ŞEHZADE KAFTANLARINDA KULLANILAN KUMAŞLAR ve ÖZELLİKLERİ

## (FABRICS USED IN OTTOMAN PRINCE CAFTANS AND THEIR CHARACTERISTICS)

**Fatma Nur BAŞARAN**[*]
**Sultan GÜRBÜZER**[**]

**ABSTRACT**

Caftan became one of the most characteristic symbols of the Ottoman Empire ruled by the dynastic system. The most expensive and most elite caftans were used of sultans and also used by the upper palace important people, and even as a uniform they were considered a symbol of power on battlefields. It is mostly an open-fronted garment made from very special fabrics and has taken its place in history with poisonous examples as a means of punishment as well as a gift for success, appreciation or honor in every important duty in the palace tradition. With color, composition and valuable material properties, gift caftans have changed according to the service or achievement made and are also known by various names.

The caftans, who clearly reveal the social status of the wearer, are prepared in large garment patterns to give a majestic appearance. The Sultan sons of the ruling were also trained for administrative administration from their early ages. The princes, which are prayerful wear shirts which were prepared before their birth, were wearing caftans enriched with install lever at the ceremonies of the feast and culüs when they came to the presence of their father. When they come to the starboard position, they were honored by the sultan for their duties by giving precious fabrics and caftans as gifts. Despite the fact that a large part cannot be preserved, unique samples arriving today are exhibited in our museums.

There are countless books, articles, films, documentaries, etc. written on Ottoman palace life. In these documents, mostly the sultans' lives, performances, wars, arts, articles and clothes they used, and many other information were given. In this research, the types and technical characteristics of the fabrics used in the Ottoman period prince caftans were studied and 20 samples obtained with the source scans were studied.

Key words: *Ottoman period, Caftan, Prince, Weaving*

## GİRİŞ

Altın ve gümüş tellerle dokunmuş ipekli kumaşlar, Osmanlı İmparatorluğu'nun saray hayatında sadece ihtiyaç için değil, manevi bakımdan da önem taşımış, İmparatorluğun kuvvet ve görkemini yansıtan bir simge haline gelmiştir. Sultan'ın yabancı ülkelere, devlet ve din adamlarına verdiği hediyeler arasında saray kumaşları en ön sırayı almıştır.

Ekonomik, ticari, sosyal nedenlerden dolayı dokuma sanatı, Osmanlı İmparatorluğu'nun yükselmesine paralel olarak gelişmiş ve dünyada eşine rastlanmayan bir düzeye ulaşmıştır. Zamanla imalat çeşitlenmiş, zenginleşmiş ve güçlü bir sanat kolu haline gelmiştir (Gürsu, 1988:17). Fatih Sultan Mehmed'in ölümünden sonra, ölen sultanlara ait giysilerin bohçalanarak saklanması, Osmanlı İmparatorluğu Dönemi kumaş sanatını 15. yüzyılda kısa bir boşluktan sonra 16.

[*] Doç. Dr., Gazi Üniversitesi Sanat ve Tasarım Fakültesi Tekstil Tasarımı Bölümü, Ankara,
[**] Gazi Üniversitesi Güzel Sanatlar Enstitüsü Yüksek Lisans Öğrencisi, Ankara,

yüzyıldan 20. yüzyıl başlarına kadar kopmadan izlememize olanak sağlamaktadır (Akpınarlı ve Balkanal, 2012:181).

(Старинные, 1871); «Песня о реке Большой Цивиль» (Песня, 1871); «Записи разных песен» (в книге описи ГИА ЧР дело названо «Тексты песен различной тематики», в которых представлен перевод чувашских песен на русский язык) (Тексты).

Вышеперечисленные рукописи чувашского просветителя до настоящего времени по неизвестной нам причине не привлекало внимания яковлеведов. Правда, в начале 1980-х гг., при составлении первого тома текстов «Революцичченхи чăваш литератури» (Дореволюционная чувашская литература) старший научный сотрудник ЧНИИ (ныне ЧГИГН) Г.Ф. Трофимов (Юмарт) расшифровал и выписал все песни из вышеназванных рукописей. К сожалению, тогда редколлегия не смогла включить их в книгу, изданную в 1984 г. (она их отнесла к не совсем оригинальным произведениям И.Я. Яковлева). 22 мая 2001 г. эти выписи были переданы автору данной статьи с дарственной надписью. Данные архивные тексты до настоящего времени не смогли дойти до специалистов и массового читателя. В январе 2018 г. автор статьи сверил выписи Г.Ф. Трофимова с их оригиналами из фонда И.Я. Яковлева (Ф. 515) ЦГА ЧР и подготовил к публикации в одном из сборников ЧГИГН в 2018 г.

Итак, когда, где и кем были собраны вышеперечисленные материалы, а также кто их переводил на русский язык? Какая степень причастности к ним просветителя чувашского народа? Ответы на некоторые из них можно найти в рукописях же. Так, «Записи татарских народных песен» (Записи, 1875) И.Я. Яковлевым собственноручно датированы 1875 г. На титульном листе рукописи имеется следующее, его же рукой внесенное замечание: «Большая часть песен вовсе не рекрутская, как должно бы ожидать по заглавию (татарского). Почти дословный перевод татарских песен». Ниже добавлено: «Студенту 4 к(урса) фил(ологического) фак(ультета) Г(осподи)ну Яковлеву. 1875 год» (Записи, 1875:1). На то, что чувашский студент лишь выписывал с готовой рукописи переводы, указывают некоторые авторские пометки и объяснения (в скобках): «Я люблю читать “Бакирган” (заглавие книги)»; «...»* (* Нельзя разобрать)»; «(Первая строка не разобрана)»; «(пропуск в подлиннике)» и т. п. Очевидно, оригинал рукописи, с которого выписывал студент выпускного курса Казанского университета и будущий просветитель, был двуязычным (на татарском и русском языках).

Как отмечает Г.Ф. Юмарт, выпись чувашского студента с какой-то готовой рукописи сохранилась полностью. При этом Иван Яковлевич пронумеровал до пятой песни, которые одновременно распределялись по годам записи (так можно понять из следующего вычеркнутого после записи словосочетания: «1853 г. “пелась”»). Всего пронумеровано 22 песни и они охватывают 1853 – 1874 гг. Свои выписи студент Яковлев сделал, как отметил сам копиист, в 1875 г. Но с чьей же рукописи он переписал русский перевод текстов татарских (не столько кряшен, сколько мусульман) народных песен? Кто мог увлеченно собирать и систематизировать по годам записи этих образцов народного творчества в течение 22 лет? Пока окончательного ответа на данный вопрос нет (конечно, можно допустить авторство Н.И. Ильминского, но тогда загадочными становятся оставленные Яковлевым пометки в нерасшифрованных строках песен, так как он имел возможность консультироваться со своим учителем в любом удобном для них случае).

Как известно, в студенческие годы И.Я. Яковлев и его друзья усиленно собирали образцы чувашского народного творчества, часть которых сохранилась в его личных фондах. Так, в фонде 515 ГИА ЧР хранятся записи

В.А. Белилина (студента Казанского университета, талантливого фонетиста) тексты чувашских песен, пословиц и сказок, а также сюжеты сказок на татарском языке. Рукопись имеет следующее название: «Поговорки в стихах на чувашском и татарском языках»(Поговорки, 1871). Здесь первое слово использовано не в значении фольклорного жанра, а в смысле «образцы речи в их фонетическом звучании» (тщательно отмечены палатальные варианты согласных букв, а также современные буквы *ă* и *ĕ* соответственно написаны как *ъ* и *ь*). Записи этих текстов сделаны, скорее всего, в ходе работы В.А. Белилина и И.Я. Яковлева над составлением «Букваря для чуваш<ей>» 1872 года издания. Именно тогда они изучали фонетические особенности чувашской речи в сравнении с татарской и русской. Убедительным доказательством тому служит совместное письмо студента Белилина и чувашского учителя-самоучки Тимофея Петрова к И.Я Яковлеву из чувашского села Пимурзино (Буинского уезда Симбирской губернии, расположенного в шерсти километрах от русского села Бурундуки), написанное 18 мая 1871 г. (Письмо, 1871: 1 – 2). «В этом письме о себе и о занятиях Василия Алексеевича скажу только следующее, - сообщает Т. Петров, - переписывание сказок и песен и т(ому) под(обных) пока идет довольно медленно, но за всем тем мы успели записать около тридцати разных песен и около двух сказок (одна сказка не докончена рассказчиком)» (Письмо, 1871:1). Более точна информация В.А. Белилина: «Написали мы с Тимофей Петровичем 36 песен, 11 загадок, 4 молитвы, одну статейку некую под заглавием “слова дружки” и полторы сказки» (Там же).

Из писем И.Я. Яковлева А.В. Рекееву становится известно, что в 1873 г. В.А. Белилин собирал фольклорный материал для чувашского букваря в с. Тимерсяны (Яковлев, 1985:158). Из письма от 1 февраля 1874 г. можно узнать, что к сбору материала он подключил и А.В. Рекеева: «не можешь ли ты собрать, пока не удалился из Тимерсян, побольше сказок, рекрутских песен, а также и других песен, например, хороводных, - у В(асилия) Ал(ексеевича) в Тимерсянах очень мало записано» (Яковлев, 1985: 164 – 165).

Итак, в годы работы над составлением и переработкой «Букваря для чуваш<ей>» (1871 – 1974 гг.) его авторский коллектив под руководством студента Яковлева собрал большое количество фольклорного материала. Особый интерес, проявленный студентом из Кошки-Новотимбаево к рекрутским песням (смотрите предыдущее письмо), думается, совершенно не случаен. Первоначально мы полагали, что на основе текстов данного жанра студент выпускного курса намеревался сочинить курсовую или дипломную работу в сравнительном аспекте (на основе сравнений татарских и чувашских рекрутских песен) (Родионов, 2017: 81). На такую мысль наталкивает рукопись И.Я. Яковлева «Тексты песен различной тематики», в которой имеется русский перевод и чувашских рекрутских песен (Тексты). Поэтому мы допускали, что по какой-то объективной причине (наличие недостаточного количества материала, изменение темы и т.п.) работа не была выполнена.

В ходе работы над составлением данной статьи мы обратили внимание на письмо И.Я. Яковлева Н.И. Ильминскому от 11 ноября 1875 г., в котором первый сообщает второму следующее: «До сих пор я еще не писал диссертации, не знаю как и быть, собираюсь кое-что написать да послать Фирсову» (Яковлев, 1985: 59). В примечаниях книги «Письма» ее составитель (Н.Г. Краснов) утверждает, что выпускник Яковлев написал научную работу по

теме «Несколько памятников устной чувашской словесности в переводе на русский язык» (Яковлев, 1985: 306).

Как уже было отмечено, научным руководителем И.Я. Яковлева был профессор Фирсов Н.А., который рекомендовал выпускнику сочинить кандидатскую диссертацию и представить ее до января 1876 г. Наличие материала по татарскому фольклору (песни и сказки) позволяет предположить, что И.Я. Яковлев тогда действительно собирался сочинить научную работу, в первую очередь в сравнительном плане. Утверждение же Н.Г. Краснова о завершении чувашским студентом диссертационной работы по вышеизложенной теме пока остается ничем не подтвержденным предположением. Его поиски рукописи данной научной работы, как нам известно, остались безрезультатными.

После окончания университета И.Я. Яковлев был назначен, как известно, инспектором чувашских школ Казанского учебного округа и, естественно, он полностью был погружен в педагогическую и школьно-организационную практику, по этой причине, следует полагать, постепенно охладел к научной деятельности. В данном случае логичнее считать, что его работа по оформлению диссертации приостановилась на этапе сбора материала, не более того. По воспоминаниям самого просветителя, часть собранного в те годы фольклорных текстов в начале XX в. была передана в распоряжение Н.И. Ашмарина, а другая часть осталась в его домашнем архиве (Яковлев, 1997: 98). В советский период вместе с остальными документами они были переданы в ЦГА Чувашской АССР (ныне ГИА ЧР). Что касается работы «Несколько памятников устной чувашской словесности в переводе на русский язык», то она, как нам кажется, исследователями перепутана с архивной рукописью И.Я. Яковлева «Тексты песен различной тематики», которые тоже являются русскими переводами чувашских народных песен (Тексты). В ней представлены переводы следующих жанров чувашских народных песен: *сăра юррисем* («гостевые») – 56 песен, (рекрутские) – 12 песен; «молодых парней и девиц» - 17 песен; «свадебные» (вместе с «плачем невесты») – 56 песен. Все названия жанров и примечания (типа «По записи Архипа Богд(анова)», «Из моей тетради») принадлежат И.Я. Яковлеву. Архип Яковлевич Богданов – это ученик Симбирской чувашской школы (до 1874 г.), затем он работал учителем Новоайбесинской школы, а в 1889 г. – в школе д. Казанлы Вольского уезда Саратовской губернии (Яковлев, 1985: 125). Следует полагать, что свои записи он сделал по просьбе И.Я. Яковлева в 1874 – 1875 гг., быть может, и несколько раньше. Сбор текстов устного народного творчества самим просветителем осуществлен в те же годы. Например, в письме Н.И. Ильминскому от 12 июня 1871 г. он пишет следующее: «Я тоже в последнюю поездку записал несколько сказок, пословиц и загадок; но этим делом я еще хочу заняться среди лета. Вообще у нас материалу для составления учебников на чувашском языке наберется много, но только не знаю, как мы сумеем им воспользоваться» (Яковлев, 1985: 54). В рукописи «Тексты песен различной тематики», как уже было отмечено, имеется пометка автора: «Из моей тетради». Следовательно, он увлеченно собирал и народные песни, многие из которых при переводе сопровождались его пояснениями и замечаниями. Особую любовь чувашский просветитель имел к рекрутским и гостевым песням. Думается, они его привлекали возвышением в текстах значения родного дома и родни, земляков, родины. Эти тексты ярко отражали народную философию, менталитет, а также этику и эстетику. Для примера

можно привести перевод И.Я. Яковлева следующей чувашской рекрутской песни:

У вороной лошади, куплен(н)ой в Казани,
На голове черные шелковые узды.
У саврасой лошади, куплен(н)ой в Самаре,
На голове зеленые шелковые узды.
Голова перед отцом и матерью,
А душа перед Богом и Судьбой.

Не менее философичны и глубоко лиричны строфы из татарских рекрутских песен:

Горит огонь в очаге.
Времена тяжелые ныне, Маргузямал.
Провожай, говоря: «будь здоров, милый душенька!»

Тяжелые нынешние времена
Подошли в наши молодые годы, М-л.
Провожай, говоря:
«Будь здоров, милый душенька!»

Шыбыр-шыбыр дождь идет,
Окропляя верхушки молодых трав, М-л.
Провожай, говоря:
«Будь здоров, милый душенька!»

Зачем царь собирает солдат (берет в солдаты),
Заставляя плакать молодых парней?
М-л, провожай, говоря:
«Будь здоров, милый душенька!»

Из всего сказанного вытекает следующее заключение: 1. Первоначально студент Яковлев организовал сбор памятников чувашской устной словесности с целью составления учебных пособий на чувашском языке, в том числе с намерениями изучения фонетических особенностей чувашской речи. 2. По мере приближения к выпускному курсу он, как сложившийся практик, считал целесообразным использовать этот готовый, но не использованный материал в написании выпускного сочинения (кандидатской диссертации) в сравнительном плане (прежде всего с татарским фольклором).

Была и другая, более весомая причина охлаждения начинающего свою просветительскую деятельность И.Я. Яковлева к науке, это – пример Н.И. Ильминского. Именно благодаря этому незаурядному человеку чувашский студент, собиравшийся получить высшее образование и реально помогавший отдельным юношам (знакомым, сверстникам) получить образование в Симбирском удельном училище, преобразовался в деятеля-практика на ниве народного (чувашского) просвещения. Он действительно был практиком, опиравшимся на теоретические разработки своего учителя. Преданность делу жизни Ильминского Яковлев подтверждал не только активной просветительной деятельностью (создание букваря, открытие чувашских школ и т.д.), но и официальным заключением со своим учителем так называемого «договора о родстве» (в 1877 г. обязанный Ильминскому во всем, в том числе и получением должности инспектора чувашских школ, И.Я.

Яковлев женился на ее приемной дочери). Такой жертвенный поступок с его стороны был необходим ради достижения самой главной его жизненной цели, которая определилась у него, как считал сам просветитель, еще в 1864 г. (Яковлев, 1997: 57). Через 11 лет став инспектором чувашских школ, он в последующие годы полностью реализовал свои юношеские мечты и желания, всю жизнь был предан своему святому делу - национальному подъему чувашского народа. Фольклором чувашский просветитель интересовался и в последующие десятилетия: включал в свои буквари тексты разных жанров устного поэтического творчества, издавал отдельные книги с текстами и нотной записью народных песен. В них он видел духовную основу народа, его философию, эстетику и менталитет.

## ЛИТЕРАТУРА И ИСТОЧНИКИ


Записи татарских народных песен // Государственный исторический архив Чувашской Республики (ГИА ЧР). Ф. 515. Оп.1. Д. 3. 1875 г. - 18 л.

Песня о реке «Большой Цивиль» // ГИА. Ф. 515. Оп. 1. Д. 11. Не ранее 1871 г. - 1 л.

Поговорки в стихах на чувашском и татарском языках // ГИА ЧР. Ф. 515. Оп. 1. Д. 6. Не ранее 1871 г. - 12 л.

Письмо В.А. Белилина и Т.П. Петрова от18 мая 1871 г. // ГИА ЧР. Ф. 7. Оп. 1. Д. 223. Л. 1 - 2.

Родионов В.Г. Чувашское сравнительное литературоведение: теория и практика. -Чебоксары: Новое Время, 2017. - 92 с.

Сказки, загадки, поговорки и пословицы и бытовые обряды, собранные И.Я. Яковлевым // ГИА ЧР. Ф. 515. Оп. 1. Д. 7. - 18 л.

Старинные песни для детей на чувашском языке, собранные И.Я. Яковлевым // Там же. Д. 10. Не ранее 1871 г. - 1 л.

Тексты песен различной тематики, собранные И.Я. Яковлевым // ГИА ЧР. Ф. 515. Оп. 1. Д. 12. - 19 л.

Яковлев И.Я. Моя жизнь: Воспоминания. - М.: Республика, 1997. - 696 с.

Яковлев И.Я. Письма. - Чебоксары: Чуваш. кн. изд-во, 1985. - 366 с.

# М.МӘҺДИЕВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ (“МӘҢГЕЛЕК ЯЗ” РОМАНЫ ҺӘМ “АЧЫ ТӘҖРИБӘ” ҖЫЕНТЫГЫ МИСАЛЫНДА)

# (FEATURES OF THE USE OF PHRASEOLOGICAL UNITS IN THE WORKS OF M. MAGDIEV (ON THE EXAMPLE OF THE NOVEL "ETERNAL SPRING" AND THE COLLECTION "BITTER EXPERIENCE"))

**Ramilya SAGDIEVA***
**Damir HUSNUTDINOV****

**SUMMARY**

Writers often apply in their works to the use of idioms which may vary depending on the style of the given piece of literature.

The article investigates specific use of phraseological units by M. Magdeev in his works of belles-lettres fiction and journalistic style. The author tries not to use the same phraseology, turns to synonyms. The folklore genre and individual phraseological units come to the aid. M. Magdiev very successfully uses antonyms.

Тел – кешелек җәмгыятендәге гаҗәеп үзенчәлекле, катлаулы һәм гаять әһәмиятле күренеш. Аның кайсы гына өлкәсен алып карасаң да, анда кызыклы, мөһим фактларга тап буласың, әллә никадәр яңалыклар ачасың.

Әдәби әсәрләрнең тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү дә бик кызык нәтиҗәләр ясарга мөмкинчелек бирә. Теге яки бу язучы-шагыйрьнең иҗатын өйрәнгәндә, һичшиксез, аның телен, сүз уйнату осталыгын тикшерү мөһим (Husnutdinov, Sagdieva, Mirzagitov, 2016: 42).

Фразеологик әйтелмәләр дә – телнең бер байлыгы. Аларда халыкның иң күркәм тойгылары, олы хисләре, тапкырлыгы чагыла. Алар кыска һәм оста әйтеләләр, үткен һәм образлы сүзләрдән торалар. Фразеология – әдәби әсәрдә төп тел-сурәт чараларыннан берсе. Аннан оста файдалану – язучының отышлы ягы.

М.Мәһдиев әсәрләренә кулланылган фразеологизмнар нәрсәне дә булса атап кына калмыйлар, ә сөйләнгәннәргә язучының мөнәсәбәтен дә белдерәләр, аңа бәя бирәләр, предмет яки күренешне экспрессив бизәккә төрәләр. М.Мәһдиев – язучы һәм әдәби тәнкытьче. Шуңа күрә аның ике өлкәгә караган әсәрләрен чагыштыру кызык. “Мәңгелек яз” романында да, “Ачы тәҗрибә” истәлекләр җыентыгында да фразеологизмнар гади сөйләм бизәлешенә ия. Беренче әсәрдә ул татар авыл халкының көнкүрешен, яшәешен тасвирлаганда ярдәм итсә, икенче китапта татар халкының танылган шәхесләрен төрле яктан ачып бирү өчен хезмәт итә. Язучы халыкның сүзлек байлыгыннан бик иркен файдалана. Бер үк форманы кабатламаска тырыша.

М.Мәһдиев “Мәңгелек яз” романында бер идиоманы төрле-төрле вариантта бирә, ягъни аларның синонимик төрләреннән оста файдалана белә. Мәсәлән, язучы геройларның бик нык борчылуларын түбәндәгечә тасвирлый: *Аның күзләрендә шатлык очкыннары күреп, Рәифнең* ***йөрәге телгәләнде*** (Мәһдиев, 1996: 350). *Рәифнең* ***йөрәгенә кан сауды*** (Мәһдиев,

---

* Dots., Candidate, Kazan Federal University, Kazan.

** Dots., Candidate, Kazan Federal University, Kazan.

1996: 349). *Тәгәрмәч астына эләккәннәре генә чакырдап сытыла, моңа Гыйлфанның* ***йөрәге әрни*** (Мәһдиев, 1996: 400). *Гыйлфанның кинәт кенә* ***йөрәге сулкылдап куйды*** (Мәһдиев, 1996: 450). *Бу сүз шуннан бирле адәм баласының* ***йөрәген тетрәтеп*** *яши бирә* (Мәһдиев, 1996: 424). *Малайның* ***йөрәгенә кан укмашты*** (Мәһдиев, 1996: 344). *Ахиярнең* ***йөрәге дерелдәп алды*** (Мәһдиев, 1996: 482). *Сольманың да, Гасимәнең дә* ***йөрәгендә кан иде*** (Мәһдиев, 1996: 425). *Гыйлфанның ул хатны укыгач,* ***йөрәге өшеп китте*** (Мәһдиев, 1996: 523). Автор әлеге ***йөрәк*** белән бәйле идиомаларны ***җан*** сүзе аша да бирә: *Колхозда өч гектар бәрәңге күеп утырган бер көнне,* ***җаныңны кая куярга белмәгән*** *бер көнне, колхоз территориясенә Тавис кайткан* (Мәһдиев, 1996: 443). *Әллә узышлый болай гынамы,* ***җанына урын тапмагынгамы****?* (Мәһдиев, 1996: 472). *Әмма өйгә килеп кергәндә буылып елый башлаган Илүзә* ***үзенә урын таба алмады*** (Мәһдиев, 1996: 494). Бу мисаллардан күренгәнчә, М.Мәһдиев татар теленең сүзлек составыннан, мөмкинчелекләреннән иркен файдаланган.

Язучы бер әсәр эчендә генә түгел, ә төрле әсәрләрдә файдаланган фразеологизмнарны истә тотып эш итә. Бу очракта да ул бертөрлелектән котылу ягын карый: бер үк мәгънәне биргәндә, төрле фразеологизмнарны куллана: *Бүген-иртәгә күтәрелләбез, фрицның, - диде, -* ***арт сабагын укытабыз*** (Мәһдиев, 1996: 386). *Шырпы сызып,* ***авыз тирәсенә менеп төшә*** (Мәһдиев, 1996: 514). *Өстәл өстенә ике талонлык эчемлек куйды, кооператор кияү шуларны ялтыратып хәл итте, каенатасына* ***берне дә сыламаган көе*** *саубуллашып кайтып китте* (Мәһдиев, 1993: 93). Әлеге фразеологизмнарның өчесе дә кыйнау мәгънәсен бирә.

“Ачы тәҗрибә” җыентыгында еш кына аракы эчү белән бәйле эпизодлар сурәтләнә. Халыкта спиртлы эчемлекләр куллану белән бәйле бик күп фразеологизмнар хасил булган. М.Мәһдиев аларның барысын да белә диярсең. Бу мәгънәне бирү өчен, ул төрле-төрле фразеологизмнар куллана. Алар әсәрне тагын да халык теленә якынайта, җанлылык өсти: *Аспирантурасын тәмамлап, документлар алып бетергән көнне* ***каты гына төшереп алган*** *бит бу ходай бәндәсе* (Мәһдиев, 1993: 236). *Герой ләх исерек ул, кичә Шадриннан кайткач, бик* ***каты салганнар*** (Мәһдиев, 1993: 251). *Ә кияүләр теге “Рислинг”ны малга да санамыйча, үзләре кыстырып килгән “Столичная”ны* ***хәл итеп утыралар*** (Мәһдиев, 1993: 211). *Мин кайткач шатланып китә һәм* ***бераз өстәп куйгач****, һәр көнне бер генә сүз әйтә* (Мәһдиев, 1993: 227). *Яшь председательнең башы чуалган, чөнки шимбә көн иртүк ирләр* ***баш төзәтеп йомшап ук куйганнар*** *икән* (Мәһдиев, 1993: 251). Шушы ук мәгънәне биргәндә, автор индивидуаль фразеологизм да хасил итә: *Әйдә, иң яхшысы, керик, өстәл янына утырыйк та тагын бер тапкыр* ***көмеш бокалны алтын пута белән буып куйыйк*** (Мәһдиев, 1993: 147).

**Карау** мәгънәсе түбәндәге фразеологизмнар белән белдерелгән: *Шәп хатын, эссе көндә салкын һава массасы тупланган акшарлы кибет эченә кереп,* ***күз ташлады*** (Мәһдиев, 1996: 453). *Аннан миңа борылып, җирәнеп кенә* ***караш ташлады*** *да болай сөйләп китте* (Мәһдиев, 1993: 213). *Аның минә дигән хатыны – алдынгы китапханәче, культуралы, әдәпле хатыны, - председатель блокнотына* ***күз салып алды****, - Сольма ханым бар* (Мәһдиев, 1996: 506). *Сүзне башлар алдыннан секретарь зал буйлап* ***күз йөртеп чыкты****...* (Мәһдиев, 1996: 546). *Ялтыравыклы кара ботинкаларның линейка белән тигез сызыгы* ***күзгә ташланды*** (Мәһдиев, 1993: 98). Әлеге даими

фразеологизмнарның һәрберсенең текстта 5-7 тапкыр кабатлануын да искәртеп үтү кирәк.

**Үлү** мәгънәсенең дә тикшерү өчен алынган әлеге әсәрләрдә синонимик вариантлары бик күп: *Шулай яшь җан **дөньядан китеп барды*** (Мәһдиев, 1996: 352). *Беренче бөтендөнья сугышында булган, бик соңга калып кына бер бала үстергәннәр, карчыгы берничә ел элек инде **дөнья куйган*** (Мәһдиев, 1993: 272). Язучы әлеге мәгънәне еш кына ***җан*** сүзе аша да бирә: *Тегесе **җан биреп ята**, ди* (Мәһдиев, 1996: 379). *Кичтән үк **җан тәслим кылган** бит ходай бәндәсе* (Мәһдиев, 1996: 488). *Закирҗан белән күтәреп, чанага салып алып чыктым, ара ерак түгел, әмма ләкин, өйгә кереп җиткәндә иртән таңда үз кулымда **җан бирде*** (Мәһдиев, 1996: 488). Бер урында гына М.Мәһдиев үлү очрагында алла сүзен файдалана: *Үзен дә **алла сукты сугуын**: сөлекле күл төбеннән табып алдылар* (Мәһдиев, 1993: 276). Җөмләнең мәгънәсеннән аңлашылганча, тискәре геройның үлүе хәбәр ителә. Сугыш белән бәйле эпизодлардагы һәлак булуларны, хайван, кош-кортларның үлү очракларын тасвирлау да аерылып тора: *Галимнәр әллә нинди лабораторияләр ачтылар, әллә ниткән штатлар алып бетерделәр, өйрәнепме-өйрәнәләр, ә дуңгыз балалары **кырыла бирә*** (Мәһдиев, 1996: 526). *"Ямаулы күлмәген киеп, минем сөйгәнем бара", әле ул "мылтык алып, кылыч тагып" киң далада дошманнарны **кырып сала*** (Мәһдиев, 1993: 102). *Их, кайчан гына килер шундый вакытлар дип уйлый пионер, кайчан гына **кеше канын коя башларга*** (Мәһдиев, 1993: 103). Мәетне җиргә күмү белән бәйле М.Мәһдиев үлү мәгънәсен җир, кабер сүзләре аша да бирә: *Ул, эшне аңлагач, карусыз гына гариза язды, китеп барды һәм... коллективтан аерылгач, озак үтми **җир куенына кереп ятты*** (Мәһдиев, 1993: 229). *Бәхетең инде, Хрущев заманы, югыйсә, **каберең өстендә рус каены үсеп утырыр иде** инде* (Мәһдиев, 1993: 226).

М.Мәһдиев әсәрләрен укыганда, шул ачык сизелә: язучы, укучыны ялыктырмас өчен, телнең бар мөмкинчелекләреннән дә оста файдалана. Ул татар әдәби телен генә түгел, ә җанлы халык, сөйләм телен дә, кешеләрнең аралашу манерасын да бик яхшы белә. Фразеологизмнарны төрләргә бүлеп тикшерсәк тә, һәрбер төрдә дә бер үк төшенчә бик күп төрле синонимнар белән белдерелүе үзен сиздерә. Югарыда без моңа дәлилле мисаллар китерсәк тә, бу очракта да кызыклы җөмләләрне билгеләп узмыйча булмый. М.Мәһдиев башы чуалган геройларны төрле-төрле семантик-стилистик синоним фразеологик берәмлекләр ярдәмендә тасвирлый: *Башта аннан көлделәр, бераздан аңладылар: алдынгы эшче, карусыз хатынның, бичара, **акылына зарар килгән** иде* (Мәһдиев, 1996: 498). *Әмма акыллы хатын белән яшәгән ирнең берзаман **башы сыеклана*** (Мәһдиев, 1996: 492). ***Акылына зыян килә башлаган иде** – факт* (Мәһдиев, 1996: 392). *Ямаулы капчык аскан җитү чәчле ике малай узды – бичаралар, фашист тылында яшиләр, **акылы исәрләнгән** бер карчык узды – анысы егерме-утыз метр барган саен шәлен, сәләмә кофтасын селки, нәрсәдер куа...* (Мәһдиев, 1996: 402). *Бүген төнлә Рәхмәтләр йокламаган, Рәхмәткә **җен зәхмәте кагылган**, авырып егылган, хәзер саклап утыралар, ди* (Мәһдиев, 1996: 464). *Әлбәттә, башта **акылдан шашасың*** (Мәһдиев, 1993: 275).

М.Мәһдиев синонимнар белән генә чикләнеп калмый. "Ачы тәҗрибә" дип исемләнгән истәлекләр җыентыгында үзара антоним фразеологизмнар да байтак очрый. Мәсәлән, шатлану хисен белдергәндә язучы түбәндәге синоним фразеологизмнарны куллана: *Мин **күкләргә аштым*** (Мәһдиев, 1993: 218). Шуннан соң килгән икенче җөмләдә үк әлеге геройның хатынының

шатлануы исә башка фразеологизм белән бирелә: *Заһидә апаң да шатланып риза булды, оныклары янына дачага барырга дип* ***канатланып йөри иде*** (Мәһдиев, 1993: 218). Шатлану хисенең антонимы булган борчылу, кайгыру хисләре дә укучыга фразеологизм аша җиткерелә: *Алда зур бәрелеш көтелә иде, мин* ***кара кайгыга баттым*** (Мәһдиев, 1993: 265). *Кешенең* ***башы аска иелде*** (Мәһдиев, 1993: 209). Икенче бер җөмләдә прозаик, кайгыруны күрсәтү өчен, үзенең фразеологизмын да оештыра: *Мин монысын да йөрәк трансформаторым аша -* ***өч йөз сиксән вольтны йөз егерме җиде вольтка төшереп*** *кабул иттем, шулай да аларга бик рәхмәтлемен* (Мәһдиев, 1993: 207).

Гомумән алганда, М.Мәһдиевнең “Мәңгелек яз” романын һәм “Ачы тәҗрибә” дип аталган истәлекләр җыентыгын яхшылап укып чыкканнан соң, язучының һәр җөмләдә диярлек теге яки бу фразеологизмны кулланганлыгын сизәсең. Чөнки халкыбыз тарафыннан күп йөз еллар буенча иҗат ителеп килгән тел җәүһәрләре булган фразеологик әйтелмәләрдә тирән мәгънә, фикер, коллектив акыл һәм тәҗрибә сәнгатьле-сурәтле итеп, матур бизәкләр ярдәмендә белдерелгән. Халык тормышын, бигрәк тә авылны тасвирлаганда язучы фразеологизмнарны берничек тә төшереп калдыра алмый. Мәсәлән, “Мәңгелек яз” романыннан бер өзекне генә алыйк:

“*Кинәт кенә аның* ***йөрәге чәнчеп алды***, ***күз алдыннан боҗралар йөгерде***, ***йөрәген, тәнен курку басты***. *Егылам,* ***инфаркт була*** *дип* ***коты чыкты***. *Инфаркт сүзен кешелек җимгыятенең белә башлаганына әле күп түгел иде. 1953 елның бишенче мартында, бөтен ил халкының* ***йөрәген селкетеп***, *Бөек шәхеснең үлүе турында хәбәр бирделәр. Радио авырулар дөньясыннан бер исем атады: инфаркт. Бу сүз шуннан бирле адәм баласының* ***йөрәген тетрәтеп яши*** *бирә. Ахиярда ул бер тапкыр була язган иде инде. Председатель булып эшли башлаган беренче атнасы. Сәкинә посттан* ***авырлык белән китте***. *Печатьне, ачкычларны* ***кара янып тапшырды***. *Беренче идарә утырышында ук* ***комачау итте***: *үз тарафдарлары белән* ***сүз берләштереп***, *теге-бу мәсьәләдә* ***аяк чалды***. *Аннан һәр көнге планерка бетешенә идарә алдына килеп торып, аннан чыгучылардан сорашып, алай дөрес түгел, болай кирәк иде дип,* ***коткы салып***, *гел Ахиярнең* ***нервларында уйнады***... (Мәһдиев, 1996: 424).

М.Мәһдиевнең “Ачы тәҗрибә” дип аталган истәлекләр җыентыгында алдагы әсәр белән чагыштырганда фразеологизмнар ул дәрәҗәдә күп түгел. Ул төгәл билгеле бер вакыйгаларны, кешеләрне искә алу, аларны тасвирлауга кайтып кала. Һәрвакыт автор теге яки бу вакыйгага үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Шул очракларда прозаик еш кына фразеологизмнарга мөрәҗәгать итә дә инде. Тарихи шәхесләрне сурәтләгәндә, аларның җанлы сөйләмен тасвирлаганда да әлеге алым уңышлы файдаланылган.

Нәкъ менә “Ачы тәҗрибә” җыентыгында без М.Мәһдиевнең индивидуаль фразеологизмнарын күрә алабыз. Кешеләрнең эчке һәм тышкы сыйфатларын тасвирлаганда ул ***сыек гәүдә, агач елмаю, агач чырай, чуен күңел*** кебек фразеологизмнар ясый: *Иң алдан озын буйлы,* ***сыек гәүдәле*** *Яхъя Халитов бара* (Мәһдиев, 1993: 61). *Ләкин ул* ***агач елмаю*** *белән елмайды* (Мәһдиев, 1993: 62). *Миңа ВКП (б) тарихыннан “өчле” куйган тимер тавышлы,* ***чуен күңеллеләргә***, ***агач чырайлы*** *директорларга үч итеп ачыкмыйм* (Мәһдиев, 1993: 64). Эшсез йөрүче геройларны да язучы үзенчә, үз сүзләре белән үткен итеп сурәтли: *Дөрес инде: шундый чибәр булган хатынга* ***дуга белән печән чабып йөрүче җилкуар ни пычагыма?*** (Мәһдиев, 1993: 217). Икенче бер җөмләдә шул ук мәгънәне бирү өчен автор

тагын бер фразеологизм уйлап таба: *Хәзер бит ирләр азынды, хатыннары туйдыра, ә аларның эш рәхәт,* ***дандарага җон тетеп йөриләр*** *шунда* (Мәһдиев, 1993: 217). М.Мәһдиев берничә урында иске, шыксыз өйне сурәтләү өчен дә үз индивидуаль фразеологизмыннан файдалана: *Йортта башкача беркем дә юк, шыксыз,* ***мамыксыз өй*** (Мәһдиев, 1993: 271). Калын тавыш дигәнне ул түбәндәгечә бирә: *Хатын* ***бозлы тавыш*** *белән: "Әйдә бар, җәһәннәмеңә кит", - дип калды* (Мәһдиев, 1993: 212). Автор төз атлап килүне, геройның матурлыгын да үзенчә тасвирлый: *Килә атлап каршыма, минсиңайтим, әйтерсең* ***Кытай авторучкасы белән кәгазьгә җыр тезә. Сөт белән каннан гына тора инде*** (Мәһдиев, 1993: 122). Язучының *Бераздан Европага* ***тәрәзә тишкән*** *Петербург тотынган* (Мәһдиев, 1993: 99) җөмләсендәге индивидуаль фразеологизм да уңышлы дип саныйбыз.

М.Мәһдиевнең индивидуаль фразеологизмнар хасил итүе кызыклы. Югарыда күрсәткән мисалларда автор фикерне үтемлерәк итү өчен яңа фразеологизмнар уйлап таба, үз кичерешләрен тагын да тирәнрәк итеп ача. Ә кайбер очракта индивидуаль фразеологизмнар бертөрлелектән котылу чарасы да булып тора. Мәсәлән, кешеләрнең күп булуы, буш урын булмаганлыкны бирү өчен халык *аяк басарлык та урын юк* дигән фразеологизмны куллана. Әлбәттә, автор аны төшереп калдырмый: *Клубта* ***аяк басарлык*** *урын юк иде* (Мәһдиев, 1993: 159). Ләкин икенче бер урында М.Мәһдиев аны үзенчә үзгәртеп бирә, кабатлаудан кача, укучыны бер үк форма белән ялыктырмый: *Кичен клубта* ***энә төртерлек*** *урын юк иде – мин пәрдәнең кырыеннан залга карадым* (Мәһдиев, 1993: 272). ***Баштан пар чыга*** (Мәһдиев, 1993: 145) дигән җөмләдә *"баштан пар чыгу"* кешеләрнең (бу очракта нәшрият хезмәткәрләренең) эшләре күп булуын аңлата. Икенче бер урында, укучыга эш күплекне җиткерү өчен, язучы әлеге гадәти фразеологизмны берникадәр үзгәртеп куллана: *Печән өсте. Авыл халкының* ***башыннан ялкын күтәрелә*** (Мәһдиев, 1993: 284).

Димәк, М.Мәһдиев бер үк фразеологизмны кабатламаска тырыша. Бу бер әсәргә генә карамый. Язучы төрле әсәрләрендә дә кабатлаудан качарга омтыла. Ул синоним фразеологизмнарны бик оста файдалана белә. Синонимик оя төзергә аңа халык иҗаты да, индивидуаль фразеологизмнар да ярдәмгә килә. Авторның фразеологизмнарны антоним итеп бирергә дә осталыгы зур.

**ӘДӘБИЯТ**

Мәһдиев М. Ачы тәҗрибә: Истәлекләр. – Казан: Тат. китап нәшр., 1993. – 384 б.

Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр, 3 томда. II том: Ике роман. – Казан: Тат. китап нәшр., 1996. – 576 б.

Husnutdinov D.H, Sagdieva R.K, Mirzagitov R.H., Comparative constructions in G. Ibragimov's works//Journal of Language and Literature. - 2016. - Vol.7, Is.4. - P.42-45

# ПЕНЗА ӨЛКӘСЕ ҺӘМ МОРДОВИЯ РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАР-МИШӘРЛӘРЕ ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫ ӨЙРӘНЕЛЕШЕ

## (STUDY OF RITUAL FOLKLORE OF TATARS OF THE PENZA REGION AND THE REPUBLIC OF MORDOVIA)

**Flera SAYFULINA***

**SUMMARY**

For centuries, the Tatars lived in different parts of Russia. Today they live in such places as the Republic of Bashkortostan, the Chuvash Republic, Western Siberia, Orenburg, Ekaterinburg, Ulyanovsk, Nizhny Novgorod, Penza, Samara, Saratov, Tambov, and others. Folklorists are interested in oral folk arts, in customs and traditions of the people living in these areas, which were formed under the influence of geographical conditions, and the influence of neighbours. During the 20th century, there was a great activity aimed at collecting folklore of Tatars living in different parts of the country. To this end, various expeditions were organized, the collected materials were studied, they also were classified according to the genre, and textbooks, anthologies, multi-volume books were published. This article is devoted to the analysis of the folklorists' study of the traditions of the Tatars living in the Mordovia Republic and Penza region.

There are typical characteristics peculiar to the Tatars from other regions in the works of oral folk arts, preserved in the language of Mishar in the Mordovia Republic and Penza region, as well as there are works different from the others. Folklore of this area is studied in detail and separately and in the context of the folklore of the Tatars in other regions.

In the social and cultural life, following the traditions, customs and holidays is common to each nation. This is an important element of culture, it has an ethnic component and proves a connection with the ancient features of the nation. From this point of view, ritual folklore in the center of many scientists' attention. Lexical units related to this genre are studied by linguists, and observance of rituals and traditions is carefully studied by folklorists.

Татар халкы Татарстаннан тыш гасырлар буенча Россиянең төрле төбәкләрендә сибелеп яши. Бүенге көнгәчә татарлар Башкортстан, Чувашстан Республикаларында, Көнбатыш Себер, Ырынбур, Свердлау, Ульян, Түбән Новгород, Пенза, Самара, Сарытау, Тамбов һәм башка өлкәләрдә гомер итә. Әлеге җирләрдә яшәүче халыкның географик урыннары, яшәү шартлары, күршеләре тәэсирендә формалашкан үзенчәлекле гореф-гадәтләре, авыз иҗаты әсәрләре фольклорчы галимнәр игътибарын үзенә тарта. XX гасыр дәвамында төрле төбәкләрдә яшәүче татар кауменең фольклор әсәрләрен туплау-язып алуга юнәлдерелгән экспедицияләр оештыру, тупланган материалны аерым алып өйрәнү, җанрлар буенча классификацияләү, дәреслекләр, хрестоматияләр, күптомлыклар бастырып чыгару юнәлешендә җитди эш алып барылды. Әлеге мәкалә Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары йола фольклорының галимнәр тарафыннан өйрәнелешенә багышлана.

* Philol. Ph. Doctors, Prof., Kazan federal Universities, Kazan

Пенза өлкәсе һәм Мордовия Республикасы мишәрләре телендә сакланып калган фольклор әсәрләрендә төрле регионнарда яшәгән татар халкына хас булган сыйфатлар да, шулай ук, башкалардан аерып торган эчтәлекле әсәрләр булуы да табигый. Әлеге төбәк фольклоры фольклорчылар тарафыннан аерым алып та, башка төбәкләрдә яшәүче татарлар авыз иҗаты жанрлары контекстында да шактый өйрәнелгән.

Иҗтимагый-мәдәни тормышта билгеле бер йолаларны үтәү, гореф-гадәтләр тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык халыкларга да хас күренеш. Ул мәдәниятнең мөһим элементы булып исәпләнә һәм аның аермачык этник төстә булуы, халыкның бик борынгы үзенчәлекләренә бәйлелеге күзгә ташлана. Бу яктан караганда йола фольклоры күп галимнәрнең игътибар үзәгендә тора. Бу жанрга караган әсәрләрнең лексик атамалары тел галимнәре тарафыннан өйрәнелсә, йола, традиөияләрнең үтәлеше фолҗклорчылар тарафыннан тәфсилләп өйрәнелгән булуы белән аерылып тора.

Татар халык авыз иҗатының иң кызыклы, катлаулы һәм авыл халкының яшәү рәвешен, тормышка мөнәсәбәтен чагылдыра торган тӧренең берсе – йолалар. Йола фольклоры – халык иҗатының иң борынгы төрләреннән берсе. Галимнәр халык йолалары белән бәйле телдә сакланып калган әсәрләрне икегә бүлеп карыйлар: ел фасыллары дәвамында башкарыла торган хуҗалык эшләренә бәйле календарь йолалары; гаилә-көнкүреш йолалары. (Бакиров, 2012: 50)

Мордовия татар- мишәрләрендә табигать культы турында аерым мәгълүматлар В.Рогачев мәкаләсендә Мордовия халыклары белән чагыштырма аспектта карала (Рогачев, 2003: 154-157). Бу хезмәттә сөйләм үрнәкләре буларак тәкъдим ителгән текстларда яңа елны каршылау, авыл хуҗалыгы эшләре белән бәйле йолалар, төрле өмәләр, аулак өйләр һ.б. турында мәгълүматлар табарга мөмкин.

Пенза өлкәсеннән җыелган материаллар арасында төрле бәйрәмнәр уңаеннан күрәзәлек итү – киләчәкне алдан күреп юрау, аның төрле формалары, нардуган, нәүрүз вакытында теләкләр теләү, теләккә чыгу (яңгыр теләге), изгеләр каберенә барып теләк теләү кебек йолалар – шуларның бер чагылышы булып исәпләнергә хаклы. Пенза өлкәсендәге (Пенза өлкәсе, Каменка районы, Кикино авылы) мәгълумат җыючылар Арслан Полка исемле кешенең каберенә мөнәсәбәтле ышану һәм йолаларга еш туктала. Бу тарихи шәхеснең каберлегенә куелган чардуганга күпсанлы кульъяулыклар бәйләнгән. Җирле халык моны кабер иясенең изге җан булуы белән аңлата, каберлектә шушындый хәер калдырып, теләк телисең, үтенечеңне сөйлисең икән – теләкләрең тормышка ашачак дип ышаналар. Бу шәхес хакында телдә күп легендалар яши, аларның күбесе К. Акъегетнең «Пенза татарлары» (Акъегет, 2001: 140) китабында дөнья күрә.

Гаилә-көнкүреш йолаларына бала туу белән бәйле, никах туе, кешене соңгы юлга озатуга мөнәсәбәтле йолалар комплексы, кузайтын (каршы алу), хәрби хезмәткә озату һ.б. бәйрәмнәр керә. Билгеле булганча, гаилә-көнкүреш йолаларыннан *туй йола*сы иң күренеклесе. Халыкның гаилә коруга җитди мөнәсәбәте, тормыш төзү кануннары бик борынгыдан формалашып, милли яшәү рәвеше буларак оешкан һәм туй йолаларында чагылыш тапкан.

Татарларның башка этник төркемнәре кебек үк, татар-мишәрләрнең туй йолалары фольклорчы галимнәрнең игътибар үзәгендә тора. Бу юнәлештәге хезмәтләрдән, Р.К. Уразманова (Уразманова, 2001: 196 ), Ф.С. Баязитова (Баязитова, 1992: 295; 1995: 56; 2003: 288)

Р.М. Мөхәммәтҗанов (Мөхәммәтҗанов, 1977: 11; 1990: 156), З.М. Арикеева-Брусько (Брусько, 2012: 21) һ.б. хезмәтләрен күрсәтергә мөмкин. Туй йоласы фольклорчылар, этнографлар тарафыннан да яратып, тәфсилләп, шактый өйрәнелгән өлкә. Фольклор һәм шигърият белгече М.Бакировның соңгы елларда дөнья күргән җитди, саллы хезмәтләрендә дә бу юнәлештә эзләнүләр аерым урын алган. (Бакиров 2008: 359; 2012: 400) Бу хезмәтләрдә Пенза, Мордовия татар-мишәрләренең халык иҗаты үрнәкләренә дә шактый урын бирелгән.

Төрле этаплардан торган катлаулы бер күренеш буларак Мордовия мишәр-татарларының туй йоласы М.М.Акашкин хезмәтендә Мордовия халкы туйлары белән чагыштырма аспектта өйрәнелә. (Акашкин, 2000: 154). Хезмәт туй йолаларын үтәү вакытында башкарыла торган җырларны өйрәнүгә багышланган булса да, эшнең шактый өлеше туй йолаларын характерлауга, үзенчәлекләрен, бүгенге көндә сакланылыш дәрәҗәсен күзәтүгә багышлана.

Р.Мөхәммәтҗанов билгеләвенчә: «Туй йолаларының төп юнәлеше һәм составы бер йорттан икенче йортка кыз (кәләш) тапшыру, булачак ирнең йортына озатудан тора. Калган бөтен эшләр (башта, озатканда, соңыннан булган чаралар) һәммәсе дә әлеге үзәк акт – ярәшелгән кызны күчерү – тирәсенә тупланган». (Мөхәмәтҗанов, 1977: 11) Бу процесс күпчелек халыкларда һәм татарларда да шулай булган һәм берничә көнгә яки айга сузылган. Шул рәвешле катлаулы фольклор-этнографик комплекс барлыкка китерелгән.

Кеше гомерендә иң әһәмиятле урын тоткан туй, бала туу һәм кешене мәңгелек дөньяга озату белән бәйле йолалар татар халкының гомер юлындагы иң әһәмиятле этапларны үз эченә ала. Ф.С. Баязитованың алда телгә алган "Гомернең өч туе" (Баязитова, 1992: 295) китабы чагыштырма аспектта төзелгән булуы ягыннан үзенчәлекле. Бу хезмәттә төрле регионда яшәгән татар-мишәр халкының гаилә-көнкүреш йолалары терминологиясе кулланылышы, мәгънәсе хакында аңлатма бирелә, аларның үзенчәлекләре, вариантлары тәкъдим ителә. Китапта галимә Мордовия һәм Пенза татар-мишәрләре йолаларын да терки. Шундыйлардан, Мордовия татарлары йолаларына хас булган төшенчәләрдән, "кийәү җийу" (26 б.), "туй мунчасы" (33 б.), "еңгә" (45 б.), "шалдырдавык" (53 б.), "мәһәр" (100 б.), "кода уняу" (111 б.), һ.б.; Пенза мишәрләре теленнән язылган үрнәкләрдән "башкода" (10б.), "бузал" (18 б.), "йарашу" (18 б.), "киңәш" (20 б.), "сүз алырга килү" (23 б.), "сүз бирү, йакшы сүз бирү" (23 б.), "ир артыннан чыгу" (23 б.), "ырланып китү" (23 б.), "никах сывы" (30 б.), "кодагигый бару" (39 б.), "арчига килү" (44 б.), "чыңгыл" (53б.), "йараш туй" , "туй келәве" (118 б.) һ.б. китерелә. Китапның туйлар белән бәйле бүлеге – эшнең иң зур өлешен тәшкил итә: аның аерым этаплары, кыз алуның хикмәтләре, яшьләр, кода-кодагыйлар мөнәсәбәте, туй киемнәре белән бәйле күптөрле төшенчәләр татар халкының тел һәм күңел байлыгын да, яшьләргә яңа тормышны башлауның никадәр җитди эш булуын да аңлатуга юнәлдерелгән. Гаилә-көнкүреш йолалары, һичшиксез, боларны үткәрү барышында әзерләнә, кулланыла торган ризыклар белән дә бәйле.

Мордовия татар-мишәрләреннән 2015 елда КФУ галимнәре һәм студентлары татарыннан язып алынган фольклор материаллары арасында туй йолалары белән бәйле шактый кызыклы мәгълүматлар бар. (Кадирова һ.б., 2015: 324) Бу җирлектә тупланган туй йоласының тәртибе, бала туу, аңа исем бирү һәм аны үстерү барышында үтәлергә тиешле йолалар, һәм, кеше

вафатыннан соң башкарылырга тиешле гамәлләргә дә китапта аерым урын бирелгән.

Мордовия республикасының экспедиция оештырылган кайбер татар-мишәр авылларында туй йолаларының шактый сакланган булуы игътибарга лаек. Бу якларда туй йоласы аерым ритуалларны берләштерә. Шундыйлардан, *яучылау* өчен биредә иң уңышлы көн дип чәршәмбе һәм җомга көн санала. Яучы булып егетнең әти-әнисе яки берәр якын туганы килергә мөмкин. Кыз бу егеткә барырга риза булса, аның әти-әнисе чәй өстәле артында яучыларга хәбәрне әйтәләр һәм *кул билгесе көнен* билгелиләр. *Ярәшү* яки кул билгесе көнне кыз йортына егетнең әти-әнисе бүләкләр белән килә. Алар булачак кодалар белән калым хакын, кызга нинди киемнәр алырга кирәклекне (елның дүрт фасылына да яраклы баш, өс, аяк киемнәре, туй, туй арты көне өчен киемнәр һ.б.) сөйләшәләр. Аларны тәмле ризыклар белән сыйлап, кызның ризалык билгесе буларак берәр бүләк, мәсәлән, сөлге биреп озаталар. Кияүнең нинди вакытка килергә мөмкин икәнен әйтеп җибәрәләр. Билгеләнгән вакытка кияү үзенең бертуган абыйсы яки энесе, я берәр якын дусты белән килә. Кызга бүләк итеп алтын бизәнү әйбере һәм чәчәк алып килә. Аннан соң *сүз бетерү* үткәрелә, ягъни бу көнне егетнең әти-әнисе һәм якын туганнары җыелышып кыз йортына баралар. Алар барысы да яшь киленгә һәм аның әнисенә бүләкләр алып киләләр. Кияүнең әнисе кәләшкә алтын бизәнү әйберсе бүләк итә. Кодагыйлар да бер-берсенә бүләкләр бирешәләр. Сүз бетергән көнне кичен кыз өенә ике яктан да яшьләр җыела. Әлеге табынны *туй* дип йөртәләр. Бу көнне кунакка килгән яшьләрнең барысына да кызның әнисе бүләк биреп җибәрә.

Әлеге китапта туйның иң әһәмиятле булган өлеше – *никах (фатия)* турында да шактый информация бирелә. Башка җирлектә яшәүче татарлардагы кебек үк аны үткәрүдә ислам, шәригать кануннары өстенлек итә. Никах кыз өендә укыла, нигездә өлкәнрәк буын кешеләр килә. Мулла никах укыр алдыннан кыздан өч тапкыр рөхсәт сорый. Кызның уңай җавабыннан соң гына никах укыла. Кияүнең әтисе мәһәрне кәләшнең кулына тапшыра. Башка яктагыдан аермалы буларак никах бәйрәмен бу якларда фатия дип атау да бар, никах укыту вакытында өстәлгә савыт белән су куела, аны “фатия суы” дип атыйлар. Никахтан соң бу су белән яшьләр кулларын, битләрен юу гадәте кызыклы, ахырдан суны агач төбенә түгәләр.

Өлкәннәр таралгач, кияү, дус егетләре кызны алырга килә. Шул вакыт мылтыктан ату йоласы да саклануы хакында информация бар. Мылтыктан ату аерым урынныйрда, мәсәлән, Себер татарларында бүгенге көнгә кадәр сакланган. Туй йоласына караган фәнни хезмәтләрдә бу күренешкә карата да фикерләр бар. Р.Мөхәмәтҗанов кияү килгәндә мылтыктан атуны борынгыдан калган йола элементы дип күрсәтә һәм борынгы кеше карашынча, усал, явыз көчләргә каршы тору чарасы, ягъни апоторопик магиянең бүгенге көнгә килеп җиткән күрсәткече дип саный. (Мөхәмәтҗанов, 1977: 28).

Кыз өендә ашап-эчкәч, кияү, әти-әнисеннән рөхсәт сорап, кызны алып китә һәм егет ягы әзерләгән табынга – туй мәҗлесенә – *кодага* кайталар. Кодада кеше бик күп була, зурлап уйнала. Ирләр һәм хатын-кызлар аерым өстәлләр артына утыра. Яшь парлар да иң якын туганнары белән аерым утыралар. Кунаклар бераз ашап-эчкәч, яшь кәләш белән кияүне хатын-кызлар ягына «тау итәргә» ягъни, күренергә чакыралар. Күренекле галим М.Бакиров «Туй табыны җырларының берише, мәҗлес ахырында җырлана торганнары, «тау итү җырлары» дип атала. Тау итү кыпчаклардан килгән борынгы гыйбарә, рәхмәт белдерү мәгънәсендә. Мондый җырлар мишәрләрдә һәм

кершен татарлары арасында күбрәк сакланган» – дип яза. (Бакиров, 2008: 79). Туй җырлары турындагы мәгълүматлар күп чыганакларда бирелгән.

Мордовия һәм Пенза өлкәсендә яшәүче кардәшләребезнең гаилә йолаларының иң матуры – никах туе йоласын бүгенге көнгә кадәр шактый тулы формада саклап үткәрүләре һәм киләчәк буынга җиткерүләре бик матур күренеш. Әлбәттә, аерым үзенчәлекләр олы буын хәтерендә генә истәлекләр рәвешендә сакланып калган, кайбер очракларда йолаларның аерым өлешләре өлкән буын галимнәр язмаларында гына саклана.

## ӘДӘБИЯТ

Акашкин М.М. Свадебные обряды, песни татар-мишарей и мордвы (Сравнительный анализ): дис. … канд. филол. наук. – Казань, 2000. – 154 с.

Акъегет К. Пенза татарлары: кыскача тарих, авыллар, халык иҗаты. – Казан: “Матбугат йорты” нәшр., 2001. – 140 б.

Бакиров М.Х. Татар фольклоры. –Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.

Бакиров М.Х. Татарский фольклор. – Казань: Ихлас, 2012. – 400 б.

Брусько З.М. Фольклор семейно-бытовой обрядности татар / Автореф. канд. филол.наук. - Казань, 2012. – 21 с.

Мордовия Республикасы һәм Пенза өлкәсе татарлары: диалектология һәм халык авыз иҗаты материаллары / Төз.-авторлар Э.Х.Кадирова, Г.Р.Галиуллина, Ф.С.Сәйфулина, Ә.Ш.Юсупова. - Казан: Казан ун-ты нәшр., 2015. – 324 б. китабы материаллары нигезендә.

Мөхәмәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (Туй поэзиясе) “Татар халык иҗаты” курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы. – Уфа, 1977. Б. 11.

Рогачев В.И. Культ покровительницы воды в свадебной обрядности и в фольклоре народов среднего Поволжья // Интеграция образования, 2003. - № 2. – С.154-157.

Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. – Казань: Тат.кит.нәшр., 1995. – 156 б.

Татар-мишәр рухи мирасы: гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. – Саранск: Татарская газета, 2003. – 288 б.

Уразман Р. Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992.

# ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНЫҢ КАЙБЕР АФОРИСТИК ЖАНРЛАРЫНДА ВАКЫТ ТӨШЕНЧӘСЕН БЕЛДЕРГӘН СҮЗЛӘР

# (THE NOTION OF TIME IN SOME APHORISTIC GENRES OF TATAR ORAL FOLK ART)

**Ruzilya SALAKHOVA***

## SUMMARY

Despite the fact that a person is not born with a sense of time, the concept of time has always played an important role in the life of the whole society throughout its history. Acting as a parameter of the existence of the world, this concept, subjectively and consciously experienced by people. In order to understand the attitude of the people of the past eras, to the time as the basic category of human thinking, it is necessary to turn to his oral creativity. It is in it that the deep layers of his spiritual culture are reflected, expressing the cognizable in the already cognized, providing a holistic perception of artistic reality in compositional works. The presented article is devoted to the problem of consideration of the notion of time in the Tatar folklore text. Discusses some of the variety of the folklore of the time, depending on genre classification. The originality of the image of time in Tatar folklore is in close connection primarily with the fact that it is neither the actual nor the depicted author. This folk lyrics is radically different from the lyric book, where the author is not only required, but where he plays a very important role as a "lyrical hero" of the work. Tatar folk lyrics are not so much" created " as they are performed. The place of the author stands in her performer. Her "lyrical hero" is to a certain extent the performer himself. The singer sings about himself, the listener listens to about yourself.

Вакыт төшенчәсе төрле мәдәниятләрдә һәм җәмгыятьнең төрле үсеш стадияләренә бәйле рәвештә төрле халыкларда аерым бер дәвердә бер-берсенә охшаш булмаган күзаллаулар формалашуы белән бәйле. Бу күренеш бер төркем факторлар белән билгеләнә. Бүгенген көн күп кенә галимнәрнең фикеренчә, үткән белән киләчәк турындагы күзаллаулар мәгълүмат тапшыру юнәлешендә бара, ягъни кешелек җәмгыятенең тәҗрибәсен үткәннән киләчәккә тапшыруы процессы. Шулай итеп, фәнни яссылыкта вакыт төшенчәсе үткәннән киләчәккә агучы процессны белдерә.

Вакыт төшенчәләре татар теле фондының әһәмиятле компонентын тәшкил итәләр. Борынгы чор җәмгыятендә барлыкка килгән халык авыз иҗаты әсәрләрендә, аерым алганда, афористик жанрлардан булган мәкаль-әйтемнәрдә, сынамышларда әлеге төшенчәләр аеруча зур урын алып торалар.

Мәкаль кыска һәм тирән мәгънәле булганга, аны халык хикмәте дип атау барлык халык фольклорында бик таралган. Һәр халыкның мәкале үзенчә. Менә шулардай мәкальнең иң зур күпчелеге һәр халыкның үз иҗтимагый-тарихи тормыш тәҗрибәләреннән һәм ышануларыннан, аның үз теленең иҗат һәм сурәтләмә мөмкинлекләренә таянып барлыкка килгәнлеге аңлашыла. Мәкаль үзе шулай бик кечкенә булса да, күпьяклы, үзенчәлекле һәм хикмәтле нәрсә. Җыйнап әйткәндә мәкаль нәрсә дигәнгә шундый

---

* Candidate of Philological Sciences. Associate Professor, Kazan Federal University, Kazan.

билгеләмә биреп була: сөйләшкәндә сүзгә ямь һәм куәт бирү өчен, көнкүрештә күп сыналган дәлил яки шигъри бер мисал урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин гомуми бер, тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре мәкаль дип әйтелә.

Нәкъ менә поэзия суфиларның мистик күзаллауларын һәм фикерләрен укучыга ирештерү өчен уңайлы әдәби төрләрнең берсе булып тора, чөнки үзе дә серлелеккә омтылган шигърият мистик фикер, образларны җиткерү өчен уңайлы форма санала (Кныш, 2004: 170), сакраль һәм дөньяви фикерләрне ирештерүдә чикләнмәгән мөмкинлекләр ача (Шиммель, 2000: 225). Суфичылык сүз сәнгате мистик әдәбият булып, серлелекне, дөньяны танып бетерә алмау фикерен алга сөрә, фикерне “ачкыч” булган символлар, киная, төсләр символикасы аша җиткерә һәм шул яктан әдәби телне баета, стильне камилләштерә. Поэтик телнең күпкатламлы булуы шагыйрьләргә төрле кеше төрлечә кабул итәрлек, ягъни ике эчтәлекле әсәрләр иҗат итү мөмкинлеген калдыра (Кныш, 2004: 170). М. Степанянц фикерен дәвам итеп әйткәндә, «суфичылыкның мөселман дөньясында, мәдәниятендә тоткан урыны ничек кенә каршылыклы булмасын, аның шигърияткә, шигъри тел үсешенә уңай тәэсирен, йогынтысын кире кагып булмый» (Степанянц, 1995: 10).

Әлеге үзенчәлекләр XIX гасыр әдипләре (Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Г. Кандалый, Ш. Зәки һ.б.) иҗатында да бөтен тулылыгында чагылыш таба. Көнчыгыш әдәбияты үрнәгендә рухи халәтне, хис-тойгыны җиткерү өчен символик образлар системасы эшләнә һәм алар үзенә бер мәгънәне беркетә. Мәсәлән, исерү хакыйкатьне аңлау, Аллаһ белән кушылу, шәраб – хакыйкать, шәм – Аллаһ, матур кыз, Ләйлә, сәмруг кош та Аллаһ эчтәлеген ала; гөл һәм былбыл, шәм һәм күбәләк илаһи, Аллаһка мәхәббәтне белдерә (Пригарина, 1989: 15). Догалар, зикер, мәдхия, мөнәҗәт, тәүхид, нәгытьләр суфичылык әдәбиятының төп жанрлары булып формалаша. Мәсәлән, Ш. Зәки иҗатында суфичыл жанрлардан тәүхид (“Игре юлларны куюбән, тугры юла варасы...”, “...уйгангым килер” һ.б.), нәгыт (“Мәдхе рәсүл”, “И, хәбиби падишаһи кәрдигяр...”), миграҗия (“Гашикъ ашәфтәнең биһүдә сайма аһыны...”) һ.б. жанрлар урын ала.

Билгеле булганча, классик суфичылык әдәбиятының теле булып фарсы теле санала һәм ул Иран, Әфганстан, Урта Азия Әзәрбәйҗан, Төркия, Һиндстан кебек ил-төбәкләрдә таралыш ала. Моннан тыш, гарәп, төрек, хәтта

грек телендә язылган суфичыл характердагы әсәрләр билгеле. Гарәп әдәби телендә суфичыл эчтәлектәге бик күп поэма һәм фәлсәфи трактатлар дөнья күрә (Кныш, 2004: 245). Башлангыч чорда фарсыча, гарәпчә генә булса да, галимнәр фикеренчә, һиҗри VIII гасырдан башлап төрки телдә дә суфичыл әсәрләр иҗат итела башлый. Суфичылык әдәбиятларының классиклары булып Ибн Гарәби, Ибн Фәрид, Гатауллаһ Искәндәри гарәп, Гаттар, Сәнагый, Әнвәри, Хафиз, Руми фарсы, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакырганый, Фөзүли һ.б. санала. Инглиз галиме Аннемари Шиммель күрсәткәнчә, “суфичылык тел үсешенә дә зур йогынты ясый: юристлар, дин белгечләре һәм тәрҗемәчеләр суфичылыкка хас әйләнмәләрне тел өлкәсенә алып кереп, гарәп телен баета һәм камилләштерә. Бу процесста мистиклар да зур урын тота. Поль Нвийа нәкъ менә мистиклар ярдәме белән гарәп телендә күпмәгънәле, яшерен эчтәлекле сүзләрнең артуын билгели: суфиларның хезмәтләрендә тел-сурәтләү чараларының төрлелеге белән янәшәдә мәгънә тирәнлеге дә күзгә ташлана” (Пригарина, 1983: 34). Авторлар тарафыннан символ, сүзләрне, аваз-хәрефләрне мистик уйнату кебек алымнар суфи әдәбиятта шактый эшкәртелә, стилистик яктан катлаулы “техник телнең” формалашуын тәэмин итә (Шиммель, 2000: 50). Суфичылык әсәрләренең теленә күзәтү ясаган Н. Пригарина фикеренчә, мондый стиль XI-XII гасырларда ук инде канун буларак билгеләнә, гомум кабул ителә һәм гадилек билгеле дәрәҗәдә кире кагыла. Мондый стиль әдәбиятның алдагы дәверләрендә саклана һәм үстерелә (Пригарина, 1983: 95).

Әлеге фикерләр татар суфичылык әсәрләренә карата да актуаль. Билгеле булганча, төрки-татар дөньясында сүз сәнгатенең башлангыч чорларыннан ук шигърият әдәбиятның “югары төре” булып санала. Төрки язма әдәби теленең үк лексик кына түгел, грамматик яктан да чит тел алынмалары, грамматик формалары белән чуарлануы, шигъри телнең сөйләмә телдән аерып куелуы шуңа бәйле (Благова, 1977: 99). Шигъри әсәрләр, нигездә, югары стильдә иҗат ителә һәм Урта Азиядә белем алып, гарәп-фарсы телләрен камил белгән билгеле бер катлам кешеләргә (галимнәр, дини эшлеклеләр, суфи шагыйрьләр) йөз тотып языла. М.И. Мәхмүтов билгеләп үткәнчә, XVII-XIX гасыр суфи әдипләре үзләренең әсәрләрен гарәп-фарсы классик әдәбиятына йөз тотып, ияреп яза, гарәп-фарсы алынмаларын күпләп кулланулары да шуның белән аңлатыла (Махмутов, 1966, 12). Ә. Каргалый, Һ. Салихов, Ш. Зәки кебек шагыйрьләр әсәрләре телендә суфичылык поэзиясенә хас мотивларның югары шигъри стильгә хас сыйфатлар белән кушылу тенденциясе күзгә ташлана. Мондый форма татар язма әдәби телендә шигъри вариантка хас традиция була. Гарәп-фарсы һәм татар теленә хас грамматик чараларның бергә үрелүе, төрлелеге әсәрнең стиле, жанры, авторның максаты белән дә бәйләнә (Ганиева, 2002: 18). Мәсәлән, Ш. Зәки әсәрләренең тел нигезен традицион угыз-кыпчак һәм гарәп-фарсы катламнарының берлеге тәшкил итә (Юсупов, 2004: 26-27). Бу исә, иң беренче чиратта, шагыйрьнең суфичылык традицияләренә йөз тотуы белән аңлатыла.

XIX гасыр суфичылык әсәрләре телендә тагын бер күренеш – стилистик һәм морфологик яссылыкларда мәгънәви һәм грамматик күчешләр күзгә ташлана. Стилистик яктан бу үзенчәлек әдипләрнең гади образларны аллегорик калыпта кулланылуына бәйле. Мәсәлән, Ш. Зәкинең “…булгай-булмагай” әсәрендә “сәүдә” сүзе аллегорик яктан суфичыл “мәхәббәт” мәгънәсен бирә:

*Бу җәһанның шәһринең базарының сәүдәсе күб,*

*Кыйл бу сәүдәне янә базары булгай, булмагай.*

Морфологик яссылыкта исә Ш. Зәки, Ә. Каргалый әсәрләрендә гарәп-фарсы грамматик категорияләренең башка функциядә, мәгънәдә килүе яки башка сүз төркеменә күчүе күренә. Мәсәлән, гарәп теленә хас исем фигыль-масдарның һәм сыйфат фигыльләрнең рәвеш функциясендә килү яисә фигыльнең ярдәмче сүз төркеменә күчү очраклары күзәтелә.

Гарәп-фарсы телләренең йогынтысын лексик-стилистик, морфологик яссылыкларда күзәтү генә дә XIX гасыр әсәрләрендә суфичылык традицияләренең көчле булуын күрсәтә. Безнең карашыбызча, шагыйрьләр үзләренең әсәрләрендә гарәп-фарсы грамматик формаларын суфичылык әдәбияты теленең үзенчәлекләрен җиткерергә теләү максатыннан аңлы рәвештә куллана.

Көнчыгыш әдипләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнеп, Лазар өч калыптагы телне аерып чыгара. Беренче калып сүзләрне үз мәгънәләрендә кулланучы гади сөйләм телен, "мистик булмаган" телне үз эченә ала. Икенче калып тел дип галим конвенциональ телне аерып чыгара, аның үзенчәлеге итеп вакыт үтү белән мәгънәви калыплашкан, канунлашкан символларның кулланылуын күрсәтә. Өченче калып тел буларак ассоциацияләргә корылган "яшерен, мистик" тел билгеләнә, төп хасияте итеп берничә "мәгънәви баскычлы", берничә төрле укылышка урын калдырган символларның бирелеше алына (Пригарина, 1983: 101). Бу классификациягә таянып гомумиләштергәндә, безнең карашыбызча, XIX гасыр суфи әсәрләренең теле өченче калыпка туры килә.

Шулай итеп, татар суфичылык поэзиясе телендә тел-сурәтләү чаралары, образлылыкның гына түгел, грамматик формаларның да стилистик вариантлар тәшкил итүе күзәтелә; төрле системадагы телләрнең стилистик, грамматик чараларын кушып иҗат итү – шул чор язма әдәби теленең шигъри варианты буларак билгеләнә.

## ӘДӘБИЯТ


Абилов Ш. Суфичылык // Татар әдәбияты тарихы: 6 т. – Казан: Тат. кит. нәшр., – Т.1: Борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты. – 1984. – Б. 356-366.

Бертельс Е.Э. Избранные труды: В 3 т. – М.: Наука, 1965. – Т.3: Суфизм и суфийская литература. – 560 с.

Благова Г.Ф. О методике изучения морфологии средневековых тюркских поэтических текстов // Вопросы языкознания. – 1977. – № 3. – С. 86-100.

Ганиева Р.К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во КГУ, 2002. – 272 с.

Идиятуллина Г.Г. Абу Наср Курсави и среднеазиатские истоки татарской общественной мысли конца XVIII – начала XIX веков (по материалам трактата «ал-иршад ли-л-‘ибад»: автореф. дисс. … канд. истор. наук. – Казань, 2001. – 22 с.

Кныш А.Д. Мусульманский мистицизм. – СПб.: "Изд-во "Диля", 2004. – 464 с.

Махмутов М.И. Фонетическое и грамматическое освоение арабских заимствований в татарском литературном языке: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. – Казань, 1966. – 20 с.

Пригарина Н.И. Образное содержание бейта в поэзии на персидском языке // Восточная поэтика. – М., 1983. – С. 89-108.

Пригарина Н. Введение // Суфизм в контексте мусульманской культуры. – М.: Наука, Гл. ред. вост. лит., 1989. – С. 3-17.

Сибгатуллина А.Т. Суфизм в татарской литературе (истоки, тематика и жанровые особенности): автореф. дисс. … д-ра филол. наук. – Казань, 2000. – 62 с.

Степанянц М.Т. Поиск скрытого смысла // В поисках скрытого смысла. Духовное учение Руми. – М.: Изд-во “Ладомир”, 1995. – С. 4-15.

Тримингэм Дж.С. Суфийские ордена в исламе / Пер. с англ. А.А.Ставиской, под ред. и с предисл. О.Ф.Акимушкина. – М.: «София», ИД «Гелиос», 2002. – 480 с.

Шиммель А. Мир исламского мистицизма / Пер. с англ. Н.И.Пригариной, А.С.Раппопорт. – М.: Алетейа, Энигма, 2000. – 416 с.

Юзеев А. Татарские мыслители конца XVIII – XIX веков о суфизме // Суфизм в Поволжье: история и специфика. – Казань: Изд-во «Иман», 2000. – С. 29-36.

Юсупов А.Ф. Морфологические особенности языка произведений суфийского поэта I половины XIX века Шамсетдина Заки: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. – Казань, 2004. – 29 с.

# МӨХӘММӘТ МИРЗАНЫҢ ФӘЛСӘФИ ЛИРИКАСЫНДА ШӘРКЫЙ ТРАДИЦИЯЛӘР ЯҢАРЫШЫ

# (THE REVIVAL OF EASTERN TRADITIONS IN THE PHILOSOPHICAL LYRICS OF MUHAMMAT MIRZA)

**Nurfiya YUSUPOVA***


## SUMMARY

In the article features of philosophical lyrics of Muhammat Mirza are considered, its aesthetic nature is revealed. Scientific novelty is determined by a different approach to studying the lyrics of Muhammad Mirza: his philosophical lyrics are explored against the background of the re-creation of coded eastern images and symbols, motifs, and also in the broad context of Eastern literature and Islamic philosophy. During the research it is proved that his philosophical works testify to polyphony and intertextuality in modern Tatar poetry. The author establishes a dialogue with medieval oriental poetry and Tatar literature of the Middle Ages.

On the material of the poet's works, oriental traditions are revealed, manifested at the level of principles and techniques of the artistic image, the genre paradigm and the figurative structure of texts. At the same time, the constructive principle in his philosophical lyrics is the use of religious-Sufi and Eastern-Romantic symbols. In the course of the research, frequently used stable symbols and codes are allocated, their hidden semantic and philosophical-aesthetic load is determined.

In the framework of this study it is proved that in the poet's philosophical lyrics the works stylized under the genres of medieval Eastern poetry dominate and have common structure-forming features. It is established that in the work of Muhammad Mirza, oriental poetry genres undergo transformation. As such, rubai, kasida, gazelle and pentacism are revealed. All this allows us to state that the poet's philosophical poetry has specific features of development in which the processes of self-identification of national literary and artistic systems manifest themselves.


М.Мирза иҗаты соңгы елларда сүз сәнгатендә барган төп тенденцияләрне үзендә туплый, шигырь-поэмаларында кешелекнең яшәеш кануннарын аерып чыгарган, кешене олы кыйммәт итеп күтәргән яисә тормыш закончалыкларын тәнкыйть утына алган үзгә әдәби модельне укучы хөкеменә тәкъдим итә.

Узган гасыр ахырында иҗтимагый-сәяси вазгыятьнең алышынуы үзенчәлекле идеологик мәйдан буларак формалашып җиткән татар шигъриятенә дә көчле борылыш ясый, сүз сәнгатендә яктыртылган проблемалар гомумкешелек югарылыгына күтәрелеп, поэзия үзгә фәлсәфи-әхлакый, эстетик, сәяси кыйммәтләрне һәм аларны җиткерүнең үзгә юлларын, алымнарын, калыбын эзли башлый. Аерым сүз осталары татар шигъриятенең алга таба үсешен рус яки көнбатыш әдәби кыйммәтләренә, гареб эстетик һәм сәнгати кануннарына юнәлтеп үстерүдә, аерым

* Associate Prof., Candidate of Philology, Kazan Federal University, Kazan.

шагыйрьләр исә үз, нигез традицияләрне яңартуда, көнчыгыш әдәби үзенчәлекләрен заманга яраклы дәвам итүдә күрә.

М.Мирза икенчесен кулай дип саный, шигъриятнең үсешен асыл кыйммәтләрне милләт хәтеренә төшерүгә һәм күңеленә салу юлларын яңартуга бәйли, шәркый эстетик һәм фәлсәфи-этик кыйммәтләрнең, сәнгати алымнарның актуальлеген югалтмавын дәлилли. Бу сыйфат аның шигырьләрендә чагылыш тапкан дөнья сурәтендә, лирик геройның дөньяга карашында яки фәлсәфи күзаллауларда, тәрбияви максатларда гына күзәтелеп калмый, сурәтләү чаралары, шартлы-эмоциональ, эчке, субъектив эчтәлеккә ишарәләгән образлылыкта, жанрлар төрлелегендә яисә шигырь калыбын, хәтта үлчәмен сайлауда да ачык күренеп тора. Аның шигырь-поэмалары турыдан-туры фәлсәфә сатуга корылмый, шагыйрь еш кына аерым авторларның әсәрләреннән өзекләрне эпиграф итеп ала, билгеле шәхесләрнең образларына мөрәҗәгать итә яки аерым сүз-образларның мәгънәләрен “уйната” башлый, аерым гыйбарәләрне афоризм дәрәҗәсенә күтәреп чарлый. Аерым әсәрләрдә шәркый әдәби сурәтләр шигырь структурасына уңышлы кертеп урнаштырыла, көнчыгыш, ислам фәлсәфи концепцияләренә хас караш-билгеләр алга чыга, хәтта әдәби сурәтләүдә гарәп-фарсы лексик берәмлекләренә (җаһил, шаһ, өммәт, акын, касә, иҗтиһат һ.б.) зур урын бирелә, шәркый әсәрләргә охшатып стильләштерү дә күзгә ташлана.

Һәр шагыйрьнең иҗат йөзен билгеләгән бер төп сыйфат-үзенчәлек була, гадәттә, ул шуңа мөнәсәбәттә әдәбият тарихында үз урынын ала да. М.Мирза иҗатын билгеләгән андый хасиятләрнең берсе итеп итеп нәкъ менә фәлсәфилекне аерып куярга мөмкин булыр иде. Мондый әсәрләрдә лирик герой философ статусында калка, ул кеше кыйммәте, кеше гомеренең бәһасе, аның яшәеш кануннары, яшәү һәм үлем, гомумән, яшәешнең асылы турында уйлана, яшәү һәм үлем бөтенлеген ислам кануннары яктылыгында күзаллый.

Лирикасындагы бер төркем шигырьләрнең үзәгенә кеше фәлсәфәсе куела, яшәешнең мәгънәсе, кешенең бу җирдәге миссиясе хакында уйланулар үзәк лейтмотивны тәшкил итә. Яшәешнең асылын танып белергә омтылу барышында М.Мирза еш кына кеше гомеренең төрле этапларын тергезергә ярата. Мәсәлән, “Хисләр чакырып алыр кунак түгел...”, “Сәбәп итәре табыла...”, “Күз”, “Миндә күзләр салмаклыгы”, “Кара каен” һ.б. шигырьләрдә табигать күренешләре, ел фасыллары, төсләр мөһим роль уйный, аларның һәркайсы фәлсәфи гомумиләштерүгә ия. Мисал өчен, “Кара каен” шигырендә кара каен образы ак каеннар турында шигырь укып күнеккән укучыны сискәндереп куя, алга таба строфадан-строфага аның каралыгының сәбәпләре ачыкланып бара, шуңа бәйле төстә ул берничә мәгънәне үзенә сыйдырган символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Бер яктан, мәңге табылмаслык бәхетне эзләп, авыллардан, әнкәләре катыннан киткәннәрне хәтерләткән кылганнар һәм карга оялары образлары белән янәшәлектә ул ташландык нигез кебек укыла. Икенче яктан, шушы ук образлар белән янәшәлектә ул юкка чыккан авыллар белән ассоциация тудыра. Өченче яктан, лирик геройга гомеренең үтүенә бәйле туган сызлануны җиткерергә ярдәм итә:

Япа-ялан кырда
Шадра кара каен...
Охшап барам аңар,
Гомер үткән саен.
Буразнасын ярып,

Кара ятты йөзгә...
Янып бетеп гомер,
Кереп барам көзгә (Мирза, 2016: 32).

Шуның аша М.Мирза табигатьтә генә түгел, яшәештә дә һәр кеше ялгыз, фани, вакытлы, үтә-югала, дип кабатлый.

Шуңа да М.Мирзаның кеше фәлсәфәсенә корылган күп шигырьләрендә лирик герой сызланучан, нечкә күңелле, мондый шигъри үрнәкләр татар поэзиясен экзистенциаль мотивлар белән баета. Мәсәлән, "Бербөтенлек хакның таләбендә" шигырьләр бәйләмендә шундый сыйфат белән очрашабыз. Кеше гомеренең чикләнгәнлеге ("Бер күк астында яшәп тә..."), язмышны үзгәртеп булмау тойгысы ("Козгын кунды өйнең түбәсенә...") лирик герой күңелендә сызлану тойгысын тудыра, шул герой "Барысы да үтә, бөтенесе кала" дип, кеше яшәешенә хас канунны кабатлый: бар да вакытлыча, бар да фани, барысы да үтә. Бу сызлану аерым кеше тормышыннан башлап, милләт яшәешенә кадәр гомумиләшә.

Кеше фәлсәфәсенә корылган шигырьләрдә иман ныклыгы, иман сафлыгы иң төп мәсьәләләрнең берсе итеп күтәрелә. "Бетмәс байлык – иман / Оҗмахка керерлек" дип санаган шагыйрь өчен иман дини-әхлакый, милли һәм мәдәни таяныч, рухи кыйммәт дәрәҗәсендә кабул ителә. Мәсәлән, "Иң тынгысыз матдә – кеше" шигыре мисалында карасак, иман ныклыгы аерым кешенең генә түгел, милләтнең дә әхлакый нигезе кебек аңлатыла. "Бүленгәнне бүре ашар" эпиграфы шигырьнең төп эчтәлеген ачу барышында ачкыч ролендә укыла һәм интертекстуаль вазифа үти. Мәкальнең үзендә бүленүнең аяныч нәтиҗәләргә китерүе хакында әйтелә һәм бердәм булу кешелек җәмгыятендә яшәүнең нигезе дип тәкъдим ителә. Әмма шигырь кысаларында "канатлы сүзләр, эзоп теленә охшаш кинаяләр остасы" (Акмал, 2003: 141) буларак танылган шагыйрь бүленү сүзе белән "уйный" башлый. Бер яктан, бүленү арту, күбәю кебек шәрехләнә:

Бүленешү – чиккән челтәр кебек,
Чылбырланып кабат берләшү.
Җирдә иң тынгысыз матдә – Кеше,
Яшәр өчен мәңге көрәшү (Мирза, 2016: 25)

Шул ук вакытта авторның матур бер табышы күзгә ташлана: бүленүне ул соңгы строфада һәр кешенең эчке халәтенә бәйләп куя, эчке рух, иманның бүлгәләнүе хакында сүз башлый. Кавем, милләтләрнең, гомумән, кешелекнең бердәмлеге, алга таба яшәеше өчен һәр кешенең күңел ныклыгы, иманының бүленмәслеге кирәк!

М.Мирзаның аерым шигырьләре дини мотивларга корыла һәм тулысынча дини контекстта укыла. Мондый әсәрләрендә шагыйрь кеше гомерен Аллаһ тарафыннан бирелгән бүләк итеп таный, язмышның алдан язылуы хакында сөйли, шуңа бәйле әт-тәүхид (бераллалык) идеяләре,ислам кануннарындагыча, язмышның Аллаһтан булуы мотивы алга куела. Мәсәлән, "Тере су" китабына кертелгән күп газәлләр шушы фәлсәфә тирәсенә туплана. "Бер күк астында яшәп тә..." шигырендә кеше тормышы Аллаһ биргән язмыш белән тыгыз бәйләнештә карала:

Язмышлар күктә языла,
Бер хакның ихтыяры... (Мирза, 2007: 31).

Мондый шигырьләрдә лирик герой ислам фәлсәфәсен, кануннарын яхшы белүче, тормыш авырлыгыннан Аллага сыенучы, аңардан ярдәм көтүче, аңа рәхмәт укучы диндар кеше булып күтәрелә, шушы юлны бу дөньядагы бердәнбер хакыйкать итеп таный. Мисал өчен, "...Фатихасыз бер

көнем дә торалмам...” шигырендә ул, ислам кануннарында язылганча, Аллаһтан ярдәмне үзе өчен генә түгел, бөтен милләт, кавем өчен сорый:

Фатихасыз бер көнем дә торалмам,
Ил-көнемә иминлек бир, бер Аллам.
Уң кыл юлын бөтен нәсел-ыруның,
Кодрәтең киң, рәхмәтең зур, бер Аллам! (Мирза, 2007: 8).

Дога кебек кабул ителгән шигырьдә “Бер Аллам” рәдифен кабатлау аша шагыйрь кешегә Аллаһ ярдәменең иң мөһим шарт икәнлеген кабатлый.

Шәркый шигърияттән яхшы мәгълүматлы шагыйрьнең дини эчтәлекле шигырьләрендә, кагыйдә буларак, көнчыгыш поэзиясендә еш кулланылган образларга, әдәби сурәтләргә мөрәҗәгать ителә. Шушы фонда кайбер шигырьләр суфичылык әсәрләренә охшатып, стильләштереп иҗат ителә, шул рәвешле М.Мирза иҗади экспериментлар ясап карый. Мәсәлән, “...Карыйм да бу дөньяның дүрт ягына...” шигырендә былбыл, гол кебек суфичылык поэзиясе аша таныла торган образлар, бер яктан, яшәешкә, тормышка булган мәхәббәтне ачуга юнәлтелә. Суфиларда былбыл-гөл парлы символик сурәте актив кулланыла; Аллаһ белән кушылу мотивының көчле булуы билгеле. Романтик шигъриятtә исә әлеге образлар аша дөньяви мәхәббәтне, сөйгән ярны ярату тойгысын җиткерү традициясе формалаша. Ләкин шагыйрь, образның мәгънәви кырын киңәйтеп, иҗади тәҗрибә ясый. Шигырь кысаларында әлеге сурәтләр лирик геройның үзен әйләндереп алган тормышка, яшәешкә мәхәббәте булып укыла. Икенче яктан, лирик геройның шушы тормышны бүләк иткән Аллаһка мәхәббәтен тасвирлауга юнәлтелә:

Хөрлегемә, саулыгыма мең разый,
Тулып агам гомер-дәрьям ярына.
Ил-йортым киң, ризыгым мул, рухым шат,
Юлым ачык – хилафсыз иманыма.
Ким итмәгән – ургып тора хисләрем,
Былбыл оя кора күңлем талына.
Күгем зәңгәр, таңым алсу, гөлләрем
Һәрчак шифа, илһам коя җаныма. (Мирза, 2007: 34).

Күренгәнчә, күңел талына оя корган былбыл, гөл образлары суфи контекстта кабул ителми, суфичылык символлары трансформацияләнгән вариантта кулланыла.

Моннан тыш поэтик яссылыкта нур образына басым ясала: ул мәңгелек нуры, яктылык нуры, илһам нуры, иман нуры кебек шәрехләнеп, төрле яссылыкларда аңларга мөмкин булган символ югарылыгына күтәрелә. Мәсәлән, “Адәм баласы” циклында нур образы илаһи биеклеккә күтәрелә алганнарның җаны (“Адәм баласының / Нурга әверелеп / күрер кайсылары?”), илаһи яктылыкка ышаныч, өмет (“Кап-кара төннең дә / бар сүрелмәс нуры...”), көнчыгыш фәлсәфи традицияләрендәгечә, җирдәге яшәешне барлыкка китерүче илаһи көч (“Бөек яратылышның / даһи иҗатчысы...”), Аллаһ рәхмәте (“Адәм баласының / җаны Илаһысы / нурында коенган...”), “Ахырзаман” шигырендә иман нуры (“Ана сөте белән керә, диләр, / Бала күңеленә иман нуры”) мәгънәләрендә укыла.

Фәлсәфи эчтәлекле аерым шигырьләр романтик материалда кешенең яшәеш кануннарын бәяләргә, яшәеш закончалыкларын фикерләр автор тарафыннан яшәеш кануннары буларак билгеләп куела. Мондый шигырьләрдә кешелекне рухи камиллеккә өндәү, әхлакый яңарышка чакыру мотивлары әйдәп бара. Әйтик, “Сорау һәм җаваплар” шигыре тулысы белән шушы каннунарны бер әсәр чикләрендә аерып чыгару омтылышын ясый. Шагыйрьнең “Адәм баласы” шигырьләр циклы да шул яссылыкта иҗат ителә һәм аксиологик кыйммәтләрне югары күтәрә.

Залимлек – Иблиснең
Кодрәте – дәрманы...

Адәм баласының
Сакланганын саклар
Бер Хакның фәрманы... (Мирза, 2017: 40).

Кеше тормышында залимлекнең Иблистән, дәрманы үзеннән булуы турында сүз алып барыла, әмма дәрманлы кешенең дә Аллаһ каршында көчсез булуы турында фикер әйтелә, Аллаһ кеше тормышының иминлеген, бөтенлеген саклаучы төп көч итеп раслана. Аллаһ – бердәнбер, абсолют. Автор шушы фикерне хакыйкать, аксиома итеп күтәрә. Әмма бу чынбарлыкны йолдыз булып яну бәхете тигән сирәкләр генә аңлый, кешенең фаҗигасе дә шунда, дип кабатлый автор.

Форма ягыннан шагыйрь иҗатындагы көнчыгыш әдәби традицияләренең дәвам ителүе, үстерелүе иң беренче нәүбәттә жанрлар төрлелегендә, жанрлык экспериментларында күренә. М.Мирза шигъриятенең иҗади йөзен билгели торган хасиятләрнең икенчесе – шәркый жанрларны тергезүдә яки трансформацияләүдә. Аның шигъриятендә газәл, робагый, касыйдә жанрларының урын алуы шул хакта сөйли. Билгеле, М.Мирза газәлләре, шәркый үзенчәлекләрне дәвам итүдән бигрәк, төрки-татар әдәби традицияләрен үстерә. Алар, гыйшык җырыннан бигрәк, иҗтимагый-социаль эчтәлек белән сугарыла. Дуртьюллык – робагыйларында исә фәлсәфи, әхлакый, гыйшкый (интим), иҗтимагый мәсьәләләр күтәрелә. М.Мирзаның робагыйлары структур яктан көнчыгыш әдәби традицияләрендәгечә төзелә:

Кемдә кемнең хакы йөри түләнәсе,
Кемне каплый кемнең кара күләгәсе.
Дөнья матур, дөнья киң, дип акыл сата
Денен, телен җуйган илнең кем-кемсәсе? (Мирза, 2016: 156).

Күренгәнчә, һәр строфа шигырьнең гомумидеясе тирәсенә берләшсә дә, аерым функция үтәве белән үзенчәлекле. Беренче юл, гадәттә, укучыны фикер кабул итүгә әзерли, икенчесе шуны көчәйтеп, фикерне киңәйтә, укучының игътибарын арттыра, фәлсәфи фикерне җиткерә, өченче тезмә фикерне кискенләштерә, дүртенчесе йомгаклый, төгәлләп куя. Иң “җаваплы” вазфаны башкаруына бәйле төстә, шәрык әдәбиятында аны “стун” (төп) дип атау да яшәп килә. Һәр робагыйда, шәркый традицияләргә хас булганча, әхлакый мәсьәләләр үзәккә куела; иҗтимагый-социаль кануннар да фәлсәфи-этик яссылыкта хуплана яки кире кагыла, рухи, әхлакый яңарышка өндәү мотивы көчле яңгыраш ала. Р.Ганиева фикеренчә, аларда рухи яңарышка чакыру, фәлсәфи-этик фикер әйтү теләге көчле (Ганиева, 2013: 13).

Шуның белән янәшәдә шагыйрь иҗатында касыйдә жанрының яңарышы да күзәтелә (Загидуллина, 2017: 231). Касыйдә жанры шәркый әдәбияттан үтеп кереп, төрки-татар шигъриятендә калыплашкан жанрларның берсе булып тора. Төрки касыйдәдә тематикасына мөнәсәбәттә берничә жанр формасы аерыла: сурәтләү, тасвирлау характерындагы касыйдә (аның язгы табигатьне сурәтләүче бәхәрия, шагыйрьнең уй һәм теләкләрен гәүдәләндерүче хөлия, мәхәббәт белән бәйле тойгыларны җиткерүче гыйшкия, төрле халәтләрне тасвирлаучы хәмрия кебек төрләре формалаша); мактау характерындагы касыйдә (аның кемнедер олылаучы мәдхия, авторның үзен мактаучы фәхрия, фәлсәфи уйлануларны җиткерүче хәмед, Мөхәммәдне мактаучы, зурлаучы нәгыть кебек төрләре урын ала); вафат булган затларны мактау характерындагы касыйдә-мәрсия; сатирик характердагы касыйдә-хәҗвия; дини характердагы касыйдә-мөнәҗәт; суфыйчылыкның теоретик нигезләрен лирик яссылыкта җиткерүче фәлсәфи касыйдә (аның укучыларны әхлакка өндәүче, киңәшләр бирүче әхлакый-дидактик һәм фәнни төрләре аерыла); ясалма касыйдә. М.Мирза иҗатында касыйдәнең сурәтләү, тасвирлау характерындагы формасы урын ала. “Күкләр хәбәр итә шул көн хакында...”, “Чигенде кыш – чигенгән гаскәр кебек...”, “Кышның китәсе килмиме һич кенә”, “Күкләр битараф түгел һәр тарафка...” һ.б. әсәрләр шул хакта сөйли.

Шагыйрь мондый әсәрләрен чагыштырмача мөстәкыйль булган икеюллык строфалардан, бәетләрдән төзи, алар а а б а в а... рәвешендә рифмалашып, гаруз белән языла:

Кышның китәсе килмиме һич кенә,
Өеп-өеп яуды кары кич белән.

Салкын тынын өрде бөтен җиһанга,
Салкын тунын, күлмәген кигәч кенә.

Ак мамыкка төрде каен, талларны,
Бөреләре ачылам дигәч кенә… (Мирза, 2007: 23)

Автор строфадан строфага кышкы табигатьне сурәтли, тасвирлау характерындагы касыйдәдәге кебек үк, һәр образ шушы функциягә буйсындырыла.

Шагыйрь иҗатында бишьюллыклар аерым әһәмияткә ия, бу яктан аның әдәби тәнкыйтьтә шактый бәяләнгән (Р.Ганиева, Д.Заһидуллина, Р.Харис, Ф.Хәсәнова һ.б. язмалары) "Адәм баласы" шигырьләр циклы аеруча үзенчәлекле. Ф.Хәсәнова әлеге бишьюллыкларны миниатюра жанр формасы итеп карарга тәкъдим итә (Хәсәнова, 2010: 137). Милли шигъриятттә "Туфан строфасы" буларак калыплашкан һәм лирик герой кичерешен, автор фикерен, текстларның яңгырашын, көен, хисси тәэсирен җиткерүгә йөз тоткан бишьюллыкны М.Мирза бөтенләй үзгә форма итеп коруга ирешә. Мәкаль-әйтемнәрне куллану, шигырь юлларын хикмәтле сүз әйтү традициясендәгечә төзергә омтылу, "шәркый" характерлы, бик нечкә иронияга, төртмәле кинаягә мөрәҗәгать итү – барысы да аның үзгәлеген, оригинальлеген тәэмин итә. Икенче яктан, шагыйрьнең осталыгы сүз-гыйбарәләр белән гаҗәеп оста эш итүгә, образларны көтелмәгән мәгънә бөтенлекләре, борылышлары белән баетып, бөтенләй көтелмәгән ассоциацияләр тудыра алуга да бәйле. Шуңа да алар, шәркый бишьюллыкларны стильләштерү кебек кенә кабул ителми, татар шигърияте өчен үзгә жанр формасы буларак мәйданга чыга. Бу форма аның матур табышы буларак бәяләнүгә лаек.

Әнә шулай М.Мирза шигърияте бүгенге әдәби барышта шәркый традицияләрнең дәвам ителешен, үстерелешен, мәгънәви баетылышын дәлилли һәм шигъриятнең милли нигезләрне, шәркый әдәби кыйммәтләрне югалтмавы хакында сөйли.

**ӘДӘБИЯТ**


Акмал Н. Шигырьне сагыну // Казан утлары. – 2003. - № 3. – Б. 139 – 145.

Ганиева Р. Акыллы сүз белән рухи-әхлакый яңарышка таба // М.Мирза. Биш юлым – биш гөлем. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. – Б. 5 – 30.

Загидуллина Д.Ф. Татарская поэзия рубежа XX-XXI веков (1986-2015г.г.): эстетические ориентиры и художественные поиски. – Казань: Изд.-во Академии наук РТ, 2017. – 268 с.

Мирза М. Тере су: газәлләр, робагыйлар, гыйбарәләр, шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. – 318 б.

Мирза М. Берүземә бер диңгез: шигырьләр, поэмалар, гыйбарәләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2016. – 222 б.

Мирза М. Адәм баласы // Казан утлары. – 2017. – № 12. – Б. 40 – 41.

Хәсәнова Ф. Шигърияттә – яңалык // Казан утлары. – 2010. – № 4. – Б. 134 – 142.


аерып куярга омтыла: кеше табигатеннән ялгыз һәм яшәеш контурларын да үзе өчен үзе сыза; ул, иҗтимагый кануннарга баш имичә, кешелеген саклап калырга тиеш; матди тормышка түгел, рухи яшәешкә, рухи югарылыкка омтылу лазем; бу тормышның фанилыгын, һәрнәрсәнең вакытлы булуын онытмау мөһим кебек

# ОБ ЭСТЕТИЧЕСКИХ ВЛИЯНИЯХ В ДЕКОРАТИВНО-ПРИКЛАДНОМ ИСКУССТВЕ НА ПРИМЕРЕ ЦВЕТОЧНОГО ОРНАМЕНТА В ТЮРКСКОЙ КЕРАМИКЕ

## (STYLISTIC INFLUENCE IN DECORATIVE-APPLIED ART ON THE EXAMPLE OF FLOWER ORNAMENT IN TURKIC CERAMICS)

**Mikhail YAO***
**Juliana EMANOVA****

**SUMMARY**

The article deals with the specifics of arts and crafts. The main feature of arts and crafts is the inextricable link between the form of the object and its purpose, between the material from which it is made and the decor that adorns it. On the specifics of Muslim art. An important component of the artistic image in the Muslim arts and crafts is an ornament. Ornament is endless in time and the possibilities of using in the decorative design of material culture. The ideological reason for using the ornament lies in its unifying possibilities. Ornament becomes here a sign, a symbol, a semantic component of an artistic image. Museums traditionally contribute to the peaceful introduction of other cultures into the art of the country, the emergence of new directions. Ceramics can symbolize all decorative and applied art. It is the most ancient and widespread artificial material. China is the birthplace of porcelain. For a long time its composition was the main technological secret of the country. Chinese ceramics had aesthetic impact on the Christian and the Muslim world. In the Turkish ceramics of Iznik interpreted the motifs of lotus flowers, peony, "Chinese clouds". In turn, Turkish ornamental carnations and tulips have become a symbol of the entire Turkic world. They are found in the decor of European countries. In the ceramics of the village of Pestretzi of the Republic of Tatarstan (Russia), one can find ornamental techniques of Turkish plant motifs. Pestrechinsky ceramics are characterized by dense painting colored clays. The elements of the ornament are inscribed with a slightly deeper contour and have a slightly pronounced relief. Ornamental motives are simplified folk interpretations of plant and flower ornaments created under the impression of Iznik ceramics.

В статье говорится о специфике декоративно-прикладного искусства. Главная особенность декоративно-прикладного искусства – это неразрывная связь между формой предмета и его назначением, между материалом, из которого он сделан и декором, украшающим его. О специфике мусульманского искусства. Важной составляющей художественного образа в мусульманском декоративно-прикладном искусстве является орнамент. Орнамент бесконечен во времени и возможностях использования в декоративном оформлении материальной культуры. Идейная причина использования орнамента лежит в его объединительных возможностях. Орнамент становится здесь знаком, символом, смысловым компонентом художественного образа. Музеи традиционно способствуют мирному

* Candidate of Sociological Sciences, Associate Professor, Kazan Federal University, Kazan.
** Candidate of Sociological Sciences, Associate Professor, Kazan Federal University, Kazan.

привнесению иных культур в искусство страны, появлению новых направлений. Керамика может символизировать собой всё декоративно-прикладное искусство. Она является наиболее древним и распространенным искусственным материалом. Китай – родина фарфора. Его состав долгое время был главным технологическим секретом страны. Китайская керамика оказало эстетическое воздействие и на христианский, и на мусульманский мир. В турецкой керамике Изника интерпретируются мотивы цветов лотоса, пиона, «китайских облаков». В свою очередь турецкие орнаментальные гвоздики и тюльпаны стали символом всего тюркского мира. Они встречаются в декоре европейских стран. В керамике села Пестрецы Республики Татарстан (Россия) можно встретить орнаментальные приемы турецких растительных мотивов. Для пестречинской керамики характерна плотная роспись цветными глинами. Элементы орнамента обведены незначительно углубленным контуром и имеют слабо выраженный рельеф. Орнаментальные мотивы представляют собой упрощённые народные интерпретации растительных и цветочных орнаментов, созданных под впечатлением изникской керамики.

Декоративно-прикладное искусство – это искусство художественного осмысления предметов, окружающих человека, составляющих его быт. Декоративно-прикладное искусство бывает – «народное» и «профессиональное». Народное декоративно-прикладное искусство анонимное и консервативное, оно существует в виде ремёсел и промыслов. Формы, возникающие в народном искусстве, оттачиваются многими поколениями мастеров, они опираются на стабильную, консервативную художественную традицию.

Профессиональное декоративно-прикладное искусство направлено на обслуживание состоятельных слоев общества, в силу своей высокой стоимости. В профессиональном декоративно-прикладном искусстве создаются стили эпохи, которые распространяются и на другие виды искусства. Примером может служить английское художественное движение викторианской эпохи «Искусства и ремёсла» во главе с его лидером Уильямом Моррисом, заложившее эстетическую основу для стиля «Ар Нуво». В свою очередь художники этого движения, ратовавшие за ручную выработку предметов, опирались на народную традицию. Они ставили своей целью сблизить искусство и ремесло, стремились привнести эстетизм и новизну в отработанную ремесленниками простую и функциональную форму. Идеологической основой этого движения стали взгляды Джона Рёскина, в том числе, провозглашенный им принцип «верности природы» и готическое искусство как эстетический образец. В 1852 году в Лондоне, после проведения Великой выставки промышленных работ всех народов 1851 года, был открыт крупнейший музей декоративно-прикладного искусства и дизайна музей Виктории и Альберта, который располагает коллекцией турецкой керамики.

Вопросы влияния на формирование стиля в декоративно-прикладном искусстве и поиск эстетических параллелей – это увлекательный искусствоведческий детектив. Музеи традиционно способствуют мирному привнесению иных культур в искусство страны. Так было, когда открылся музей этнографический музей Трокедеро в Париже, где было представлено искусство народов Африки, Азии, Океании и Америки. Можно сказать, что он во многом обусловил появление модернизма, в целом, и таких его направлений как «фовизм» и «кубизм». Свою лепту в соединение культур

внесло и экзотическое для европейца собрание китайского фарфора в султанском дворце музея в Топкапе в Стамбуле. В свою очередь турецкая керамика так же представлена в коллекциях Севрского музея керамики, в государственных музеях Берлина, в музее Метрополитен в Нью-Йорке.

Суть искусства в исламском мире замечательно сформулирована исследователем мусульманского искусства Г. фон Грюнебаумом: «Европейцев тревожит беспорядочность, а мусульман удивляет регулярность», тем самым подчеркивая различия между стремлением европейского мышления к отражению мира в геометрических формулах гармонии и пониманием той же гармонии в эстетике ислама, где она трактовалась «как привычка божества, от которых оно в любое время может отказаться» (Грюнебаум, 1981: 214).

Национальное художественное сознание мусульманских народов, развивавшееся в художественных абстракциях декоративно-прикладного искусства, органично воспринимает условное. Художественный образ в декоративно-прикладном искусстве можно представить в виде ромба, каждой вершине которого будет соответствовать одна из специфических составляющих этого вида искусства: форма, назначение, материал и декор. Орнамент бесконечен во времени и возможностях использования в декоративном оформлении материальной культуры. Идейная причина использования орнамента лежит в его объединительных возможностях, цельном, ощущаемом и, в то же время, абстрактном образе. Орнамент становится здесь знаком, символом – не дополнительным декоративным, а смысловым, составляющим компонентом художественного образа.

Мусульманин не терпит визуального обмана, навязанной материализации образа и легко воспринимает условность как форму его существования. «Человек», как персонаж, в Гюлистане не главное явление. Он является лишь частью его красоты, так же как растения и животные в этом райском саду (Яо, Еманова, Салахов, 2014: 206).

Мусульманское искусство не подчиняет образ информационной функции изобразительного искусства. Художественную гармонию, воплощенную в орнаменте и каллиграфии, мусульманину легче воспринять, так как за визуальным образом он видит его абстрактное, символическое значение.

Нам представляется, что те характерные качества, которые были выявлены и отшлифованы в декоративно-прикладном искусстве, мусульманским сознанием экстраполируются и на другие новые виды искусства, в частности на его плоскостные виды. С определенной долей условности, можно выделить следующие их черты: 1) плоскостность композиции как естественная форма существования художественного образа; 2) декоративность, как неотъемлемое художественное качество; 3) насыщенность композиции, стремление заполнить плоскость по «ковровому» принципу; 4) орнаментальность композиции; 5) яркий, лаконичный колорит с преобладанием локальных цветов; 6) созерцательный характер изображения, с пульсирующим ритмом изложения (Яо, 2012: 68).

Ни один вид изобразительного искусства не имеет столько подвидов, сколько декоративно-прикладное искусство, так как человек живет в многообразных климатических, экономических, религиозных, социальных, этнических условиях. Многообразие жизненных укладов определяет многообразие видов декоративно-прикладного искусства. В общем виде его можно дифференцировать по используемым материалам: керамика, дерево и

растительные материалы камень, металл, текстиль, кость и иные природные, а так же синтетические материалы. В этом многообразии материалов керамика может символизировать собой всё декоративно-прикладное искусство, поскольку является, вероятнее всего, первым искусственным материалом, созданным человеком.

На развитие гончарного дела во всём Старом Свете оказало большое воздействие керамика Китая в целом, и особенно, открытие в IX веке фарфора. Фарфор стал едва ли не основной статьей экспорта из Поднебесной, превзойдя по объему даже экспорт шелка. Китайский фарфор можно встретить в самых отделенных уголках Евразии. Сохраняя секрет производства «Порцелана» Китай оказал воздействие и желание подражать ему как у христианского, так и у мусульманского мира. Не зная секретов производства, мастера в разных уголках земли экспериментировали и открывали аналоги фарфоровой массы, порой вплотную подходя к разгадке тайн фарфора. Примером может служить «фарфор Медичи» (XVI в.), «Дельфтский фаянс» (XVII) и «Мягкий фарфор Севра» - это керамические массы, которые на самом деле фарфором не являются. Своим путем овладения тайной фарфоровой массы шли керамисты Ирана и позднее Турции.

Первооткрывателями турецкого фарфора для европейцев принято считать С. Фортнэма и А. Жакмара, которые в 70-80 –х годах XIX века предприняли попытку научного описания и классификации турецкой керамики. Исследование продолжили работы Ф. Зарре. Г.Мижона и А. Сакисьяна, Б. Рэкхэма, А Лейна, К. Отто-Дорна, К.Эрдмана. В русском искусствоведении изучением турецкой керамики занимались А.А. Карбоньер, А.А. Половцев, а в советском – И.А. Орбели, А.Н.Кубе, Э.К. Кверфельдт, В.С. Гарбузова, Ю. Миллер и др.

Особенностью иранской и турецкой керамической массы с XV- XVI вв. была смесь белой глины – коалина с размолотым кварцем. Таким образом, для получения настоящего фарфора им оставалось лишь добавить в массу полевой шпат. Эта кварцевая смесь, уступая в пластичности и цвете настоящему фарфору, тем не менее, открыла большие возможности, как в формообразовании, так и в декорировании предметов.

Главным центром керамического производства в Турции являлся город Изник, где уже в XV столетии было широко развито керамическое производство, творчески перерабатывающее образцы китайского фарфора. Вплоть до конца XVI века изникская керамика носила сугубо уникальный характер и не производилась в промышленных, серийных масштабах (Моццати, 2012: 246). Подражание Китаю проявлялось в различных центрах в двух направлениях. Первое – в формообразовании, когда мастера аранжируя, воспроизводили классические китайские формы предметов. Особенно влюбленность в китайский фарфор проявилась интерпретациях орнаментальных мотивов – это второе направление. Так, изникские мастера, используя импортированные из Китая предметы, уже с XIV века, воспроизводили кобальтовую посуду эпохи Юань (XIII – XIVвеков) и Мин (XIV-XVII веков). Характерно, что в эпоху Мин было налажен экспорт фарфоровых изделий специально для стран Среднего Востока, которые украшались, учитывая запреты Ислама, преимущественно растительным орнаментом. Многие из них были украшены цитатами из Корана (Фар-Бекер, Хаземанн, Дунн, 2015: 208). Особенно популярными были расписные блюда. Повторяя китайские образцы, мастера Изника по-своему, стилистически разнообразно

интерпретировали мотивы цветов лотоса – «хатаи», пиона, перистых листьев и «китайских облаков» (Миллер, 1972: 27). Эти пришлые мотивы органично соединились в орнаментике Изника со своими местными мотивами. Мастера широко вводили в свои композиции изображения изящных, вытянутых цветков тюльпана, гвоздики и гиацинта. Как и на китайском фарфоре на блюдах Изника и ныне плывут под раздувшимися парусами стилизованные парусники.

Такая орнаментика позднее будет подхвачена европейскими центрами керамики. Гвоздики и тюльпаны, увиденные уже на турецкой керамике, займут свое достойное место в росписях Дельфта.

Своеобразное воздействие турецкой керамики можно ощутить в изделиях мастеров из центра традиционной керамики Татарстана села Пестрецы. Здесь с середины XIX века производилась керамика. Она получила распространение среди мусульманского населения России и даже экспортировалась за её пределы в Иран. В продукции этого центра часто встречаются формы, напоминающие турецкие кувшины и цветочные вазы. Для пестречинской керамики характерна плотная роспись ангобами – цветными глинами по такому же фону. Элементы орнамента обведены незначительно углубленным контуром и имеют слабо выраженный рельеф. Орнаментальные мотивы представляют собой упрощённые народные интерпретации растительных и цветочных орнаментов, созданных под впечатлением изникской керамики. Интересен характер этих интерпретаций. Вытянутый зубчатый лист с острым завершением на пестречинском кувшине загибается, напоминая среднеазиатского огурца, а веточка гиацинта превращается в гирлянду из голубых четырехлепестковых цветов. Здесь же встречаются и чисто турецкие вытянутые тюльпаны с изящными лепестками, и стилизованные цветы, напоминающие одновременно «китайско-турецкие» пионы или цветы лотоса. Вероятно, под турецким влиянием мотив тюльпана стал общетюркским орнаментальным элементом, его можно увидеть и в керамике, и в кожаной мозаике, и в ювелирном искусстве, и в текстиле. Мотив тюльпана занимает заметное место и в европейской орнаментике, являясь национальным элементом декора немецкого, фламандского и особенно голландского искусства. Сам цветок является неофициальным символом этой страны. В изразцах, текстильных принтах и оформлении полей книг компании "Моррис, Маршалл, Фолкнер и Ко" угадываются не только цветочные средневековые «Мильфлеры», но и уже знакомые восточные мотивы.

**ЛИТЕРАТУРА**

Грюнебаум Г.Э. фон. Основные черты арабо-мусульманской культуры.– М.: Наука, 1981 г.– 292 с.

Миллер Ю.А. Художественная керамика Турции.– Л.: «Аврора», 1972 .– 184 с.

Моццати Л. Исламское искусство.– М.: Арт-родник, 2012.– 319с.

Фар-Бекер Г., Хаземанн З., Дунн М. Искусство Восточной Азии.– М.: Арт-Родник, 2015. – 740 с.

Яо М.К. Образное мышление в изобразительном искусстве в свете идей Н.С.Гумилева// Евразийство и проблемы современной науки: коллективная монография/ Казан. гос. ун-т культуры и искусств.– Казань: Культура, 2012.– Ч.2.– С.67 –73.

Яо М.К., Еманова Ю.Г., Салахов Р.Ф. О специфике национального образного мышления в изобразительном искусстве//Tatarika: Scientific chronicles of the turkis world.– Казань.–2014.– №1(2).– С.201– 208.

# СЕБЕР ТАТАРЛАРЫНЫҢ ЙОЛА ТӘҖРИБӘСЕНДӘ АНТРОПОМОРФ СУРӘТЛӘР
## (2015 елны Томск өлкәсендә үткән экспедиция материалларына нигезләнеп)

## (ANTHROPOMORPHIC IMAGES IN RITUAL PRACTICE THE SIBERIAN TATARS)

**Gulnara YAKHSHISAROVA***

**SUMMARY**

In modern science it is important to study the folklore features of the enclave. The article discusses the reflection of the history and culture of the Tomsk Tatars enclave in their folklore, as well as the restoration of different sides of ethnosocial processes based on materials collected during expeditions.

To date, the epic folklore of the Tomsk region Tatars is gradually disappearing from the lips of the elderly. However, analyzing the material collected during the expedition, we came to the conclusion that some genres of folklore of the Tatars of the Tomsk region continue to exist today.

The cult of the dolls, the worship of idols-which, to date, have not survived. At the same time, the legends retain descriptions, terminology and peculiarities of this element of spiritual culture.

Idols-dolls by function and location were "brownies" i.e. belonged to the same family and dolls, which was worshipped by entire generations or residents of the same village. In some houses, dolls continue to be made, explaining this phenomenon as a tribute to tradition.

Thus, we can conclude that the Siberian Tatar and some other Turkic peoples living on the territory of Siberia (Altaians, Shors, Khakas etc.) are preserved some aspects of pagan beliefs.

Соңгы елларда рухи культураның, мифологиянең төрле катламнарын өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Без әлеге хезмәтебездә Томск татарлары хәтерендә сакланып калган курчакка табыну йолаларына тукталабыз. Әлеге мәкаләдә курчакның функциональ мөмкинлекләрен ачыкларга, төрле социаль аспекттагы кулланышын өйрәнергә, шул исәптән дөньякүләм культураның мифология һәм идеологияга караган системаларны тасвирларга омтылдык.

